Безнен МИРАС

ISSN:2500-011X

12

декабрь 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Ф.Нуретдинова фотолары

Уртак максатлар җыены

21 ноябрьдә КФУның Лев Толстой исемендәге Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында «Идел буе республикалары милли әдәбияты: мәдәниятара багланыш мәсьәләләре» дип аталган төбәкара фәнни-гамәли конференциясе булды. Әлеге җыен кысаларында Идел буе төбәгендәге милли әдәбиятларның бүгенге торышы, үсеш-үзгәреш үзенчәлеге, мәдәниятара багланышлар, милли әдәбиятларны мәктәптә һәм югары уку йортларында укыту мәсьәләләре игътибар үзәгенә куелды. Пленар утырышта Идел буе төбәгенең алты республикасыннан – Татарстаннан, Чувашиядән, Марий Элдан, Мордовиядән, Удмуртиядән, Башкортстаннан килгән галимнәр чыгыш ясады.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +
12 (276)
декабрь 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас»,
2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ
тарафыннан кабат гамәлгә куелып,
«Чын мирас» исемнәре белән чыкты.
2014 елның маеннан «Безнең мирас»
итеп үзгәртелде.

78

68 ОЛЫ ҖАНЛЫ ШӘХЕС ИДЕ.
Нәҗип Нәккаш

94 ТАТАР ҖЫРЫ – УЛ МӘҢГЕЛЕК!
Гөлзадә Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 *Марс Макаров*

ТАРИХИ МИРАС

4 **Болгар. Табиб йорты**
6 **Алтын Урданың икътисади багланышлары.** *А.Арсланов*
12 **«Сәфәр-89».** *А.Борһанов*
17 **Литва татарлары кулъязмасы.** *Г.Мишкинене*
20 **Метрикада — татарның үткәне.** *Э.Сәлахова*
24 **Уңышлы башламнар.** *Л.Хәмидуллин*
30 **Кызлар язмышы — милләт язмышы.** *Т.Биктимерова*

ТАТАР ГАМЕ

34 **Киләчәк кешесе үрнәге.** *Ә.Зарипов*
42 **Без килмешәк түгел бу җирдә!**

ӘДӘБИ МИРАС

44 **Кутадгу билик (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
48 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
58 **Остазымның хаты.** *Ә.Шәрипов*
60 **«Штык һәм каләм белән...»** *Ш.Мостафин*
68 **Олы җанлы шәхес иде.** *Н.Нәккаш*
75 **Кара һәм ак мунча.** *Л.Зөлкарнәй*
77 **Киң сибелгән безнең халык җир йөзенә.** *Г.Хәсән*

СӘНГАТИ МИРАС

78 **Милләтнең күңел җәүһәрләре.** *Р.Шаһиева, Р.Фәизова*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

88 **Һ.Атласи.** *Р.Мөхәммәтша*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 **Бер рәсем тарихы.** *М.Зәйнетдинов*
91 **Үткәннән хат.**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ТАТАР ҖЫРЫ

94 **Татар җыры — ул мәңгелек!** *Г.Сафиуллина*
99 **Урау юллар гизеп табылган бәхет.** *М.Макаров*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

102 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

104 **Еллар кайтавазы, яки бер сәфәр.** *Ф.Кутлу*
108 **Сөембикә ханбикә.** *Г.Җәләлева*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

110 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның декабрь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

112 **Вак-вак ләтыйфәләр һәм хикәя кисәкләре.** *Р.Шәрәфиева*

114 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Декабрь*
115 **Мирасворд**

Заказ №М-3079. Тираж – 1500 данә. Формат 70 X 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.11.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе иректә.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Кышкы пейзаж». Киндер, майлы буяу.
И.Зарипов рәсеме

МАРС МАКАРОВ
(1939-2016)

***
Аксакал сүзе – дөньяның күзе...

***
Бер очкын могҗиза тудыра...

***
Коткарыгыз, дигән тавыштан
Куркакның коты алынган...

***
Битараф кешенең йөзенә күз яшен сипсәң дә, керфеге дә селкенмәс...

***
Саран – бирмәс тә, сорамас та...

***
Чиксез байлыктан саклану өчен иң ышанычлы урын – табут...

***
Тау астында озак еллар буе яткан сер бервакыт чишмә суы кебек бәреп чыгар...

***
Яшьлек – тиле, мәхәббәт – яшьлек чире...

***
Иң зур теләк – суга сусау.

***
Даны артканның гайбәте дә арта...

***
Дөньяның иң гүзәл бердәнберен эзләмә! –
Хәтта Кояш та, галәмдә бердәнбер түгел...

***
Сәхнә – тынлыкка интеккән...

***
Чын талант – тумыштан туган һөнәргә ия...

Текстны ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Болгар. Табиб йорты

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

2012 елның 5 октябрендә шәһәрлекнең үзәк өлешендә Россиядә бердәнбер булган гарәп-мөселман медицинасы музее – Табиб йорты ачылды. Төзелешнең инвесторы – «Русский стандарт» холдингы (идарә рәисе Рөстәм Тарико). Музейның фәнни концепциясенең төп максаты – Болгарның һәм Идел буе Болгар дәүләтенең фәннәр, атап әйткәндә медицина, табигать белеме, фармакология, шулай ук әлеге тармакларга бәйле һөнәрләр үсеше үзәкләренең берсе буларак ролен чагылдыру.

Экспозициянең төп темасы – Идел буе Болгар дәүләтеннән булган урта гасыр табибы Таҗетдин Әл-Болгари хезмәтләре. Ул мөселман дөньясына яхшы мәгълүм булган. Таҗетдин Әл-Болгари кулъязмалары –«Әт-тиръяк әл-кабир» (Зур тиръяк), «Әл-әдвия әл-мофрад» (Бердәнбер дару) һәм «Мохтасар фи мәгърифә әл-әдвия» (Даруларны белү өчен кыска китап). Аларның күчермәләре Иран белән Төркия музейлары, китапханәләре фондларыннан һәм саклагычларыннан кайтарылды. ■

Алтын Урданың икътисади бәйләнешләре

Азат Арсланов

(XIII гасырның икенче яртысы-XV гасыр)

Монгол империясенең икътисади нигезен халыкара сәүдә һәм ул китергән табыш тәшкил иткән. Шул сәбәпле, сәүдә юлларын контрольдә тоту, аларда куркынычсызлык тәртибе урнаштыру, илчеләргә һәм сәүдәгәрләргә көнкүреш уңайлыклары, ял, сату-алу, товар саклау өчен шартлар тудыру, мәмләкәтнең бер өлкәсеннән икенче өлкәсенә тиз арада күчеп йөрү мөмкинлеге булдыру – болар барысы да Чыңгыз илендә дәүләт сәясәте дәрәҗәсенә күтәрелгән.

«Каталония атласы»нда Аурупа күренеше. 1375 ел

Бу сәяси тәгълиматка нигезләнеп, Аурасия киңлекләрендә махсус урбанистик сәүдә структуралары тергезелгән – монгол мәмләкәтенә яңа кушылган җирләрдә элеккеге сәүдә үзәкләре торгызылган, су һәм сәүдә юлларында шәһәрләр, кәрвансарайлар төзелгән. Әлеге процесслар Аурасия киңлекләрендә XIII гасырның беренче яртысында башланып, XV гасырның ахырына кадәр дәвам иткән. Бу эшләрдә әйдәп баручы ролен XIII йөзнең алтмышынчы елларында бәйсезлек алган Алтын Урда (Җучи олысы) үтәгән.

Җучи олысы ханнарының аерата зур казанышы – урта гасырның иң мәртәбәле һәм бай сәүдә юлын – Бөек ефәк юлын киңәйтү, аның төньяк тармагын булдыру. Моннан тыш, сәүдә мөнәсәбәтләрен

Бөек ефәк юлындагы базар. Е.Садырбаев рәсеме

урнаштыру, көндәш-конкурентлар арасындагы конфликтларны хәл итү, сәүдә эшен дәүләт тарафыннан тәртипкә салу, махсус сәүдә-аралашу зоналары булдыру механизмнары да иң беренчеләрдән булып Алтын Урдада киң кулланылышка кертелгән. Мондый үзгәреш-яңалыклар һәм, әлбәттә, территориаль яулап алулар нәтиҗәсендә Җучи олысы бик тиз арада Көнбатыш-Көнчыгыш арасындагы сәүдәне җайга салуга һәм Көнбатыш илләренең иң ышанычлы партнерына әверелүгә ирешә.

Хәзерге тарих фәнендә, Җучи олысы Аурупа илләре белән, нигездә, Каффа һәм Тана диңгез портлары аша, Генуя һәм Венеция сәүдәгәрләре арадашлыгында сәүдә иткән, дип фаразлана. Алда аталган сәүдә үзәкләре аша Мисырга һәм Көнбатыш Аурупа илләренә озатылган товарлар күләме бу юнәлештә кәрван юлларыннан озатылган товар күләменнән бермә-бер артык булган.

Шулай да, Алтын Урданың Көнбатыш илләре белән сәүдә итүендә кәрван юллары шактый мөһим роль уйнаган. Ул юллар Җучи олысының төньяк алман һөнәрчелек үзәкләре һәм Польша, Литва, Молдавия, Чехия шәһәрләре белән багланышын тәэмин иткән. Моңа кадәр Көнчыгыш һәм Көнбатышны тоташтырып торган коры җир сәүдә юллары монгол яуларыннан соң да (XIII гасырның беренче яртысы) үз вазифасын үтәгән, билгеле. Алар арасында ике сәүдә юлы аеруча актив кулланылган. Шуларның берсе Чехия, Польша, Киев һәм урыс җирләре аша алман сәүдә-кәсеп үзәкләрен Болгарга тоташтырган. Башта Киев, аннары Бату хан күчеп йөргән түбән Идел далаларына бару өчен, Рим папасы Иннокентий IV илчесе Иоанн Плано Карпини да шушы юлдан файдаланган, күрәсең.

Бу сәүдә юлы XIII гасырның ахырына кадәр кәрваннар уздырган. Әмма соңрак урыс сәүдәгәрләренең активлашуы һәм урыс кенәзләренең аларга ярдәм күрсәтергә омтылулары сәбәпле, аның юнәлеше үзгәргән. XIV гасыр башыннан Көнбатыш сәүдәгәрләренең юлы Киевтан көньякка – Алтын Урданың Азов диңгезе ярында һәм Кырымда урнашкан шәһәрләренә алып барган, моннан Тана һәм Каффа калаларына күн, тире, бал һәм балавыз китерелгән.

Бу юл белән бергә урыс җирләрен читләтеп уза торган икенче юл да булган. Анысы тарихи чыганакларда беренче тапкыр 1344 елның 14 мартында Җанибәк хан гаскәрләре Тана шәһәрен камап алуга бәйле рәвештә искә алына[1]. Ул Азов һәм

[1] Régestes des délibérations du sénat de Venise concernant la Romanie/ Par F. Thiriet. – Paris, La Haye: Mouton, 1958. – T.1 (1329-1399). – P.54.



Львов шәһәре. Гравюра. 1618 ел

Кара диңгезләрнең төньягында урнашкан Тана, Каффа, Аккирмән (хәзерге Белгород-Днестровский), Львов, Краков шәһәрләре һәм алман кенәзлекләре аша Италиягә илткән. Әлеге юл тарихи чыганакларда «татар юлы» исеме белән искә алына.

Алтын Урда сәүдәгәрләренең сәфәре, гадәттә, хәзерге Львов шәһәрендә тәмамланган. Львов сәүдәгәрләре «татар юлы»нда арадашчы вазифасын башкарган.

Ни өчен нәкъ менә Львов соң?

Эш шунда ки, бу шәһәр, чикләнгән формада булса да, феодаль склад хокукына ия булган. Урта гасыр сәүдә кагыйдәләре нигезендә, мондый хокуклы шәһәргә килгән һәрбер сәүдәгәр биредә тукталырга һәм күпмедер вакыт аралыгында (гадәттә ундүрт көн) үз товарларын сатарга тиеш саналган. Шәһәр кануннары таләп иткән вакыт узгач, сәүдәгәрләргә юлын дәвам итәргә мөмкинлек бирелгән. 1375 елда төзелгән мәгълүм «Каталония атласы»нда Львов шәһәре нәкъ менә шул сәбәпле көнчыгыш товарлары склады итеп күрсәтелгән дә[2]. Ә шул чор сәүдәгәрләреннән калган юлъязмаларда ул «Көнчыгышның коры порты» дип искә алына.

Бу шәһәр белән Җучи олысы арасында урнашкан товар-акча мөнәсәбәтләренә тәфсилләбрәк тукталыйк. Алда әйтелгәнчә, Алтын Урда калаларының Львов белән сәүдәсе арадашлык характерында алып барылган. Биредә сатылган көнчыгыш товарларының бер өлеше генә җирле халык кулланылышында калган, үзгә өлеше Польшаның көнбатыш өлкәләренә һәм Силезиягә, Фландриягә, Алманиягә, Италиягә озатылган.

Алтын Урдадан Львовка, нигездә, күпләп терлек куганнар. Әлгәре искәртелгән Плано Карпини язмаларында мондый сүзләр очрый: *«Алар (Алтын Урда халкы.* – А.А.) *мал-туарга бик бай. Монда дөяләр, үгезләр, сарыклар, кәҗәләр һәм атлар саны бихисап. Аларда булган кадәр терлек, безнеңчә, бөтен галәмдә юк»*. Алтын Урдада терлекнең күп үрчетелүе турындагы мәгълүматны без биредә 1436-1452 елларда яшәп ал-

[2] «Каталония атласы» –Арагон короле Хуан I гозере буенча атаклы картографлар – аталы-уллы Крескеслар тарафыннан Пальма-де-Майорка (Испания) шәһәрендә якынча 1375 елда төзелгән дөнья картасы. Әлеге атлас үз чоры өчен иң төгәлдән санала. Хәзерге көндә ул Париж шәһәрендә, Франциянең милли китапханәсендә саклана.

ган Венеция сәяхәтчесе һәм сәүдәгәре Иософат Барбаро язмаларында да очратабыз. Ул билгеләп үткәнчә, Җучи олысы халкы махсус сатар өчен ат, эре мөгезле терлек, дөя һәм сарык асраган. Автор фаразлавынча, атлар һәм дөяләр, нигездә, Көнчыгыш илләренә сатылган, ә менә сыерларга һәм үгезләргә Көнчыгыш һәм Көнбатыш Аурупа илләрендә (бигрәк тә Польшада, Трансильваниядә, Валахиядә, Алманиядә һәм Италиядә) ихтыяҗ зур булган. Бу илләргә мал-туар шулай ук коры җир юлы буйлап та куылган.

Терлектән тыш, Львовка төрле җәнлек тиреләре, ашлык, бал, балавыз, агач һәм һөнәрчелек әйберләре, шәраб, төрле ут-үләннәр, күн-мех эшләнмәләре һәм, билгеле, «көнчыгыш товарлары» – хәтфә, ефәк, энҗе, хушбуйлар, төрле тәмләткечләр, затлы келәмнәр, зәркән эшләнмәләре китерелгән; моннан ары алар Краковка, Познаньга, Вроцлавка, Торуньга һәм Үзәк Аурупаның башка шәһәрләренә озатылган.

Львов аша коры җир буйлап генуялыларның кол сату юлы да узган. Акт кенәгәләрендә сакланган язмаларда XIV гасырда биредә Генуя сәүдәгәрләренең күпләп торуы һәм эш итүе теркәлеп калган. Польша галимнәре уздырган эзләнүләр күрсәткәнчә, Львов һәм Краков базарларында сатылган коллар, нигездә, Каффа, Тана, Солдайя (Судак), Воспоро, Копа (бүгенге көндә Славянск-на-Кубани), Чембало һәм Килия (Ликостомо) шәһәрләре базарларында сатып алынган. Бу колларның бер өлеше Польша һәм Литва шәһәрләрендә калган. Әйтик, Кара диңгез буеннан китерелгән коллар Польша короленең Краковтагы мәгълүм Вавель замогын төзүдә катнашкан. Шулай да, колларның күбесе тагын да арырак – Аурупа эченәрәк озатылган.

Литва һәм Польша сәүдәгәрләре Алтын Урдага, нигездә, Аурупа тукымаларын, һөнәрчелек товарларын саткан. Бу товарлар Кырым һәм Азов буендагы Алтын Урда шәһәрләрендә, ә кайвакыт хәтта Идел буендагы калаларда да күпләп алынган. 1997 елда уздырылган казу эшләре барышында Алтын Урданың башкаласы – Сарай-Батуда (хәзерге Селитренное шәһәрлеге) XIV-XVII гасырларга караган Көнбатыш Аурупа сәүдә пломбалары табыла. Мондый пломбалар, гадәттә, зур тукыма бәйләмнәренең озынлыгын раслар өчен файдаланылган. Пломбаларда Алмания, Фландрия, Нидерланд, Англия шәһәрләренең исемнәре теркәлгән. Шуңа охшаш пломбалар соңрак Алтын Урданың башка шәһәрләрендә дә табылган.

«Татар юлы»нда хезмәт күрсәтүче сәүдәгәрләрнең милләтен барласак, биредә Галиция, Генуя, Польша һәм Литва сәүдәгәрләре аеруча актив эш йөрткән, дигән фикергә килербез. Әмма әрмән һәм татар сәүдәгәрләре дә аз булмаган.

Урта гасыр Польша шәһәрләре архивларында табылган документлар Львовта хәтта ки әрмән һәм татар кварталлары булуы турында сөйли. Моны раслаучы иң беренче чыганак – 1356 елгы Казимир III грамотасы. Татарлар шәһәрнең «Татар җирлеге» («Татарское предместье») дип аталган төньяк өлешендә яшәгән. (Шунысы кызыклы: хәзерге Львов шәһәрендә әлеге квартал урынында Татар урамы урнашкан. – А.А.) Шәһәрнең акт китапларында татарлар һәм татар сәүдәгәрләре турында бик күп искә алына. Мәсәлән, 1382-1389 елларда тутырылган шундый китапта татар сәүдәгәрләре катнашында узган сату-алу эшләре хакында бәян ителә. Әйтик, 1386 елның 8 августына караган язмада «Андреаш, татар, католик» сүзләре телгә алына. Әлеге мисалдан күренгәнчә, Львов шәһәренең нотарийлары (хокук белгечләре) сәүдәгәрләрнең исемен, милләтен һәм аның нинди конфессиягә каравын күрсәткән. Шул рәвешле нотарийлар төрки исемле үз гражданнарын (җирле татар общинасы әгъзаларын) «килмешәк» көнчыгыш сәүдәгәрләреннән аерган.

Шунысын да искәртик: китапларда күрсәтелгән милләт йә конфессия атамасы бу кешенең, чыннан да, католик,

православие яисә яһүди динен тотуын һәм аның, чыннан да, урыс, әрмән, яһүд яисә поляк милләтеннән булуын расламый әле. Баягы актлар китабына мөрәҗәгать итик. Әйтик, 1387 елның 16 гыйнварына караган язмада «мөхтәрәм ир Карачбей, католик» телгә алына, ә 1384 елның 26 октябренә караган язмада «Ширбей русин йорты һәм милке» турында сүз бар. Әрмән галиме Осипян Львов шәһәрендә яшәүче татарларның XIV гасырның икенче яртысында күпләп католик, православие һәм әрмән җәмгыятьләренә күчүен билгели. Бу күренешне ул 1356-1387 еллар аралыгында Львов татарларының «хәрби-йомышлы» статусын югалуты белән бәйли. Осипян фикеренчә, шул рәвешле татарлар элеккеге ташламаларын, преференцияләрен саклап калырга, хәтта ки аларны арттырырга омтылган. 1382-1389 елларга караган актлар китабында әрмән общинасы әгъзалары арасында күп кенә төрки исемнәр очрый. Шуларның кечкенә бер өлешенә күз салыйк: Abusco, Amyrbey, Asslan, Attabey (Athabey, Atlabey, Atlhabey, Achtibey), Petrus Buha, Cotlubey, Cotlusch, Czaban/Czoban, Iolbey, Kystustur, Orus, Saray, Sewoncz/Sewnucz, Tholak, Tochbey. Хатын-кыз исемнәре чыганакта сирәк очрый, әмма булганнары арасында төрки исемнәр күпчелекне тәшкил итә: Bemolik, Cotlumelik, Mamusz, Saymnelyk/Saym/Sayn, Sennachaton, Thormelyk, Zolmelyk.

XIV гасыр уртасыннан алып, «татар юлы» бетүгә йөз тота. Моңа әлеге, юллар үткән җирләрнең хуҗалары алышыну сәбәбче була. Үзбәк хан идарә иткән чорда хәрби-сәяси кодрәткә ирешкән Алтын Урда таркалыш чорына күчә һәм эчке тотрыклылыгын югалта. Мөмкинлектән файдаланып, Литва, Польша һәм Мажарстан (Венгрия) илләре «татар юлы» үткән җирләргә дәгъва белдерә. 1362 елда Җучи олысының сәяси абруе һәм хәрби дәрәҗәсе яхшы ук какшый: Алтын Урданың көнбатыш җирләрендә хакимлек иткән бәкләр – Котлыбуга, Хаҗибәй һәм Димитрий Синюха елгасы (Көньяк Буг елгасының сул кушылдыгы) буенда бөек кенәз Ольгерд гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителә.

Бу җиңелүдән соң шактый хәлсезләнгән Алтын Урда үз позицияләрен кире кайтара алмый һәм Днепр елгасыннан көнбатышка таба урнашкан җирләрдән чигенергә мәҗбүр була. Соңрак биредә яңа дәүләт – Молдавия кенәзлеге урнаша.

Җучи олысының әлеге территорияләрне калдыруы «татар юлы»нда барган сәүдәне тулысынча өзми, билгеле. Львов һәм Краков сәүдәгәрләренең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә ул XIV гасырның ахырына кадәр үз вазифасын башкара. Моны археологик материаллар да, язма чыганаклар да раслый. Мисал итеп, Жильбер де Гильбер де Ланнуа белән Амброзио Контарини күзәтүләрен, шулай ук 1372, 1379 елларда Краков һәм Львов сәүдәгәрләренә тапшырылган Алтын Урда ханнары ярлыкларын китерә алабыз.

Инде XIV гасыр ахырында, Молдавия кенәзлегенең көчәюе аркасында, Алтын Урда белән Көнбатыш илләре арасындагы сәүдәне хасил иткән юлның зур өлеше үзгә юнәлешкә – «молдав юлына» күчерелә. Молдавия кенәзлегенең географик җәһәттән уңайлы җирләргә урнашуы сәбәпле, яңа юл тиз арада сәүдәгәрләр арасында абруй казана. Кенәзлек эчендә күп санлы тикшерү һәм салым алу постлары булганга (1408 елда аларның саны унбишкә җитә), көнчыгыш кәрваннарының күпчелеге өчен Аккирмән шәһәре (бу чорда аны яңача Четатя-Алба дип атый башлыйлар) сәүдә юлының соңгы ноктасы булып тора.

Маршрут үзгәрү белән, Алтын Урда территориясеннән Көнбатыш илләренә озатылган товар исемлеге дә үзгәрә. Моннан соң бу юлдан Урда сәүдәгәрләре Көнбатышка бары тик «көнчыгыш товарлары»н гына чыгара башлый. Молдавия хакиме Александр I тарафыннан 1408 елның 8 октябрендә

«Каталония атласы»нда Бөек ефәк юлы. 1375 ел

расланган «Акчалата җыем турындагы устав» һәм 1457-1475 елларга караган Генуя-Молдавия сәүдә документларында (алар Изге Георгий банкында сакланган) китерелгән мәгълүматлар буенча, татар җирләреннән мондый товарлар кертелгән: көнчыгыш тукымалары, ефәк, камка (бизәкле ефәк тукыма), тебенко (иярне тышлау өчен махсус материал), борыч, имбирь, тимьян, ладан, грек куасы һәм лимоннар. XIV гасырда Алтын Урдадан бик күпләп чыгарылган мөгезле эре терлеккә бу чорда Аурупа илләрендә ихтыяҗ зур булмый.

Алтын Урда территориясенә исә элеккечә төрле тукымалар һәм һөнәрчелек әйберләре, моннан тыш, бик күп булмаса да, сугыш (берьяклы кордлар, кылычлар һ.б.) һәм эш (сабаннар, төрәннәр, ураклар һ.б) кораллары кайтарыла. Турыдан-туры Молдавия кенәзлегеннән Алтын Урдага, бигрәк тә Кырымга ашлык кертелә. Бу ашлык соңыннан Генуя корабларына төялеп, Византия, Трапезунд шәһәрләренә һәм, гомумән, Кара диңгез төбәге базарларына сатуга чыгарыла.

XV гасыр ахырына Алтын Урданың Польша, Литва, Молдавия сәүдәгәрләре белән элемтәләре кими. Моның берничә сәбәбе бар. Беренчедән, Аксак Тимернең 1395 елгы яулары нәтиҗәсендә зур сәүдә үзәкләре арасында бәйләнешләр өзелә. Алтын Урданың көнбатыш чигендә урнашкан шәһәр базарларыннан ерак транзит сәүдәсе товарлары («көнчыгыш товарлар») югала. Икенчедән, Алтын Урда составына кергән аерым сәүдә һәм һөнәрчелек үзәкләре икътисади бәйсезлеккә омтыла башлый. Җирле сәүдә чәчәк ата, сәяси көчләр тупланган аерым үзәкләр формалаша: Кырым, Идел буе, Төньяк Кавказ, Хәрәзем. Өченчедән, Алтын Урданың эчке сәясәтендә каршылыклар арта. Икътисади һәм сәяси бәйсезлеккә омтылган Кырым ханлыгы белән Сарай хакимияте арасындагы каршылык Җучи олысының Көнбатыш белән сәүдә урнаштыруына аеруча тискәре йогынты ясый.

Алда әйтелгәннәрне күздә тотып, без Алтын Урданың Көнбатыш илләре белән тышкы сәүдә системасында коры җир сәүдәсенең мөһим роль уйнавын, Алтын Урданың мантыйкый структурасында «татар юлы» һәм Львов шәһәренең әһәмиятле элементлар булуын гөман кыла алабыз. ■

«Сәфәр-89»

Альберт Борһанов

(Әхмәт ибне Фадлан юлыннан мең елдан соң оештырылган сәфәр турында уйланулар)

Борынгы һәм урта гасыр сәүдә-кәрван юллары буендагы археологик, тарих-архитектура һәйкәлләре фәнни даирәдә зур кызыксыну уята һәм аларны төрле илләрнең галимнәре актив өйрәнә. Евразиянең икътисади-мәдәни традицияләрен чагылдырган төбәкләрдә үткән заман һәм бүгенге көн халыкларының тормышын, гореф-гадәтләрен өйрәнү гаять мөһим. Төрки телле халыкларының этномәдәни үсеше һәм аларның башка этнос, дәүләти берләшмәләр белән бәйләнешләрендә Идел-Урал һәм Үзәк (Урта) Азиянең Арал-Сырдәрья-Әмудәрья бассейны әһәмиятле урын алып тота.

«Сәфәр-89» экспедициясендә катнашучылар

***

ЮНЕСКОның үз эшчәнлегендә һәм халыкара һуманитар проектларда Урта (Үзәк) Азия, Идел-Урал халыклары һәм төбәкләренең табигый, тарихи-мәдәни мирасын өйрәнүгә, саклауга аерым игътибар бирүе очраклы түгел. Әлеге оешманың борынгы һәм урта гасыр сәүдә-кәрван юллары буенча беренче экспедициясе белән бервакытта «Сәфәр-89» Бөтенсоюз һуманитар компексы тарихи-этнографик экспедициясе дә оештырылды. Ул 1989 елның август-октябрь айларында гарәп сәяхәтчесе Әхмәт ибне Фадлан узган юлның зур өлешен кабатлады. Экспедициянең маршруты: Болгар – Казан – Әстерхан – Махачкала – Бакы – Красноводск – Мадау – Ашхабад – Серахс – Мары – Чәрҗәү (Төрекмәнабат) – Боха-

Турахан төрбәсе. Башкортстанның көнбатышы

Сәүдә юлындагы кәрваннар

«Дая-хатын» кәрвансарае

ра – Әмударьяның сул яры буенча көньякка – Көнә – Үргәнеч – Бәйнау – Җаек – Куйбышев (Самара) – Болгар – Казан. «Сәфәр-89» экспедициясе Болгар-Казаннан 2 августта кузгалып, Татарстанга 5 октябрьдә әйләнеп кайтты. Аны Ленинград (Санкт-Петербург) шәһәрендәге «Үсеш» инновация фонды, Һуманитар экспедицияләр проекты кысаларында, Казан һәм Нева буе калаларының югары уку йортлары һәм академик институтлары голәмәсе, Татарстан Диния нәзарәте һәм Мәрҗани мәчетенең имамы катнашы һәм ярдәме белән гамәлгә ашырды. Казан, Чаллы, Түбән Кама һәм Ленинградның эре сәнәгать оешмалары иганәче булып, матди ярдәм күрсәтте, җиһазлар һәм автотранспорт («КамАЗ» автомобильләре) белән тәэмин итте. Экспедициягә ул вакытта әле яшь сәяхәтче, хәзер инде танылган галим, тарихчы Александр Юрченко җитәкчелек итте. Ул экспедициягә Ленинград, Казан, Уфа, Чабаксар һәм Ашхабад шәһәрләренең 19 яшь галимен, этнограф һәм археологларын, гарәп теле белгечен, Мәрҗани мәчетенең имам-хатибын, «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар компаниясенең «Кадр» кино төшерү төркемен, фотограф һәм ике шоферны җәлеп итте.

«Сәфәр-89»экспедициясендә катнашучыларның игътибар үзәгендә дөнья халыкларының үзара элемтәсе тарихы, борынгы һәм урта гасырлардагы Шәрык һәм Көнбатыш илләрендә яшәүче этник төркемнәрнең мәдәни казанышлары, гореф-гадәтләре һәм традицияләре, кешеләр һәм мал-мөлкәт хәрәкәте булды. Бүгенге галимнәрнең борынгы маршрут буенча фәнни сәяхәте хәзерге Евразиядә яшәүчеләрнең тормышын күрү һәм ерак бабаларыныкы белән чагыштыру мөмкинлеген бирә.

2016-2017 елларда хәлиф Җәгъфәр әл-Мөктәдир илчеләренең 921-922 елларда Багдад хәлифәте башкаласыннан, Иран һәм Урта Азия аша, Идел буе Болгарына сәяхәтенә 1095 ел тула. Ул вакытларда, X гасырда Мәверәннәһер һәм Хөрәсән белән Идел буе Болгар дәүләте арасындагы сәүдә әйләнеше куәтле була. Дипломатик, дини-мәдәни һәм сәяси бурычларны үтәүче «тынычлык кәрваны»ның җитәкчесе Ибне Фадлан Урта Азияне Көнчыгыш Европа белән тоташтырган юлны җентекле тасвир-

Экспедициядә катнашучылар Мадау авылында. Төрекмәнстанның көньяк-көнчыгышы. 1989 ел

Навидах шәһәрлеген өйрәнү. Төрекмәнстанның көнчыгышы

лый. Элегрәк юл Багдадтан һәм Ираннан Идел буе Болгарына Кавказ арты һәм Хәзәр каганлыгы аша үткән була. Әмма X гасыр башында, хәлиф Җәгъфәр әл-Мөктәдир идарә иткәндә, Багдад хәлифәте белән Хәзәр каганлыгы арасындагы мөнәсәбәтләр кискен начарлана һәм сәүдә юлы Мәверәннәһергә күчә. Ибне Фадлан хәбәр итүенчә, кәрваннар Бохарадан Җәйхунга (Әмудәрьяга) бара, аннан елга буеннан Кәт каласына – Көньяк Хәрәзем үзәгенә, алга таба Җүрҗәниягә (Гөргәнҗәгә), шуннан соң Эмба аша Болгар патшалыгына юл тота.

Шулай итеп, сәүдә юлы Хәзәр каһанлыгын әйләнеп узып, Әтилнең (Итилнең) сул ярыннан бара. Юл буенда күпсанлы кәрвансарайлар төзелә, аларның хәрабәләре безнең көннәргәчә сакланган.

Әхмәд ибне Фадлан юлыннан мең елдан соң оештырылган «Сәфәр-89» экспедициясендә катнашучылар алдында мондый бурычлар торды:

– Урта Азиядән Көнчыгыш Европага сузылган сәүдә-кәрван юлындагы археологик һәм тарих-архитектура һәйкәлләрен өйрәнү;

– шул җирләрдәге этник төркемнәрне этнографик тикшерү;

– Әхмәд ибне Фадлан сәяхәтен аның язмалары буенча модельләштерү һәм ул үткән юлның бер өлешен яңадан торгызырга омтылу;

– милләтара бәйләнешләрне, төрле илләрнең фәнни үзәкләре, югары уку йортлары галимнәре арасындагы фәнни элемтәләрне ныгыту.

«Сәфәр-89» проекты программасы табигый һәм тарихи-мәдәни зоналарга бәйле рәвештә 3 этаптагы тикшеренүләрне үз эченә алды. Бу Үзәк (Урта) Азиядәге сугарулы игенчелек, Казакъстанның дала һәм Идел буеның урман-дала зоналары. Әлеге өч төбәкнең һәркайсында гаилә-көнкүреш тәртипләре, ирләр һәм хатын-кыз хезмәте, халык бәйрәмнәрен оештыруның үзенчәлекләре бай тарихка ия һәм алар бүгенге көннәргәчә сакланган.

«Сәфәр-89» экспедициясе шушы мәсьәләләрне хәл итә алды:

1. 921-922 елларда Багдадтан Болгарга килгән гарәп илчеләре узган юлның зур өлеше кабат үтелде.

Альберт Борһанов Урта Азиядә

2. Фәнни һәм фәнни-популяр, шул исәптән тарихи-этнографик сюжетларга да корылган фильмнар төшерде.

3. Төрекмән, үзбәк, каракалпак, бәлүҗи, фарсы, казакъ, калмык, Дагыстан халыкларының, азәрбәйҗан, рус, казакъ, татар, башкорт, Урта Азия, Казакъстан һәм Идел-Урал төбәгендәге башка халыкларның традицион һәм бүгенге мәдәнияте буенча фәнни мәгълүмат җыйды.

4. «Ибне Фадлан энциклопедиясе» өчен берникадәр материал туплады, ә соңрак экспедициянең кайбер әгъзалары Урта Азия һәм Идел буе халыкларының традицион һәм заманча этикеты турында фәнни хезмәтләр яза башлады.

5. Төрле республика башкалаларындагы, өлкә һәм район үзәкләрендәге хакимият ярдәмендә фәнни җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән очрашулар уздырды.

6. Ислам тарихы, төрки-мөселман халыкларының традицион һәм заманча мәдәниятенең төрле мәсьәләләре буенча лекцияләр, очрашулар үткәреп, агарту эшләре алып барды.

Экспедиция юлының иң нәтиҗәле һәм озын өлеше Урта Азиядә, аерым алганда Төрекмәнстанда булды. «Сәфәр-89» анда 7-25 сентябрь көннәрендә эшләде. Монда «Нусай», «Борынгы Мерв», «Көнә-Үргәнеч» дәүләт тарихи-мәдәни тыюлыклары, Мисриан, Анау, Меаны, Серахс, Даяхатын тарихи-мәдәни комплекслары объектларында, шулай ук Абиверд-Пештак, Амул, Чәрҗәү, Дарган-Кала шәһәрлекләрендә фәнни-тикшеренү эшләре башкарылды һәм фильмнар төшерелде. 1991-1994 елларда аларның күбесе музей-тыюлыклар булып эшләп китте һәм бүгенге көндә дә реставрация-консервация эшләре дәвам итә.

«Сәфәр-89» экспедициясенең эше тәмамлангач, мин Урта Әмударья, Хәрәзем һәм Төрекмәнстанның көньягында археологик тикшеренүләр үткәрә башладым. Әлеге хезмәтемнең нәтиҗәләре буенча халыкара һәм төбәк конференцияләре үткәрелде, мәкаләләр, монографияләр басылды. 1992 елда М.В.Ломоносов исемендәге МДУның археология кафедрасында «Борынгы һәм урта гасырлар башында Амул өлкәсе» дигән темага кандидатлык диссертациясен якладым.

Йомгак ясап, җентекләбрәк әзерләнеп һәм галим-голамә, энтузиастларны җәлеп итеп, Әхмәд ибне Фадлан юлыннан, Багдад – Хамадан – Мәшхәд – Серахс – Мерв – Амул – Бохара – Көнә – Үргәнеч – Бәйнәү – Болгар маршруты буенча, яңа комплекслы экспедиция үткәрү кирәклеге турындагы фикерне белдерәсем килә. Ул ЮНЕСКО, ИРСИКО, ТӨРЕКСОЙ теләктәшлегендә, экспедиция юлындагы илләр ярдәме белән үтәргә тиеш. Безнең карашыбызча, гыйльми сәфәргә халыкара һәм һуманитар статус бирергә, аны гарәп илчелегенең 922 елда Идел буе Болгарына килүенә һәм Идел-Урал төбәгендә ислам диненең рәсми рәвештә кабул ителүенә 1100 ел тулу уңаеннан 2022 елда уздырырга кирәк. ■

ТАТАР КИТАБЫ

Литва татарлары кулъязмасы

Галина Мишкинене

(Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә яңа табылган хамаил)

Ошбу елның 14-15 июлендә Казан шәһәрендә һәм Саба районында Ә.Г.Кәримуллин истәлегенә багышланган укулар оештырылды. Игътибарыгызга Литва теле институты галимәсе, гуманитар фәннәр докторы Галина Антоновна Мишкиненең литва татарлары кулъязмасына багышланган докладын кыскартып тәкъдим итәбез.

Литва татарларында XVI гасырда гарәби язулы славян телле кулъязмалар барлыкка килү туган телне оныту сәбәпле булган. Фәнни әдәбиятта Бөек Литва кенәзлегенең мөселман кулъязмаларында дүрт әдәби тел булуы искәртелә. Бу хәрәзем, чагатай, иске госманлы һәм кырым-татар әдәби телләре. Гарәп телен белмәү һәм тора-бара татар телен дә оныту дини әдәбиятны (иске) белорус, ә соңрак (иске) поляк теленә тәрҗемә итүгә этәргән. Шулай итеп, литва татарларында гарәп язуындагы иске славян телле кулъязма китап традициясе барлыкка килә.

Литва татарларының традицион дини әдәбияты гаять бай. Алар арасындагы XVII-XX гасырларга нисбәтле китаплар, китапчыклар, хамаил-догалыклар, тәҗвид һәм тәфсирләр Бөек Литва кенәзлеге мөселманнарының төп дини-әдәби әсәрләре булып тора.

Бу кулъязма мирас Литва, Белоруссия һәм шулай ук дөньяның башка китапханәләрендә саклана. Литва, Белоруссия һәм Польшаның дәүләт фондсаклагычларында һәм шәхси тупланмалардагы кулъязмалар 1997-2015 елларда басылган алты каталогта җентекләп тасвирланды. Кулъязмаларның тасвирламалары буенча, аларның палеографик үзенчәлекләрен, эчтәлеген генә түгел, ә нинди мәдәни тирәлектә иҗат ителгәнлеген, тарихын да белергә мөмкин.

Казанда исә литва татарларының кулъязма мирасы КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә һәм ТР Милли китапханәсендә саклана. Казан университетында литвалыларның гарәп язулы өч кулъязмасы

бар: 1645 елгы китап һәм ике хамаил. XIX гасырга нисбәтле тагын ике хамаил Милли китапханәнең хәзинәсе. Шуларның берсен Казан шәһәрендә яшәүче Фирдәвес Арыслангали кызы Кушаева 2015 елның башында китапханәгә тапшырганлыгы турында безгә Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире Айрат Заһидуллин хәбәр итте.

Хамаил – гарәп һәм төрки телләрдәге догалар җыентыгы, шулай ук анда мөселман дөньясына бәйле хронология, авыруларны дога белән дәвалау, өшкерү, төшләрне юрау турында да мәгълүмат бар. Әмма, хамаил эчендәге текстлар, аны яздыручының, күчереп язучының яки төзүченең мәнфәгатьләреннән чыгып тупланган. Эчтәлеге буенча хамаилләрне өч төркемгә бүләргә мөмкин: 1) мулла хамаилләре – имамнар өчен язылган, эчтәлеге нигездә догалардан һәм йолаларга аңлатма бирүдән гыйбарәт; 2) фаллар, багучы, им-томчылар өчен язылган магик кагыйдәләр, йолдызнамә һәм төшлекләр; 3) катнаш типтагылар. Казан университеты китапханәсендәге Ибраһим Смольский (1775), Сәфәр Кәбиров күчергән хамаилне һәм Милли китапханәдәге XIX гасыр уртасында язылган кулъязманы беренче типка – «мулла хамаиле»нә кертергә була. Безнең тарафтан тасвирланган хамаил исә өченче типка якын, чөнки анда, догалар белән бергә, гореф-гадәт турындагы язмалар, астрологик, хронологик текстлар һәм төшлек бар. Ә хәзер бу китапка җентекләбрәк тукталыйк.

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә Фирдәвес Кушаева тапшырган кулъязманың 1888 елда Адам Разецкий тарафыннан күчерелгәне (*14-15, 175-183* битләрен башка кеше язган) ачыкланды. Гарәп, белорус, поляк һәм төрки телләрдә язылган китапның күләме – 189 бит, форматы – 16,1x10 см. Кулъязма, вакыт узу белән битләре саргайган булуга карамастан, яхшы сакланган, язуы да җиңел укыла. Һәр яңа тема, башка татар китапларындагы кебек үк, «баб» (бүлек) сүзе белән башланып китә. Кулъязма китап Фирдәвес ханымга әнисенең бертуган абыйсыннан мирас булып калган.

Китапның эчтәлегенә күз салыйк. Әгәр дә аның сәхифәләрен тәртип белән актарабыз икән, шушы «баб»ларны күрәбез: укылмый калган намазлар өчен өстәмә дога; зиратта кылына торган дога; кабер янында укыла торган дога; кабер яныннан узып барганда укыла торган дога; мәчеттә укыла торган догалар; ниятләр; тәкбир; госел кылу тәртибе; тәһарәт; азан нияте; сөннәтнең нияте; сөннәттән соң кылына торган дога; камәт нияте; фарызга ният; тәсбих; иртәнге намазга догалар; зикер һәм аять; сәҗдәгә ният; тәсбих; кичке намаз; «Кадех» догасы; тәүбә догасы; җәннәт ачкычын вәгъдә итә торган дога; хәреф догасы; пәйгамбәр (с.г.в.) мөһере; һәр намаздан соң кылына торган дога; бу ай, ягъни Рамазан аеның беренче һәм соңгы көннәрендә укыла торган дога; җомга догасы; иртәнге намаздан соң һәм теләсә кайсы вакытта укыла торган дога; күз тиюдән һәм бозымнардан саклану догасы; тәхлил догасы; бәйрәм намазы; Корбан бәйрәме; җомга намазына ният; календарь; ярдәм сорап дога кылу; «Йәсин» сүрәсенә ният һ.б.

Хәзерге вакытка кадәр Россия Федерациясе китапханәләрендә Бөек Литва кенәзлеге белән бәйле 11 татар кулъязмасы бар иде. Шулай итеп, Казанда саклаучы 1888 елгы кулъязманы да исәпкә алсак, литва татарларының Россиядәге язма мирасы тагын бергә артты.

Игътибарыгызга әлеге дини-мәдәни мирасның *163-169* битләреннән төш юрау турындагы «баб»ның татарчага тәрҗемәсен тәкъдим итәбез. Аның транслитерациясе, ягъни гарәп хәрефеннән поляк хәрефенә күчерелмәсе һәм урыс теленә тәрҗемәсе белән *beznenmiras.ru* сайтыннан таныша аласыз.

(163б) ***Күргән төшләрне юрау бабы.*** *Гыйззәтле Габдулла[1] әйтте, кем дә кем төшендә елый, иншаллаһ, яхшы булачак. Әгәр дә атка утырса, теләкләре чынга ашачак. Әгәр дә пошига утырса (164а), файдага булачак. Әгәр дә ишәккә утырса, кайгы-хәсрәткә төшәчәк. Әгәр дә кеше җилкәсенә утырса, хуҗа булачак. Әгәр дә кулында чукмар яки түтә булса, ир бала туачак. Әгәр дә чукмарны үзе белән йөртсә, теләге чынга ашачак. Әгәр кояш баеганны күрсә, хәерчелек бетәчәк. Әгәр дә атын кулында тотса, хөрмәткә (164б) лаек булачак. Әгәр дә корабта йөзсә яки әйләнеп капланса, кунаклары качып бетәчәк. Әгәр дә диңгезгә чыкса, фәнгә тартылачак. Әгәр төшендә очса, котылу булачак. Әгәр дә төшендә су эчсә, хуҗа булачак. Әгәр дә суны чишмәдән эчсә, яхшы булачак. Әгәр дә төшендә кыз тудырса, кайгы-хәсрәткә төшәчәк. (165а) Әгәр ир бала тудырса, шатланачак. Әгәр дә кулы имгәнсә, начар булачак. Әгәр аягы имгәнсә, гомере озын булачак. Әгәр дә төшендә теле киселсә, хөрмәткә лаек булачак. Әгәр дә киселгән бармаклар күрсә, файдага булачак. Әгәр дә намаз укыса, теләге кабул булачак. Әгәр дә кем дә кем төшендә сукса, (165б) яхшыга булачак. Әгәр дә берәү төшендә ук күрсә, хәбәр киләчәк. Әгәр дә төшендә кемдер нәрсәнедер тартып алса, Алла сакласын, зарар китерәчәк. Әгәр дә төшендә кешегә күктән нәрсәдер төшсә, Алланың рәхмәте белән, авырулар бетәчәк. Әгәр дә төшендә юл күрсә, гайбәт сүз бетәчәк. Әгәр дә төшендә хатын-кыз тырнагы күрсә, кулдан нәрсәдер төшеп китәчәк (166а). Әгәр дә төшендә улын күрсә, файдага булачак. Әгәр дә төшендә кулына яңгыр яуганны күрсә, ә кулы коры булса, авырулар китәчәк. Әгәр төшендә җир казыса, файдага булачак. Әгәр дә төшендә Кәгъбәтуллага барса, гомере озын булачак. Әгәр төшендә кишер казыса, бу улы булачагын аңлата. Әгәр дә төшендә тимер тотса, (166б) яхшы кешеләр арасында аның сүзе мөһим булачак. Әгәр дә төшендә кулына көмеш тотса, яхшы булачак. Әгәр дә төшендә яхшы кием кисә, файдага булачак. Әгәр начар кием кисә, чир киләчәк. Әгәр дә төшендә сикерсә, яхшы булачак. Әгәр дә төшендә башына калфак кисә, сәламәт булачак. Әгәр дә төшендә иярга (167а) сикереп менсә, казый булачак. Әгәр дә төшендә ияр күреп, башканыкына утырса, файдага булачак. Әгәр дә төшендә кадаклар күрсә, файдага булачак. Әгәр дә төшендә чәчен алдырса, кайгы-хәсрәткә. Әгәр дә төшендә казый күрсә, авырулар китәчәк. Әгәр дә төшендә (167б) имам яки мөәзинне яки нинди булса галим мулланы күрсә, яхшы кешеләр арасында кадер һәм хөрмәттә булачак. Әгәр дә төшендә табиб күрсә һәм ул өйгә дә керсә, Алла сакласын, авыру булачак. Әгәр дә үзен-үзе чирле күрсә, Алла ярдәме белән савыгачак. Әгәр (168а) төшендә карт кешене күрсә, файдага булачак. Әгәр карт хатын-кызны күрсә, гомере озын булачак. Әгәр төшендә рыцарь күрсә, кайгы-хәсрәткә булачак. Әгәр кечкенә малайларны күрсә, яхшы хәбәр алачак. Әгәр төшендә музыка яки ниндидер туй күрсә, кайгырачак. Әгәр (168б) төшендә дөя яки бәрән, яисә куян күрсә, гомере озын була. Әгәр дә төшендә үзен кемнең дә булса крепостное итеп күрсә, Аллаһы Тәгалә аны бәйлелектән коткарачак. Әгәр дә төшендә үзен хәерче итеп күрсә, Аллаһы Тәгалә үзенең рәхим-шәфкате белән аны баетачак. Әгәр (169а) төштә үзен чирле итеп күрсә, сәдака бирергә кирәк, үтәчәк, тиз үләчәк. Әгәр төшендә печкән үгез яки сыер сөте, яисә сыр күрсә, бик тә бай булачак. Әгәр төшендә каләм яки язу карасы күрсә һәм ул кара түгел, ә кызыл төстә икән, яхшы булмаячак. Әгәр төшендә чәнечке күрсә, югарыга күтәреләчәк һәм яхшы (169б) хатынга өйләнәчәк. Әгәр дә хатлар һәм язма күрсә, бер яхшы хәбәргә шатланачак. Әгәр язу карасы күрсәң, эш белән бергә кулыңда мал-мөлкәт тә булачак. Бу төшләрдән соң дога укы, Аллаһы Тәгалә барысын да яхшы итәчәк.* ■

[1] Габдулла бине Габбас (619-686) – Мөхәммәт (с.г.в.) пәйгамбәрнең туганнан-туганы.

Метрикада – татарның үткәне

Эльмира Сәлахова

Тарих сәхифәләрен актарганда, халыкның үткәнен өйрәнгәндә галимнәр, тикшеренүчеләр төрле чыганакларга мөрәҗәгать итә. Һәрберебезнең нәсел тарихын саклап калып, безнең көнгә кадәр китереп җиткергән бәһасез, алтынга тиң кыйммәтле документларыбыз бар. Алар – метрика язмалары.

Бу документ мәчеттә мулла тарафыннан тутырыла, анда билгеле бер мәхәлләдә туган, вафат булган кешеләр, укылган никах, талаклар теркәлә. Бер караганда, мондый документлар мәгълүматны кабул ителгән кысалар буенча кыска, төгәл итеп бирә, икенче яктан исә тарихны тулы, комплексны өйрәнгәндә алар ярдәмендә шул чорның картинасын тулы итеп чагылдыру мөмкинлеге бар. Метрика язмалары рәсми документ булганлыктан, аларда субъективизмга, нинди дер эмоциональлеккә урын юк. Менә шул яклары белән дә алар тарих өчен кыйммәтле чыганак.

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк, дигән затлы мәкаль бар. Бабаларыбыз җиде, ә бәлки аннан да күбрәк буын тарихны белгән, бу беркем өчен дә гайре табигый нәрсә булмаган. Хәзерге вакытта, кызганыч ки, буыннар арасында элемтә какшый барган заманда, метрика язмалары аларны торгызучы бер көч була ала.

Мондый кенәгәнең иң беренче сәхифәсенә кеше гомеренең иң тәүге һәм зур вакыйгасы – туу турындагы мәгълүмат языла. Беренчедән, мөселманча күркәм исем кую таләп ителсә, икенчедән, ул исемне дөрес итеп төгәл язу шарты куела. Балага исем куштыру, аны теркәү мәшәкате гаилә башлыгына – әти кешегә йөкләнә, төрле сәбәпләр аркасында, баланың атасы моны башкара алмаса, бу вазифаны бабасы башкарырга бурычлы. Исем куштыру артыннан йөргән кеше мулла кушкан һәм теркәгән исемне укып, дөреслегенә инанып, имза куярга тиеш. XIX йөзнең икенче яртысы-XX йөз башы метрика язмаларындагы исемнәргә игътибар итсәк, аларның, нигездә, гарәп теленнән кергәнлеге, сирәк кенә булса да, кайбер төбәкләрдә бик матур, борынгы төрки исемнәрнең дә кулланышта булуы күренә.

Баланың исеме һәм туган көне белән бергә, аның әти-әнисенең, ике як бабасының исеме языла, ә фамилия күрсәтү мәҗбүри саналмый. Рәсми эшләр өчен фамилия таләп ителгәндә, татарда бабай кешенең исеме фамилия ролен үтәгән. Шуңа да бер гаилә кешеләрен урыс телле рәсми документларда төрле фамилия белән очратырга мөмкин.

Никахның кеше тормышында җитди адымнарның берсе булуын метрикадагы язмалар да дәлилләп тора. Бу гамәл берничә шаһит катнашында башкарылган. Иң төп шаһит һәм бу эшнең җитәкчеләре – ике якның да этиләре – алар вәли вәкил дип аталган. Кайбер очракта мондый вазифаны кияү белән кәләшнең бертуганнары да үтәгән. Егет үзенә үзе дә вәли вәкил була алган, ләкин кызның үз-үзенә вәли вәкил булуы гадәттән тыш сирәк хәл, бу бары тик 1917 елдан соң гына күренгәли башлый. Икенче төр шаһитлар – ризалык шаһитлары, һәр ике яктан да, нигездә икешәр, ә кайбер очракта дүртәр шаһит билгеләнгән – болар туганнар, күршетирә яисә мәҗлестә булучы танышбелешләр. Шаһитларның саны күп булу


برنچی « نصل » ۱۹۰۳ نچی یلده دنیاغه کیلگان بالالرنی یازار ایچون

ایر	قز	بالانک اسمی	قایو آیده توغان آینک نیچه‌نچی کونی	بالانک آتا آناسینک هم هر ایکی طرفده اولان باباسینک اسمی اگرده بولسه فامیلیه‌سی قایو طائفه‌دن ایدکی	قایده توغان

1903 елда Яңа бистәдә дөньяга килгән балаларны теркәү бите. Мисал өчен, 6 нчы номердагы (иң өстә) ир бала: «Мөхәммәдсадыйк. 2 нче февральдә (туган). Атасы – Казан өязе Кукмара волосте Уразлы авылының крестьяны Мөхәммәдсәгый Мөхәммәдкәрим углы. Анасы – Маһикямал Габдесаттар кызы. Дөрес язылган, диеп, атасы Мөхәммәдсәгый Мөхәммәдкәрим углы» раслаган. Әлеге метрика Фатих Әмирханның әтисе, Таш мәчет мәхәлләсе имамы Зарифулла Әмирхани тарафыннан язылган. ТР МА. 204 ф. 180 тасв. 13 эш.

– үзе үк бу гамәлнең җитдилегенә ишарә. Татар халкында гаилә кору зур адым саналганлыктан, егет белән кызның якын туганнары шаһитлыгыннан башка, бер генә никах та теркәлмәгән. Никахны яшерен рәвештә уку мулланың указы алынуга сәбәп була алган. Шуңа да, никах өчен нинди генә киртәләр чыкмасын, ике як уртак бер фикергә килеп, мәсьәләне уңай хәл итәргә тырышкан. Шаһитлар никахның законлы булуын раслап, аның дөреслеге хакында үз өсләренә җаваплылык алып, имза яисә тамга куйган.

Никахны егетләргә 18 яшьтән, кызларга исә 16 яшьтән уку мөмкин булган, ә 80 яшьтән узган кешеләргә никахны рәсмиләштерү рөхсәт ителмәгән. Беренчедән, никахны теркәү өчен яшь хакында белешмә , икенчедән, шаһитлар кирәк булган, никахка керүчеләрнең икесенең дә мөселманлыгы шарт итеп

куелган. Әдәби әсәрләрдә еш кына татар кызының бик иртә кияүгә бирелүе хакында язылса, ләкин бу факт документаль яктан һич кенә дә расланмый. Никах 16 яшьтән рөхсәт ителгән булуга да карамастан, бу яшьтә никахка керү хакындагы язма безгә мәгълүм булган документларда очрамады, никахлашу яше, иң иртә дигәндә, 17 яшь.

Никах мәҗлесендә ир кеше булачак хатынына мәһәр биргән. Мәһәрнең күләме чынлап та әйтелгәнчә булуын һәм аның бирелүен раслап шаһитлар кул куя яисә үзләренең тамгаларын сала. Гадәттә, мәһәр малы ике өлештән торган: берсе никах укыган вакытта тапшырылган, ә икенче өлеше «көтәчәк мал» дип аталган. «Көтәчәк мәһәр хатынның ир өстендәге бурычы булып, бер тараф үлгәндә, яхуд аерылышканда ул мәһәр хатын файдасына буладыр. Авылларда мәһәр итеп ат, сыер, түшәк, ястык һ.б. шундый нәрсәләр язылса, аның кыйммәте язылып бәян ителергә тиеш. Ат, сыер төсе белән язылса, яхшы булыр», – диелә Диния нәзарәте таләбендә. Мәһәр күләме өйләнүче кешенең байлыгына карап төрлечә булган, ләкин малны иркен тотарга тырышканнар. Шул заманның иң зур малыннан берсе – сыер бирү дә сирәк хәл түгел. Татардагы мәһәр – калым түгел, ягъни эти кеше кызын бу мал бәрабәренә үлчәп бирми. Никахта тәкъдим ителгән мал – яңа туган гаилә малы, моны үзенә күрә, хатын-кызны көтелмәгән, күңелсез (мәсәлән, аерылышу булган очракта) хәлләрдән саклаучы бер социаль страховка формасында кабул итәргә кирәк.

Аерылышу эшләре, нигездә, ир кеше һәм хатынның атасы арасында алып барыла, ә хатын исә бу хәлләргә турыдан-туры катнашмый, ләкин әлеге факт һич кенә дә хатын-кызның хокуксыз булуын аңлатмый. Ислам тәртипләре буенча, ана булган яисә киләчәктә ана буласы хатын-кызлар һәртөрле күңелсез хәлләрдән, стресслардан мөмкин кадәр сакланган. Шуңа да, аерылышу очрагында хатын-кызның барлык таләпләре әтисе аша җиткерелгән һәм ул һәрвакыт үзенә тиешлесен ала алган. Бу процесс та гаять җитди булганлыктан, гамәлнең кануни яктан дөреслеген, аның гадел үткәрелүен шаһитлар раслаган. Шунысын да билгеләү артык булмас, XIX йөзнең икенче яртысы-XX йөз башында талак – бик сирәк күренеш, булган кадәренең дә төгәл сәбәбен билгеләү авыр, чөнки татар кешесе күңел халәтен читләргә белдерергә ашкынып тормый. Күп очракта «арада мәхәббәт юклык сәбәпле» яисә «мәхәббәт вә өлфәт юклык сәбәпле» дип языла, ләкин Диния нәзарәте фикеренчә, нәкъ менә шушы сүзләр астында мөһимен яшереп калдыралар, аерылышуга китергән сәбәпләрне төгәл ачыкларга тырышу кирәк, диелә. Бер документта аерылышу сәбәбе дигән графага мулла: «Хатын бик озак елады, ләкин сәбәбен әйтмәде», – дип язып куйган.

Соңгы сәхифә буларак фани дөньядан бакый дөньяга күчүчеләр исемлеге бирелә. Кешенең исемен, вафат булу көнен, яшен һәм сәбәбен күрсәткән исемлек татар тормышы хакында шактый мәгълүмат бирә ала. Бу исемлектә мәрхүмнең һәм аның әтисенең исеме күрсәтелә, шулай да, Диния нәзарәте таләбе буенча, вафат булган хатын-кызның, кем кызы булуы белән бергә, кем хатыны икәнлеге дә теркәлгән.

Бу сәхифәдә игътибар итәрлек нәрсәләрнең тагын берсе – ул дөньядан китү сәбәпләре. Вафат булучылар арасында кече яшьтәге балаларның саны күп булуы күренә, алар төрле йогышлы авырулардан бакый дөньяга күчкән, нишләптер, мондый чирләр күбрәк ир балаларга янаган. Фани дөнья белән иртә хушлашучылар рәтендә яшь хатын-кызлар да аз түгел, аларны бала тудыру вакытында килеп туган көтелмәгән хәлләрдән алып чыгарлык медицина ярдәме булмау якты дөньядан алып киткән. Яшь һәм урта яшьтәге ирләрне еш кына тормыш авырлыклары харап

иткән: «тегермән ташына эләгеп вафат», «суга батып» һ.б. сәбәпләр бар. Мөселман метрика язмаларында үзүзенә кул салу нәтиҗәсендә дөньядан китү очраклары теркәлмәгән, шулай ук «үтерелгән» дигән сәбәп тә очрамый. 1920-1921 елларда фани дөньядан бакый дөньяга күчү сәбәпләре инде, әлбәттә, ил өстенә ябырылган коточкыч ачлык.

Бу язмалар аша XIX йөзнең икенче яртысы-XX йөз башында татар җәмгыятенең гомер озынлыгы турында да сүз алып барып була. Илле биш, алтмыш яшьлекләрнең вафат булу сәбәбен күрсәткәндә «картлыктан» дип язу үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Туксанга, йөзгә җитеп вафат булучылар да очрый, ләкин аларның саны бик аз.

Метрика язмалары нигезендә гаилә генә түгел, ә гомумән, шул чор татар җәмгыятен дә күзалларга мөмкин. Беренче карашка, бу төр документлар коры гына фактларны тәкъдим иткән кебек булса да, алар, чынлыкта исә, татар кешесенең дөньяга аваз салуыннан башлап, соңгы сулышына кадәрге тормышын сөйли. Метрика язмаларына таянып шәҗәрә төзегәндә, бик кызык күренеш ачыклана: ир кешенең нәсел тамыры өзелгән икән, аның рекрутлыкка алынып, нәсел дәвам итәргә сәләтсез булып әйләнеп кайтканлыгы ачыклана, сирәк очракта гына солдат хезмәтендә булган кешенең нәсел җебе өзелми кала.

Татар җәмгыятенең тагын бер үзенчәлеге: татар кешесе нәселен үз туган авылында гына дәвам иткән, чит авыллларга күчеп яшәү яисә хатын авылында төпләнү бөтенләй юк, бары тик муллалар гына, указ белән башка авылга, хәтта чит өяз һәм губерналарга да билгеләнеп, гомерен туган авылыннан еракта үткәрергә мөмкин. Бу яктан, метрика язмалары имамнарның тормыш юлын ачыкларга да мөмкинлек бирә. Биредә метриканы тутыручы мулла, мөәзиннәрнең исеме теркәлә, аларның туу вакыты, урыны, белем алган уку йорты яисә остазы күрсәтелә.

Метрика язмалары татар тарихында тирәнтен өйрәнүне таләп иткән сословие-катлам проблемасын да күзәтергә мөмкинлек бирә. Сабыйның исемен язганда сословиесен күрсәтү таләп ителмәгән, ләкин, шулай булса да, муллалар барлык документларда да диярлек бу мәгълүматны язып барган. Иң еш очраганнары: «игенче», «зирәгатьче», «крестьян», «башкорт», «типтәр», «ясаклы». Ничек кенә сәер тоелмасын, Самара губернасының Бөгелмә өязенә кергән Мөәмин-Каратайда, «крестьян», «ясаклы» белән беррәттән, кайбер кешеләр «христиан» дип языла һәм шунысы шаккаттыра: бу һич кенә дә хата булырга охшамаган, чөнки шул ук сүз төрле елларда башка муллалар тарафыннан да теркәлгән.

Туу турындагы документларда тагын кайбер кызыклы гына нәрсәләр очрый: Казан өязе Яңа Кенәр авылында баланың әтисе «крестьян Камалетдин Гайшә улы» дип бирелә. Мөгаен, моның сәбәбен Гайнетдин Әхмәревнең «Мәкрүһләр хәленнән» дигән мәкаләсендә сөйләнгән вакыйга белән аңлатырга мөмкиндер: яңадан исламга кайтучылар, никахларын законлы рәвештә терки алмау аркасында, балаларын үз исемнәренә яздыра алмыйча, хатын исеменә яздырырга мәҗбүр булганнардыр. Яисә татар җәмгыятендә бик сирәк кенә очраган вакыйга – әтисенең мәгълүм булмавымы? Әлегә монын сәбәбен кистереп кенә әйтү авыр.

Бары тик Казан шәһәре метрикаларында гына очраган бер күренеш, ул – кыз балага Мария исеменең бирелүе (Атасы Әхмәд Бәдретдин улы Апанаев). Моның сәбәбе XX йөз башында татарның урыс җәмгыяте белән якынлашырга тырышуымы, әллә башкадамы?..

Югарыда куелган сораулар, бер карашка гади, әллә ни игътибар итәрлек түгел кебек тоелса да, аларның төбендә мөһим проблема ята. Болар татар тарихының әле өйрәнелмәгән, әмма һичшиксез тикшерелергә тиешле юнәлешләренең бик күп булуына ишарә ясый. ■

Уңышлы башламнар*

Лирон Хәмидуллин

Татарча «Татарстан» журналы чыга башлаган вакытларда, 1990 нчы еллар башында, милли рухта тәрбияләнгән баш мөхәррирләр Дамир Шәрәфетдинов һәм Рафаэль Мостафиннар, бүлек мөхәррирләре Тәүфыйк Әйди, Солтан Шәмси һәм Рәис Даутовлар эшләгән чорда милләтнең тарихи мирасын барлау юнәлешендә шактый гына уңышка ирешелде. Ләкин журнал өчен ул чор бик кыска гомерле булды.

[1] Ахыры. Башы журналның 2016 елгы 11 нче санында.

Бу журнал СССР таркалгач, Мәскәү тарафыннан күзәтүчәнлек йомшый төшкәч борын төрткән беренче шундый тарихи басма булгандыр, мөгаен. Ләкин элгәреләренә алмашка килгән мөхәррирләр ул мәҗмуганы тиз арада заман буржуйлары күңеленә якынрак тоелган эзгә борып җибәрделәр. Шома, ялтыравык кәгазь битләрендә замана байларының биографиясен язуга, фотосурәтләрен урнаштыруга өстенлек бирә башладылар. Андый язмалар да кирәк, әлбәттә. Үзе сайлаган эштә зур уңышка ирешкән шәхесләр турында язу бик кирәк. Ләкин ул еллардагы «Татарстан» мәҗмугасы халкыбыз мирасына кагылышлы язмаларга бөтенләй әһәмият бирми башлаган иде шул.

Әлеге хатаны сизгән кебек, тиздән әдәби, иҗтимагый, тарихи юнәлештәге мирасны барлауга йөз тоткан махсус «Мирас» мәҗмугасы калкып чыкты. Ике гасыр чиген берләштергән еллар дәвамында ул журнал битләрендә онытылып баручы байтак кына язма җәүһәрләребезгә икенче җан өрелде. Әлеге журнал эшчәнлеген әйдәп баручы галимнәр Флүн Мусин һәм Һәнүз Мәхмүдевләр, язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм Фирдәвес Зарифлар булып, мәҗмуганың эчтәлеген баетуга үз өлешләрен кертүчеләр арасында да абруйлы галимнәрдән Миркасыйм Госманов, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Равил Фәхретдинов, Равил Әмирхан, Хатип Миңнегулов, Индус Таһиров, Марсель Әхмәтҗанов, Сәлам Алишев, Дамир Исхаков, Лена Гайнанова, танылган рәссамнар Рушан Шәмсетдинов һәм Зөфәр Хәкимов кебек шәхесләр булуын билгеләп үтәргә кирәктер. Ул журналның иң зур казанышы Гаяз Исхакый иҗат иткән әсәрләрнең һәм аңа багышланган күпсанлы фәнни һәм истәлек язмаларының халкыбыз, ягъни бүгенге заман укучыларыбыз һәм галимнәребез карамагына кайтарылуыдыр дип уйлыйм. Әйе, шул җәһәттән бик зур эшләр эшләнде. Башка төрле ачышлар һәм табышлар да булгалады ул мәҗмуга сәхифәләрендә. Аларны да онытырга кирәкмәстер, мөгаен.

1995 елдан үз халкының үткәне белән кызыксынучылар өчен ике телдә нәшер ителүче «Гасырлар авазы / Эхо веков» журналы чыга башлады. Аның оештыручысы һәм беренче мөхәррире күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы, галим Дамир Шәрәфетдинов булган иде. Шуннан соң күп тә үтмәстән Фәннәр академиясе дә татар һәм рус телләрендә аерым чыгучы ике мәҗмугага – «Фәнни Татарстан» белән «Научный Татарстан» журналларына җан кертеп җибәрде. Бу ике журналның да баш редакторы Фәннәр академиясенең президенты, академик Мансур Хәсәнов, мәҗмугага кергән гыйльми язмаларны барлап, туплап чыгаручы тарих фәннәре кандидаты Булат Хәмидуллин булды. Дүрт исем йөртүче әлеге соңгы өч мәҗмуганың да төп эчтәлеге һуманитар фәннәр темасына багышланган, дисәк тә хата булмастыр. Аларда аеруча әдәбият, сәнгать һәм тарихка багышланган хезмәтләр өстенлек итә. Шулардан ике-өч кенә мисал китереп китәсе килә. «Гасырлар авазы»ның беренче саннарыннан ук диярлек милләтебезнең тарихына багышланган, төрле илләрнең архивларында сакланган бик тә кирәкле документлар басыла башлады. Менә 1995 елгы тәүге саннарның берсен ачабыз. Төркиядән кайтарылган бер күләмле язмада 1550 елда Мәскәү кенәзлеге гаскәрләренең Казанны яулап алырга тырышуы тасвирланган. Бу дастан-поэманың авторы – шул вакыйгаларның шаһиты булган Шәриф Хаҗитархани. Дастан шул заман телендә язылганлыктан, журналга ул әсәрне, бүгенге сөйләм теленә якынайтып, филология фәннәре докторы

Фәрит Хәкимҗанов тәкъдим иткән. Инде «Эхо веков» өлешенә кергән, русча нәшер ителгән бер хат эчтәлегенә тукталыйк. Казан ханы Сафагәрәй (идарә итү еллары 1524-1549) Литва-Польша дәүләте хакимнәре исеменә дүрт хат юллаган булган икән. Шуларның берсе журналның 1997 елгы 1-2 санында китерелә. Бу хатны укып һәм хәзерге рус теленә якынайтып, искәрмәләр белән баетып бастыручы галимә Динә Мостафина була. Ә ул хатларны Польшадан кайтаручы – журналның ул вакыттагы баш мөхәррире, тарих фәннәре докторы мәрхүм Дамир Шәрәфетдинов.

«Научный Татарстан» журналына да күз төшереп алыйк. Төркия галиме, фән докторы Али Биринҗи безнең Тукай, Гаяз Исхакыйларның чордашы, алар белән дустанә диярлек мөнәсәбәттә булган язучы, тарихчы һәм тел гыйлеме галиме Габделбарый Батталга (1880-1969) багышланган күләмле мәкаләсен ике санда – 2011 елның 2, 3 нче саннарында бастырган. Үз милләтенең язмышы өчен янып йөргән Габделбарыйны большевиклар беренче көннәрдән үк эзәрлекли башлагач һәм ике мәртәбә төрмәгә утырткач, 1921 елда ул иленнән чыгып качарга мәҗбүр була. Дүрт ел Финляндиядә яшәгәннән соң, Төркиягә барып урнаша. Байтак еллар яңа Төрек Республикасында оештырылган фәнни институтларда эшли. Күп санлы фәнни-тарихи хезмәтләр авторы буларак танылa. Бүгенге чор Төркия галиме Али әфәнденең милләттәшебез эшчәнлеген бәяләгән юлларына гына күз төшерик: *«Габдулла Баттал-Таймасның (Төркиядә ул шул тәхаллүс белән иҗат итә), һичшиксез, XX гасырның иң күренекле акыл ияләре һәм лингвистлары исемлегендә йөртелергә хакы бар. Ул күп кенә телләрне үзлегеннән өйрәнгән. Рус, гарәп. фарсы, француз һәм фин телләрен белгән. Күпчелек төрки телләрдә аралаша алган. Соңгы елларда ул иң мөһим эшен – Г.Кашгарыйның «Дивани лүгәтет төрек» хезмәтенә багышланган эшен (төрекчә) эшләп бетерде»,* – дип яза бу галим. Ул башлыча Габделбарыйның тел гыйлеменә бәгланышлы хезмәтләренә басым ясый. Бу хезмәтләрдән «Кыргызча-төрекчә» һәм «Якутча-төрекчә» сүзлекләр томнарын (шуларны эшләүче баш белгеч була) атап китү кирәктер. Г.Батталның татарлар тарихына багышланган берничә хезмәте дә бар. Шуларның беренчесе, биш тапкыр нәшер ителгәне, Казанда яшәү чорында язылган. «Татар тарихы»ның тәүге өч басмасы 1912-1916 елларда Казанда, соңгы басмасы Чаллы шәһәрендә, «Аргамак» журналының 1996 елгы дүрт санында басылган. «Казан төркиләре» тарихи хезмәте Финляндиядә язылa һәм 1925 елдан башлап Төркиядә өч тапкыр, Казанда бер тапкыр (1996 ел) нәшер ителә. Шулай булуга да карамастан, татар укучысы әлегә Г.Баттал иҗаты белән бик аз таныш, дип әйтергә хаклыбыз. Совет хакимияте чорында бу «ак эмигрант»ның исемен һәм иҗатын телгә алу тыелган иде. Аларны, алты күренекле шәхесне, бер җепкә тезеп, мыскыллап, «өч игезәк әбүҗәһел Садри-Фоат, Закир-Гомәр, Баттал-Гаяз» дип язу утызынчы елларда модада булган. Төркия галиме Али Биринҗинең «Научный Татарстан» журналында басылган әлеге күләмле язмасы алда китерелгән соңгы пардагы Гаяз Исхакыйдан соң Габделбарый Баттал иҗатын да иленә кайтара башларга кирәклекне белдерә сыман.

***

2012 елда, элекке җитди басма, исемен бераз үзгәртеп, «Чын мирас» журналы буларак чыга башлады. Аны оештыручылар исемлегендә күренекле җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукай

исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрь Илфак Ибраһимов, тарих фәннәре докторы Илдус Заһидуллин, яшьрәк буын галимнәр һәм журналистлардан Рамил Ханнанов, Ленар Гобәйдуллин, Алия Мөбарәкшина һ.б. бар.

«Чын мирас» битләрендә безгә изге «Болгар җыены»на багышланган җитди эчтәлекле хезмәт белән дә (авторы Җәмил Мөхәммәтшин), Казан ханлыгы тарихына караган кайбер хезмәтләр һәм бериш галимнәребезнең Казан ханлыгы язмышына бәя биргән язмалары белән дә танышырга насыйп булды. Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиевнең Татарстанның Казан арты авылларында сакланган борынгы кабер ташларын барлап язган хезмәте дә бик әһәмиятле бер язмадыр.

«Чын мирас»та 2012-2013 елларда басылган хезмәтләрдән минем өчен ачыш дәрәҗәсендә кабул ителгәне – Төркиядә яшәүче фән докторы, профессор Исмәгыйль Төрекуглының «Төрек-татар бәйләнешләре» булды. Шул хезмәтнең Төркиядә яшәп дан казанган милләттәшләребезгә багышланган өлешенә тукталып тормастан, аның соңгы – «Татарлар тарафыннан Истанбулда чыгарылган газета-журналлар» дигән бүлегенә тукталып үтәсем килә (2013 ел, 3 нче сан). XX йөз башында Истанбул шәһәрендә татар телендә бер дистә чамасы газета вә журнал дөнья күргән икән. Безнең Тукайларыбыз да бик үк өнәп бетермәгән, аны идарәче ил хакиме буларак тәнкыйтьләп, төрткеле шигырь юлларын багышлаган Төркия солтаны Габделхәмит, ниһаять, 1908 елда тәхеттән бәреп төшерелә. Илдә конституциягә нигезләнгән җөмһүрият төзү омтылышлары башлана. Шушы вакыйгалардан файдаланып, Истанбулда яшәүче милләттәшебез, язучы Муса Акъегетзадә «Мәтин» (гарәпчәдән тәрҗемәсе «Асыл нөсхә») дип исемләнгән газета чыгару теләген белдерә. Газетаның беренче саны 1908 елның 20 июлендә борын төртә. Берәздән соң, тагын ике газета белән берләшкәч, «Мәтин» исеме «Өч караш» дип үзгәртелә. Ә редакторлык вазифасы кабат Муса морзага йөкләнә. 1909 елның урталарында, Муса Акъегетзадә башка бер өлкәгә эшкә билгеләнгәч, бу татарча газета чыгудан туктый.

Ә 1910 елдан исә Истанбулда элекке Россия мөселманнары мөфтияте казые Габдерәшит хәзрәт Ибраһимов матбугат эшчәнлеген башлап җибәрә. Баштарак ул бер төркияле белән бергә «Мөселманнарның танышуы» исемле журналын чыгара. Журнал атнага бер мәртәбә нәшер ителә. Җәмгысы 32 саны басылып чыга. Ул ябылгач, 1911 елның март башыннан, Рәшит казый «Ислам дөньясы» журналын нәшер итәргә керешә. Аның 26 саны укучы кулына барып ирешә. Бу мәҗмугаларда, нигездә, Россиядә яшәүче мөселманнар тормышына багышланган һәм Балкан төбәгендә барган милләтара сугышка бәйле мәкаләләр урын алган. Мәкалә авторлары да төрле катлам кешеләре булган икән. Журналның бер санында Петербургта яшәүче милләттәшебез, дин галиме Муса Ярулла Бигинең югары катлам руханилар арасында бәхәс тудырган хезмәте басылгач, «Ислам дөнъясы»н да ябалар.

Шуннан соң Истанбулда татар телендә «Ислам мәҗмугасы» пәйда була. Бу журнал дүрт елдан артыграк яши (12 февраль, 1914. – 30 октябрь, 1918), шул еллар аралыгында аның 63 саны нәшер ителә. Бу мәҗмуганы чыгаруны оештыручы төркемдә Рәшит казый Ибраһимовның кызы Фәүзия дә була. Авторлар исемлегендә әлеге казый белән кызы Фәүзия, шул елларда Германиядәге әсир милләттәшләребез арасында зур оештыру эшләре башкарган мулла Галимҗан Идриси, Оренбургта нәшер ителүче «Шура» мәҗмугасы мөхәррире Ризаэддин

хәзрәт Фәхреддин, Муса Ярулла Биги, кайбер башка татар әдип вә журналистлары (Фатих Әмирхан, Фуат Туктар) һ.б. булган икән.

Бу журнал ябылып, озак та тормастан Истанбулда татар телендә хатын-кызларга багышланган «Асары Нисван» мәҗмугасы борын төртә. Аның беренче саны 1925 елның 26 гыйнварында басылып чыга. Мөхәррире – Фәүзия Рәшит кызы Ибраһим, әсеңлесе Кадрия Ибраһим авторлар һәм хезмәттәшләр исемлегендә теркәлгән. Ләкин бу татарча журналның да гомере озын булмый. Җәмгысы аның 28 саны дөнья күрә. Димәк, ул мәҗмуга да ике ел ярымнан озак яшәми.

Истанбулда шул замандагы татар теленә якын телдә нәшер ителә башлаган иң озын гомерле журнал – «Turk yurdu» («Төрек йорты») була. Шушы хезмәт авторы Исмәгыйль бәй Төрекуглы аны, «чын мәгънәсендә бар төрки дөнья журналы булды», дип белдерә. Бу мәҗмуганы оештыручы алты ир-ат арасында әйдәп йөрүчесе Йосыф Акчура булганлыктан, безнең матбугатта ул элек-электән «Йосыф Акчура чыгарган журнал» буларак теркәлгән. Дөрес, 1917 ел вакыйгаларына чаклы ул аның беренче мөхәррире дә булган. Бу мәҗмугага үрнәк рәвешендә Россиядә нәшер ителгән «Шура» журналы алынганлыгын Исмәгыйль Төрекуглы да билгеләп үтә. Журналны башлап чыгаруга тотылган акчаның да «оренбурглы татар байларыннан булган мәшһүр Мәхмүт бай Хөсәеновныкы» икәнлеген хәбәр итә ул. «Бу акча белән ничә ел буе өзлексез чыгып килә торган «Төрек йорты» журналына нигез салына», – дип тә белдерә Исмәгыйль бәй.

Мәҗмуганың беренче нөсхәсе басмаханәдән 1911 елның 20 ноябрендә чыга. 1911-1931 еллар аралыгында журналның «233 саны нәшер ителгән», дип белдерелә «Татар энциклопедия сүзлеге»ндә. Безнең милләт тарихы өчен шунысы да әһәмиятле: мәҗмуганың 1-2 нче саннарында патша Россиясе Дәүләт Думасы депутаты Садри Максудиның Россия мөселманнары күтәрелешенә багышланган «Бөек милли гамәлләр» мәкаләсе басылып чыга. Дөрес, ул аны үз исеме белән бастырырга җөрьәт итмичә (Россия дәүләте депутаты бит), «Җанбәк» тәхәллүсе белән чыгарырга рөхсәт бирә, дип хәбәр итә кызы Гадилә (Адилә Аида) атасына багышланган китабында.

«Чын мирас»ның 2014 елгы 1-3 нче саннарында укучы хөкеменә Йосыф Акчураның төркиләр мәдәнияте тарихында тирән эз калдырган шәхесләргә багышланган «Яңа төрек дәүләте уңчылары» хезмәтенең тәрҗемәсе тәкъдим ителә. 1928 елда язылган бу хезмәт Төркиядә инде берничә мәртәбә басылып чыккан икән. Иң әүвәл әлеге хезмәтнең аерым өлешләре «Төрек елы» мәҗмугасының берничә санында нәшер ителгән. Аннары аны 1981, 2001 елларда аерым китап рәвешендә бастырып чыгаралар. Димәк, бу хезмәтнең яңа заман укучы һәм галимнәре өчен дә әһәмияте әйтеп бетергесез зур. Ниһаять, күренекле милләттәшебезнең шушы җитди хезмәте белән «Чын мирас» журналы битләрендә безгә – якташларына да танышу насыйп булды. Хезмәтне төрек теленнән тәрҗемә һәм искәрмәләр белән журнал редакциясенә тәкъдим итүче филология фәннәре докторы мәрхүм Мәсгуд Гайнетдинов иде.

Мин мәҗмуганың 3 нче санында урын алган күренекле азәрбайҗан җәмәгать эшлеклесе һәм язучысы Фатех Али Ахундовка багышланган өлешенә генә бераз тукталмакчы булам. Бу очракта ул шәхеснең исеме Төркиядә кабул ителгән вариантта китерелә. Үзебезнең XX гасыр башы әдипләре һәм зыялылары аны бездә чак

кына башкачарак – мирза Фатихали Ахундов итеп язганнар. Ф.Ахундов – Россия төркиләре арасында иң беренче драматург буларак танылган шәхес. *«1850-1855 елларда ул туган телендә Европа ысулында берничә комедия яза. Мирза (Ф.Ахундов) иҗатына Мольерның яки Россия драма әсәрләре язучыларының, мәсәлән, Гогольнең тәэсире булуы, драматургның алардан илһам алганлыгы бик мөмкин»,* – дип хәбәр иткән Йосыф Акчура.

Ул заманда Кавказ төбәгендәге шәһәрләрдә төрки телдә эшләүче басмаханәләр булмый әле. Баку белән Тбилиси калаларында беренче басмаханәләр егерме еллардан соң гына эшли башлый. Мәсәлән, Бакуда «Игенче» исемле беренче газета 1875 елдан, Кавказ татарлары телендәге икенче газета «Зыя-и Кавказия» Тбилиси каласында 1878 елдан нәшер ителгән. Ф.Ахундов сәхнә әсәрләрен бастырып чыгару хыялы белән Төркиягә дә барган. Аларны «Җәмгыяте гыйльмия Госмания (ягъни Төркия)» утырышларында җәмәгатьчелеккә укып та күрсәткән. Ләкин әле ул вакытта Төркиядә дә сәхнә әсәрләрен иҗат итүчеләр булмый. Әдәбият гыйлеме белән кызыксынучылар әлеге оешма утырышында кунакның иҗат үрнәкләренә карата уңай фикергә килә алмыйлар. «Язган театр хикәяләре тулысынча укылды... «Җәмгыяте гыйльмия» киләчәктә (аларны) госманлы теленә тәрҗемә итеп, бастырып чыгарырга тырышачак», – дигән карар гына чыгаралар. Ләкин, Йосыф Акчураның хәбәр итүенчә, ул карар да үтәлми. Ф.Ахундов пьесалары үз заманында төрки телдә басылмыйча кала. Ә менә Тифлис каласында исә ул җиде пьеса 1859 елда ук басылып чыккан.

Яңа журнал битләрендә менә шундый кирәкле һәм кызыклы мәгълүматка бай материаллар шактый күп урнаштырылган иде. Аннары ул журналның исеме бераз үзгәртелде – «Безнең мирас» булды. Редакторлары да алышынды. Хәзер аның баш редакторы – күренекле әдип Ләбиб Лерон, аның урынбасары – танылган шагыйрь Марат Закир. Редакторлары һәм кайбер әдәби хезмәткәрләре алмашынуга карамастан, бу кызыклы мәҗмуганың эчтәлеге үзгәрмәде. Анда бик күп кызыклы, тарихи яктан кыйммәтле мәкалә һәм очерклар даими рәвештә чыгып килә. Дөрес, мәрхүм Мәсгуд ага Гайнетдиновның бакый дөньяга күчүеннән соң, Төркиягә бәйле тарихи хезмәтләрнең кытлыгы үзен бераз сиздерә кебек. Кардәш казакъ, кыргыз, үзбәк һ.б. халыклар әдәбиятына һәм тарихына багышланган язмаларны да «Безнең мирас» битләрендә ешрак күрәсе килгән чаклар була. Филология фәннәре докторы, профессор Хатип Миңнегуловның казакъ кардәшләребез әдәбиятына һәм тарихына багышланган хезмәтләре аратирә чыккалый, ләкин күңел һаман әле андый эчтәлекле язмаларның ешрак күренүен көтә шул...

Журналның быелгы 8 нче санын кулыма алгач та икеләтә сөенеч кичердем. Ул санда Чыңгыз Айтматовның Совет хакимияте елларында дөньяга чыгарырга шикләнебрәк йөргән күләмле әсәре – «Чынгызханның ак болыты» басыла башлаган. Икеләтә сөенүемнең сәбәбе шулдыр: әдипнең кыргызча бер әсәре 1990 еллар башында «Ала тоо» журналында дөнья күргән иде. Шул вакытларда Урта Азияда йөргәндә мин аны алып кайткан һәм соңрак мирасчыларга тапшырган идем. «Чыңгызханның ак болыты»н укыганда әлеге журнал да һаман күз алдымда торган кебек булды... ■

Кызлар язмышы – милләт язмышы

Тәэминә Биктимерова

Халкыбызның гаять бай тарихлы булуын, ни кызганыч, бары соңгы елларда гына аңлый башладык шул. Тарихыбызның, андагы шәхесләрнең, шул исәптән зыялы кызларыбызның да тормыш юлларының гаять дәрәҗәдә өйрәнелмәгән булуы нинди аяныч нәтиҗәләргә китерде.

XX гасыр башы... Татарның зыялы ирләре Шәрыктан килгән олы гадәтне кайтарып, хатын-кызны нинди биеклеккә куя алганнар. Бу мәкаләмдә тормыш юлларын өйрәнеп, ачып һәм талантларына, тырышлыкларына сокланып, хәйран калып яшәргә мәҗбүр иткән өч бертуган кыз – Гамбәр, Шәмсекамәр һәм Суфия Коләхмәтовалар хакында язам. Үзләренең илаһи куәтләрен замандашларының сәламәтлеген саклауга багышлаган бу кызлар.

Советлар чорында иҗатына зур бәя бирелгән, халык бәхете өчен көрәшүче дип хаклы рәвештә аталып йөргән Гафур Коләхмәтовның кыз туганнары алар. Сабын кайнату һөнәре остасы дип дан алган Юныс Коләхмәтов һәм Газизә абыстай гаиләсендә 9 бала туа. Газиз, Гафур, Каюм, Муса, Габделмәннан, Мөхәммәтәмин исемле ир балалар (әйтеп үтим, Газиздән башкалары барысы да Татарская учительская школада укыган) һәм өч кыз бала. Олысы – Гамбәр, уртанчысы – Шәмсекамәр һәм кечесе – Суфия.

Алар XX йөз башында Пензадан Казанга күчеп киләләр. Башта Юныс олы улы Газиз белән Үтәмишевләрнең Яңа бистәдә урнашкан кечерәк кенә сабын кайнату заводына эшкә урнаша, соңрак гаиләсе дә күченә. Пензадагы тормыш хәлләре ачык түгел, әмма олы кызы Гамбәрнең һәм өлкәнрәк ир балаларының, Казанга килгәнче үк, заманы өчен яхшы белем алулары ачык билгеле. Шунысы да мәгълүм: кызлар барысы да кул эшләренә бик оста булалар һәм күңелләреннән моның белән горурланганнар да, чөнки Казанның иң бай йортларыннан заказлар аларга килгән.

Татарстан дәүләт архивында Гамбәр апаның шәхси эше саклана. Анда аның 1874 елның 21 нче гыйнварында тууы, белемне гаиләдә алуы һәм, Казан укытучылар семинариясендә имтихан биреп укытучы дипломы алуы турында әйтелгән. Рус, татар, француз телләрендә иркен сөйләшкән кыз баланың шәхси тормышы да язмыш сынауларына шактый бай, нәкъ талантлы кешеләрнеке кебек, гыйбрәтле.

Милләте башкорт дип язылса да, гел Казанда яшәгән татар морзасы Шәйхелгаттар Гобәевнең офицер улы Мәхмүт Солтан гашыйк була аңа. Гаилә башлыгы Шәйхелгаттар бу вакытта инде вафат, ә менә тол калган булачак каенана килененең «сабын кайнатучы хәерче кызы» булуын бер

Шәмсекамәр
Коләхмәтова.
1903 ел

Суфия
Коләхмәтова.
1905 ел

дә теләмәгән. Ул вакытта офицерга мещан сословиесендәгеләр белән никахлашу закон белән тыелган булган. Әмма кызының бәхетле булуын теләгән ата, өяз шәһәре Свияжскига барып, сәүдәгәрлеккә язылуга ирешкән (һичшиксез, ришвәт биреп, Россиядә башкача булмый).

Яшьләр өйләнешәләр, әмма үзләре бик бәхетле булсалар да, каенанага бу эш ошамаган. Ачуыннан ул үз баласы өстеннән Петербургка хәтта шикаять тә яздырган. Шул әләк нигезендә, Солтанны Казаннан Сембергә җибәрәләр.

20 нче елларда Казанда яшәгән Зөһрә апа Баимбетова (70-80 нче елларда Мәскәүгә баргач, аның белән еш очраша идем) Солтан белән Гамбәр хакында болай дип сөйләгән иде: *«Солтан үз бәхетенә әнисенең шулай каршы төшүен бик авыр кичерә. Чиксез яраткан Гамбәре белән уртак балалары Равил туа. Ачуыннан ярсыган әнисе генә аларны тыныч-*

Гамбәр
Коләхмәтова.
1905 ел

лыкта калдырмый. Ул язган әләкләр аркасында штабс-капитан дәрәҗәсеннән бөтенләй гади солдат итеп төшерелү куркынычы тугач, Солтан атылып үлә. Бу хәл 1903 елның 31 мартында була һәм ул Сембер зиратына күмелә. Сөекле иренең үлеменнән соң, Гамбәр бик каты авырый. Улы Равил хакына гына исән калмадымы икән?! Равиле, ялгышмасам, үскәч, Башкортстанның беренче сынаучы-очучысы булды, дип хәтеремдә калган».

Гамбәр апага кайгысын җиңәргә әтисе йортындагы җылы мөнәсәбәт тә булышкандыр, дип уйлыйм. Баласын тәрбияләргә дә энисе, туганнары ярдәмгә килә. Үзе, кайгысын җиңеп, 1905 елда Казан университеты каршында ачылган акушерлар әзерли торган институтка керә һәм табиб дипломы ала[1].

Бәхетенә очраган Солтаны белән шулай тигез, матур яшәргә язмаган Гамбәр апага. Гаиләсендә дә, дус-ишләре арасында да чиксез хөрмәт тоеп үскән кыз баланың соңгы тормышы хакында мәгълүматым юк. Әмма Уфага китеп, шунда яшәгәндер, дип уйларга нигезем бар. Чөнки аны яраткан каенсеңелләре Рокыя белән Өммегөлсем – икесе дә табибәләр, Уфада гомер иткәннәр, Равилне дә бергәләп тәрбияләгәннәрдер, дип уйлыйм. Рокыя апа Совет хакимияте елларында фидакяр хезмәте өчен Ленин ордены белән бүләкләнгән, СССР Югары Советына депутат та булып сайлана алган әле.

Шәмсекамәр – кызлар арасында иң йомшак күңеллесе, аш-су әзерләгәндә дә, йорт эшләрендә дә энисенең беренче ярдәмчесе. Энеләре дә, йомышлары булса, аңа әйткәннәр, ул һәркемгә яхшылыктан башканы теләмәгән дә, белмәгән дә.

Татарның зыялы гаиләләрендә урнашкан гадәт буенча, әти-әнигә каршы сүз әйтергә кыймаган кыз баланы кияүгә әтисе бирә. Белмим, сәүдәгәр гаиләсенә бирсәм, кызымны бәхетле итәм, дип уйладымы икән Юныс ага. Әмма аракы эчәргә бик яраткан, тупас мөгамәләле бер егеткә көчләп биргән ул кызын. Шәмсекамәрнең тормышы мәхшәргә әверелгән. Көн саен исерек иренә ничек тә ярарга белмәгән ул. Баласы тугач, бәлки арабыз төзәлер, бәлки яшәп китәрбез дип өметләнсә дә, барып чыкмый. Ире, исереп кайткач, яңа туган баласын тартып алып идәнгә ыргыта. Бәхетенә, йомшак юрганга төрелгән балага зыян килми. Кызы Гайшә Габделхәмит кызы Шәрипова, үсеп җиткәч, күренекле тәрҗемәче, язучы булып таныла. Аның «Семья Гафура» дигән китабын, бәлки, әле өлкән буын укучылар хәтерлидер дә.

Ул вакытта хатынның ирдән аерылып китүе гаеп эш саналган. Каенана-каенаталарының елап үгетләүләренә карамастан, Шәмсекамәр ире йортыннан китә. Әмма баланы тәрбиялисе, үстерәсе бар бит. Шулвакыт аңа абыйсы Гафурның дусты, табиб Искәндәр Котлыбаев фельдшерлар курсына керергә булыша. Ходай биргән чиксез сәләте аңа бу һөнәрне дә бик тиз үзләштерергә ярдәм итә. Ул чын табибә булып җитешә. Казан хәтле Казанда хатын-кыз табибәләр бармак белән генә санарлык заман бит әле бу. Татар хатыннары табибларга хәтта ирләре белән бергә дә барып күренергә оялганнар. Шәмсекамәргә шуңа күрә эш җитәрлек була. Шулай үз көнен үзе күрә ул, кызын тәрбияли. Халык белән даими аралашу кыюлык та өсти аңа. Ул хәтта 1907 елның 11 апрелендә хатын-кызлар өчен куелган спектакльдә дә катнаша.

Бу тамашаның тарихы болай була. Учительская школаны тәмамлап, хәзерге Биектау районының Ямаширмә авылында укытучы булып эшләгән энесе Каюм ярдәм сорап килә. Ул бу елны ашлык уңмавын, күп кенә гаиләләрнең ачыга башлауларын сөйли. «Балалар бик ачыга», – дип кайгыра. Шулвакыт Габдулла Кариев хатын-кызлар өчен спектакль

[1]ТР МА (НА РТ), 977 ф., 563 тасв., 6 эш, 2–3, 7 б.

куярга тәкъдим итә. «Килүчеләр күп булыр, чөнки татар хатыннарының да тамаша күрәселәре килә бит, тик уйнаучылар да хатын-кызлар гына булсын», – ди. Уйнар өчен Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» дигән әсәре алына. Казан тарихында беренче тапкыр булган бу тамашага чынлап та хатын-кызлар күп килә. Аларны ирләре озатып куя, әмма үзләрен кертмәгәнгә ачулары да килә. 1907 елның 11 апрелендә куелган әлеге спектакль зур уңыш казана. Мыеклар ябыштырып ирләр ролен уйнаган Шәмсекамәр дә, сеңлесе Суфия да үзләрен сәләтле артистка итеп таныталар. Хаклы рәвештә татар театрының атасы саналган Габдулла Кариев аларга рәхмәт әйтә. Үз вакыты өчен шактый зур акча булган 67 сумга азык-төлек алып, Ямаширмә авылына җибәрәләр.

1889 елда җиденче бала булып дөньяга килгән Суфия Коләхмәтова хакында романнар язып булыр иде. Тик язмам бик озынга китте кебек, кыскача гына язарга мәҗбүр булам.

Ул үсеп җиткәндә, әтисе һәм олы абыйлары Газиз дә үлеп китә. Гаиләдәге 5 баланы тәрбияләү Гафур өстендә кала. Белем аласы, апалары кебек табибә буласы килгән Суфияны укытырга гаиләнең матди хәле авыраю комачаулый. Яшьтән үк эшчәнлеге һәм зирәклеге белән аерылып торган кыз, гаиләгә ярдәм итү ниятеннән, Пороховой бистәсендәге абыйсы укыткан мәктәпкә каравылчы булып эшкә урнаша. Ул мичкә ягарга да, мәктәпнең идәннәрен дә юарга тиеш була. Утын яру, ишегалларын себерүгә энеләре булышкач, Суфия Гафур абыйсының дәресләренә кереп утырырга да мөмкинлек ала. Үзлегеннән укып, 3 нче ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына бик яхшы билгеләренә имтихан да бирә.

Ә 1908 елда ул Петербургның Хатын-кызлар югары медицина курсларына кабул ителә. Әмма Суфия алдына 5 ел буе үзәк шәһәрдә түләүле уку йортында укыр өчен кирәкле акча табу мәсьәләсе килеп баса. Аллаһы Тәгалә талантлы, тырыш кызга бу юлы да ярдәм итә дими, ни дисең. Беренче курста күренекле язучыбыз Фатих Әмирхан бирә Суфияга акчаны. Икенче елны бөек шагыйребез Габдулла Тукай булыша. Шулай укыр өчен дә, фатир өчен түләргә дә, гомумән, уку һәм яшәү өчен мөмкинлек туа. Соңгы курсларда уку өчен кирәкле акчаны аңа булачак ире Фәхрелислам Агиев табып бирә. Бу вакытта Фәхрелислам үзе дә Казанда укып йөри. Әмма ул бәхетлерәк, аңа укыр өчен туганы акча кызганмый. Менә шул акчаларның бер өлешен егет Суфияга җибәрә.

1914 елда Суфия дипломлы табибә булып Казанга кайта. Бу вакытта Беренче Бөтендөнья сугышы башланып китә. Казанга бик күп яралыларны кайтара башлыйлар. Казанның могтәбәр байлары, дин әһелләре Галимҗан Баруди һәм Габдулла Апанаевлар тырышлыгы белән, мөселман яралылары өчен махсус лазарет ачалар. Менә шул лазаретка киләчәктә зур галим булып танылачак Әбүбәкер Терегулов белән Суфия Агиева табиб итеп чакырыла.

Тик кеше бәхете озакка барамыни! Күп тә үтми Ф.Агиевка «Бишек җыры» исемле әсәр язганы өчен, «бик кыска вакытта Казаннан китәргә» кушыла. Суфия белән Фәхрелислам (берсе – табибә, икенчесе – укытучы) Пенза өлкәсенең Юнә авылына китәргә мәҗбүр булалар. Әйбәт кенә яшәп китәләр. 1916 елда алар янына инде сәламәтлеге бөтенләй начарланган Гафур да килә. Никадәр тәрбияләсәләр дә, ярдәме тими. Инде мәгълүм булганча, татарның олуг затларыннан саналырга тиешле Гафур Коләхмәтов 1918 елның 1 апрелендә (иске стиль белән) сеңлесе һәм кияве кулында җан бирә.

Фәхрелисламы Сталин палачлары кулыннан корбан булгач, Суфия Алма-Атага китә һәм сеңлесе Гайшә белән соңгы көннәренә кадәр шунда яши. Кайчан җир куенына кергәнен төгәл белә алмадым, тик 1971 елда, 82 яшендә истәлекләр язганлыгы мәгълүм. ■

КИЛӘЧӘК КЕШЕСЕ ҮРНӘГЕ

Әхтәм Зарипов

«Больницага бер авыру белән керәсең, биш авыру белән чыгасың» дигән фикергә ышанмасам да, бер елда өч хастаханәдә ятуым кеше ышанмас хәлләргә дә ышандыра башлады.

Палатага урнашкач та авырулар бер-берләре белән сөйләшүдән тыелалар. «Ачылып» китүдән качалар, ахры. Ә бу кеше мин караватка ятканчы ук бүлмәдәгеләр белән таныштырырга ашыкты:

– Энекәшме, абзыймы, сине инсультчылар компаниясенә кертеп салдылар. Кабул итәбез. Персонально, һәркайсы, кирәк тапканча, үзе белән үзе таныштырыр. Ә мин? Мине инде, таныштырмасам да, таныгансыздыр: мин – дәгъватчы, ягъни өндәүче мәгънәсендә дәваланып ятучы.

– Нәрсәгә өндәүче? – дигәнемне сизми дә калдым.

– Үзеңнән үзең баш тартырга тиешлеккә өндәүче. Шунсыз терелү юк, диләр.

– Мөмкин хәлме бу?

– Менә мин үземнән үзем дә, тоткан

юлларымнан да, идеяләремнән дә баш тарттым, иншаллаһ, терелүгә таба барам шикелле: аягыма баса алмасам да, кая барырга, баргач, анда нәрсә кирәген әйтә алам.

Ике кулымның берсе сынган – күрәсеңдер, гипста, икенчесе – инсульт корбаны булуга карамастан, үземә тиешлене ычкындырмый. Башкаларның да шундый ук. Ә син нинди һәм хәзер кем син?

Мин үземнең «важный» кеше булуымны күрсәтергә теләп: «Узган чакырылыш Дума депутаты, хәзергә отставкадагы журналист», – дидем. Палатадагылар, башларын борып, миңа карагандай иттеләр. Ә дәгъватчы:

– Иртидатка бармасаң, журналистлык һич үзе китми. Баш тарт. Терелүеңә бер шарт шул.

– Баш тартырлык идеяләрем юк.

– Мин дә шулай уйлап яши идем. Хаталануымны дөнья танытты. Миңа гына түгел – меңнәргә, миллионнарга танытты.

– Мәсәлән, мин әлегә Сезне танымыйм. Кем Сез?

– Чөнки син идеяле кеше. Мине тану синең өчен куркыныч.

– Мин үлемнән генә куркам, иптәш.

– Үлем куркыныч түгел, ә үз-үзең булмау куркыныч. Безнең буын – үз-үзе булудан куркып качкан буын.

– Ә мин качмадым.

– Шуңа күрә инсульт алдың да.

– Ә син нигә алдың?

– Ниһаять, танышуга якынлаштык, ахры.

Исемемне әлегә әйтмим. Заманында мин Башкортстанның Иштуган сусаклагычын яклап язган өчен хөкүмәт премиясе алган газетчы. Нәтиҗәдә, дәүләт 500 миллион сум акчалата зыян күрде. Бер файдасызга. 6000 гектар сөрүлек, шуның кадәрле үк мәйдан көтүлек-болыннарын, шул чама урманнарын югалтты. Урман белән нинди киекләр югалуын әйтәсе дә юк. Иң кызганычы – Агыйделнең югалуы. Җырлардагы Агыйдел юк хәзер. Юк! ...Мин – Агыйдел буенда пароход тавышларыннан нинди пароход килүен белеп, әйтеп үскән, Казанга укырга «Гафури»га утырып барган, «Тукай»га утырып кайткан малай.

Хәзер Агыйделдә катердан башка судно йөзә алмый. Тар да, сай да. Кем гаепле? Мин үземне һәм, гомумән, журналистларны гаеплим. Ялганны күп яудырдык. Биргән премияләреннән баш тарткач, мине «акылдан шашкан» дигән хәбәр тараттылар. Шуннан соң ни булганнарын соңрак сөйләрмен. Сизәм, кызыксындың шикелле.

– Димәк, син Башкортстаннан?

– Анда минем яшәрлегемне калдырмадылар.

– Шуннан Казанга күчеп килүеңме?

– Казанда «диваналанган» дигән хәбәр таратылган, юллар ябык иде. Мәләкәстәге апайларга күчеп киттек. Дворник булып эшләдем.

– Син бит шулчактагы сәясәтне яклап язгансың? Нигә көрәшмәдең?

– Бер башлагач әйтим инде: хатын ташлап китте. Авыру малай белән ялгызым калдым. Аны, вакытлыча, әтиләргә кайтарып калдырган идем, икенче авыруы ачылды: мыек чыкмый, малайлар белән уйнамый, ирененә кызыл сөртә... Авыл халкы телгә үткен бит: улымнан «кыз тәкә» дип көлделәр. Казанга алып барып докторларга күрсәтергә киңәш иттеләр. Бардым, алып барганымны, җай чыгарып, суздым. Мәһәр – күчтәнәч, янәсе. Докторның күзе шар булды. Улыңны ир итәсең килсә, алда расходларың булыр әле, сабыр итеп тыңла, диде. Аңлатты. Тыңладым, күндем, хатамны таныдым. Операциягә салдык. Миннән ирлек «күзәнәге» алып, улыма күчерделәр. Хәзер ул улым – Себердә нефтяник. Өченче баласы туды. Бер улы минем белән яши. Хәзер Казанда укый. Миңа килеп массажлар ясый, күрерсең әле.

Шунда безне бүлдерделәр. Процедуралар башланды. Мин бер генә сорау биреп өлгердем:

– Улыңны ир иткән ул докторның исеме кем?

– Аны белмәгән кеше юк: Галиев Ринат Харисович! – диде дәгъватчы, горурланып. Мин, әлбәттә, Ринат Харис улын үзем дә яхшы беләидем. Белә генә дә түгел, аның турында телевизион очерк күрсәтеп, газета өчен дә мәкалә язган идем. «Сөннәтчеләргә мәдхия кирәкми безгә», – дип басмадылар. Ул редактор хәзер мәрхүм инде, исемен телгә дә аласым килми. Артык ашкан идея тоткыны иде. Ә язылган мәкаләмнең күпмедер өлеше сакланган.

...Хастаханәгә кешеләр шатланып бармасалар да, гомумән, хастаханә куанычлар урыны буларак кабул ителмәсә дә, мин ул көнне биредә кешеләрнең йөзләрендә шатлык чаткылары күрдем. Табибларда һәм шәфкать туташларында гына түгел. Ул көнне хастаханәдә булган һәркемнең күңелендә яшәүгә, кеше гомерен озайтуга өмет, ихтыяҗ бермәбер арткандыр... Һәм алар үзләрен хастаханәдә дип түгел, ә шифаханәдә итеп тойганнардыр...

...Җәйге ямьле көннәрнең берсендә, тиздән кияүгә чыгам, туй итәбез, дип йөргәндә авырып китә ул кыз. Башта участок, аннары район шифаханәсендә дәвалана. Әмма алга китеш сизелми, хәле көннән-көн начарлана гына бара. Республика клиник хастаханәсенә китергәндә аның инде бөерләре тәмам сафтан чыгып, үзе үлем хәленә җиткән була. Әлеге төр авыруларны дәвалауның ике генә ысулы бар икән: беренчесе – ясалма бөер. Бу очракта, авыру ике-өч көнгә бер хастаханәгә килеп, ясалма бөер аппаратына тоташып, канын чистартып торырга тиеш. Икенчесе – донор бөере, ягъни бөерне үлгән кешедән яки кан туганнардан күчереп утырту.

Республикабызда гына да бөер күчереп утыртуны көтеп яшәүчеләрнең саны 300дән артык булуны искә алганда, һәр ике ысулы да... бер сүз белән әйткәндә, өметсез. Күпчелек Европа илләрендә бу эш җайга салынган, имеш. Фаҗига була калса, һәлакәткә очраган кешенең бөерен операция көтүчеләргә, нинди илдә булуына карамастан, компьютерга алдан салынган мәгълүматлар буенча, вертолет белән китереп тә җиткерәләр. Бездә әле бу турыда хыяллану да... киләчәктә генә мөмкин булыр. Иң үкенечлесе шул: «Сезнең бөерләр экологик таләпләргә туры килми», – дип, Россияне хәтта «Евротрансплантант» җәмгыятенә дә алмыйлар. Заманча техниканың булмавы, үлгән кешедән исән калган бөерне биш минут эчендә алып өлгермәү – аны гамәлгә яраксыз итү ихтималы эшне нык читенләштерә.

Аннары кешене, кайчан «үлде» дип тануга карата булган әхлак, этик мәсьәләләр, кануннарның камил түгеллеге. Нишләргә? Гаиләдән, хыялларыңнан аерылып, гомерне шул «аппарат»ка буйсындырып яшәргәме? Кан туганнар ни дияр? Мисалга китергән очракта – кызның кияү булачак егете үз бөерен бирергә ризалашса да, кан группасы туры килмәү сәбәпле, тәкъдим кире кагыла. Башка туганнары юк. Әтисе үлгән, әнисе... әнисе исә... үзе авырый. Авырса да, кан группасы кызыныкы белән бер һәм иң мөһиме – ул кызы исән калсын өчен... барысына да риза. Тик табиблар гына ризалашсын да, кызын гына исән калдырсыннар! Кайсы табибның тәвәккәллеге җитәр икән? Табыла андый табиб! Ул – безнең Ринат Харис улы Галиев! Республикабызда гына түгел, бөтен Рәсәйгә мәшһүр уролог.

...Чыбыксыз телефон хастаханәдә яхшы эшли: ананы операция ясарлык дәрәҗәгә җиткереп дәвалау курслары тәмам, икесенә дә операция! Әнә нигә шатлана икән биредәге халык!

...Шундый катлаулы операцияләрне

уңышлы башкарып чыгуына соклануымны һәм замандаш милләттәшем белән горурлануымны белдергәч:

– Безнең эшебез, һөнәр-кәсебебез шул, әгәр мөмкинлегем булса, балалары сәламәтлеге өчен үзләренең тән әгъзаларын бирү батырлыгы эшләгән ата-аналарга шәһәребезнең иң күркәм урынында һәйкәл куяр идем мин! – диде Ринат Харис улы, ниндидер бер эчке яктыру, тирән кичереш белән.

– Әйе, ата-аналарга һәм табибларга! – дидем мин, Ринат әфәндене төзәтеп.

Чөнки нәтиҗәләр шаккатырлык: моннан ничә ел элек бөер күчереп утырткан шул кыз, кияүгә чыгып, бала тапкан. Инде оныклары бар. Сәлам хат-хәбәрләре җибәреп ята икән. Монысын соңыннан ишетеп белдем. Ә бит медицинада бөер күчереп утыртылган кеше 5 ел яшәсә, бу иң яхшы күрсәткеч дип саналган!

Әгәр елына бер миллион кешегә 20 бөер күчереп утырту операциясе ясалырга тиеш дип алсак та, Татарстанда 4 миллион кеше яшәгәч, һәр ел саен үзебездә генә дә кимендә 70 кеше әлеге төр операцияне көтә дигән сүз. Чынбарлыкта исә күпкә артык.

Профессорның уңышларын ишетеп белгәннәр Ерак Көнчыгыштан, Әрмәнстан, Әстерхан, Мәскәү, Саратов (Сарытау) калаларыннан да өмет итеп, аның янына килүләренә, хәтта чит илләргә чыгып, уңышсызлыкка очраганнарның да аның хозурына кайтып егылуларына, ул ясаган операцияләр кебек катлаулы операцияләр вакытында элек үлем-китем 75%, хәзер исә, күп булса, 5% кына тәшкил итүенә игътибарыбызны юнәлтсәк, үзеннән-үзе «бу нинди могҗиза соң?» дигән сорауга җавап эзли башлыйсың. Могҗиза!

Ә профессор бу фаразлауны кире кага! «Үз эшеңә мәхәббәт, төгәллек, түземлек, тырышлык һәм тәвәккәллек, – ди ул, тыйнак кына елмаеп, – монда бернинди могҗиза да юк! Безнең кешеләребез могҗиза!»

Әйе, профессор Ринат Харис улы Галиевтә тырышлык та, тәвәккәллек тә, төгәллек тә, түземлек тә җитәрлек. Болардан тыш, анда тагын – тыйнаклык, тәүфыйк һәм талант!

Ул дөньяда беренчеләрдән булып нечкә эчәк кисәкләреннән яңа сидек куыгы үстерүне гамәлгә ашыра! Шул юл белән ул инде биш йөзләп кешене үлемнән алып кала! Тәвәккәллекме бу? Монда мәхәббәт тә, тәвәккәллек тә, талант та бар. Төгәллеккә, түземлеккә һәм тырышлыкка килгәндә... сөйләп бетерә торган түгел. Илдә бөер күчереп утырту үзәге белән җитәкчелек итүче һәм Бөтенрәсәй күләмендә танылган профессорның авыруларны кабул итәрлек заманча җиһазлы урыны да булмый озак еллар буена! Түзә, тырыша Ринат Харис улы!

Операцияләр күп чакта, кайда мөмкин – шунда ясала. Ә мондый үзәкләр, мәртәбәле белгечләре булмаса да, биналары Мәскәүдә, Уфада, Самарада, Түбән Новгородта һәм Чабаксарда да бар, операцияләр ясау өчен Ринат әфәнде аларда көтеп алынган, кадерле табиб.

Кая кирәк – шунда бара Ринат әфәнде Галиев. Һәм ул кирәк булмаган төбәк, шәһәр, хастаханә юк Рәсәйдә! Юк! Ул кайда да кирәк! Чөнки ул... ул бөер, сидек куыгы кебек әгъзаларны гына түгел, кешенең җенес әгъзаларын дәвалауда да беренчеләрдән булган тәвәккәл, тырыш, түзем табиб!

Сүз иярә сүз китеп, шул дәваланган кешеләрнең адресларын сорагач: «Без сенсация өчен эшләмибез, безгә кешенең бәхетле яшәве – иң зур бүләк», – дип, сүзне икенчегә бора Ринат Харисович, бусы – аның тәүфыйклылыгы һәм чын тыйнаклыгы. Ринат әфәндене эш урынында видеотасмага төшерергә дип рөхсәт сорагач, ул бернинди кыланусыз ризалашса да, нәкъ менә безнең өчен, күргәзмә өчен генә эшләргә вакыт бүлә алмады. Аның һәр көне, һәр сәгате эш графигына кертелгән, аны бозу яки

аз гына үзгәртү дә кеше сәламәтлегенә бәйле, башкача булуы мөмкин дә түгел иде. Ул безне сирәк була торган ял көненә, өенә чакырды, шунда йөгерүдән соң сөйләшергә мөмкин булыр, диде.

Гаиләсе белән иртәнге сәгатьләрдә йөгерү яки чаңгыда йөрү – аның өчен генә түгел, гаиләсе өчен дә профессия таләп иткән иң фарыз гамәлләрдән икән! Әгәр дә табиб гайрәтле булмаса, чыныкмаган, камыр булса, ничек итеп ул җидешәр, унар сәгать операция өстәле янында скальпель белән эш итә алсын?!

Бу юнәлештә аның союзниклары – барлык гаилә әгъзалары! Хатыны Галия ханым – медицина хезмәткәре, рентгент аппараты белән эш итүче – шулай ук иренә теләктәш һәм һәр эшендә аңа хәерхаһ. Олы улы Шамил – теләктәш кенә түгел, әтисенең профессиясен турыдан-туры дәвам итүче, доцент. Ә кече уллары Наил – сәламәт һәм көчле булырга кирәклеген өлкәннәрдән яхшы үзләштергән шәһәр администрациясе хезмәткәре, җитәкче!

Бу гаиләдә шунысы күзгә ташлана: монда бер эш тә форма өчен генә эшләнми. Биредә һәр эш кирәк вакытта, кирәккә, файдага һәм җиренә җиткезеп эшләнә. Монда вакытны мавыгуларга, кирәге булмаган шөгыльләргә әрәм итү юк. Барысы – берәү өчен, берәү – барысы өчен! Бөтенесе эш өчен! Ихтимал, болар да гаилә лозунгысыдыр.

Хәер, бу гаиләдә эшне кушып, ягъни шигарьләргә ияреп эшләмиләр. Монда һәркем үз эшен, үз урынын, киләчәген белә.

Без авыр операциядән соң ял итәргә дә ирек бирмичә, аның кадерле вакытын бүлеп, урынлы-урынсыз сорауларыбыз белән борчыган өчен гафу үтендек.

– Нигә алай дип үз эшегезне кимсетәсез? – диде Ринат Харисович, чынчынлап гаҗәпләнеп. Бу эшегез минем өчен дә, Сезнең өчен дә түгел бит. Бәлки кемдер күреп, кемдер ишетеп, кемгәдер әйтеп, кемдәдер яшәүгә, терелүгә өмет уятыр! Кешеләрдә яшәргә, терелергә өмет уяту – зур эш ул!

Чынлап карасаң, безнең төп эшебез кешеләргә гомер өстәү ич!

***

...Язманың эчтәлеген сөйләп бетерүем булды, алдан сөйләшепкилешеп куйгандай, палатага мәһабәт гәүдәле, мыеклы егет килеп керде дә, дәгъватчының аяк очына спортчылар сумкасы куеп: «Массажга әзерлән!» – дип чишенә башлады.

– Онычым шушы була инде! – диде дәгъватчы һәм ничек бу баланың дөньяга килү тарихын сөйләде.

– Сөйләмәсәң дә, барысы «на лице написана», – дигән булдым, ни өчендер русчалап. Дөресен әйткәндә, мин бу уникаль операция турында ишеткәч, аның нәтиҗәсенә ышаныр-ышанмас яшәгән идем. Инде шикләрем тәмам юкка чыкты.

Онык бабасына массаж ясады. Мин аларның үзара сөйләшүләреннән үзем өчен кызыклы ачышлар ясадым.

Инсульт кына түгел, инфаркт та бәргән икән «егеткә». Шикәр авыруы да бар икән. Гаҗәпләндергәне шул: башкалар белән чагыштырганда иң авыр хәлдә ятса да, ул, аягына басып, палата эчендә кирәк урынына бара, гипслы кулы белән кашык тотып үзе ашый. Онычы белән сөйләшкәндә шатлыгы эченә сыймый иде аның. Онычы сорый: «Нигә шатланасың?» – ди. Ул: «Күрмисеңмени – кулым бөгелә, телем әйләнә, бармакларым теләкләремне үти. Димәк, тукталган эшемнең дәвамы озак көттермәс», – дип җавап бирә.

– Эш турында уйлама.

– Эш турында түгел, бурычымны үтәү турында уйлыйм мин, улым.

Соңыннан сөйләшеп белдем: нефтяник улы узган ел кайтуында гранит ташы алып кайткан икән. Ринат Харисовичка һәйкәл эшләргә, ди. Һәйкәл! Үз исәбенә!

– Сынчы һөнәрен беләсеңмени? – дип сорамый булмады.

– Иң мөһиме – мин бурычым барлыгын беләм. Ул минем бурыч кына түгел – күпләрнеке. Илнеке! Милләтнеке! Ринат Харисович гади табиб кына түгел. Ул – милләтебезнең мактанычы! Могҗиза иясе. Башка берәр илдә булса, мондый могҗиза иясенә алтыннан һәйкәл коеп, үз мәктәбен булдырырлар иде.

...Язу эшен ташлагач, мин, кулыма пумала тотып, сурәт ясый башлаган идем. Башлангыч белемем бар иде. Җитмәгәнен үзлегемнән өйрәндем. Ниятем ныклы!

Мине рәссамнарның идеологиягә бәйле булмаулары, үрнәкләре табигатьнең үзе булуы җәлеп итте. Уйлап кара: Сарьян 92гә җитә, Пикассо да иҗатыннан 92 яшендә генә аерыла, Шагал – 98дә, Тициан – 100дә, Микеланджело – 89да дөнья куя.

– Ә Рафаэль белән Ван Гог?

– Алар – интрига корбаннары. Мин интригалар оясыннан читтә, мәрхәмәтле кешеләр канаты астында яшим һәм чын иҗат белән шөгыльләнәм.

– Идеядән качам, дисең. Сынчы сәнгатендә дә идеясез булмый, туган.

– «Өзелмәсен өмет!» – идея була аламы?

– Була ала.

– Мин синең элек язганнарыңны укый алмам. Болай, телдән әйтсәң, төн буе тыңларга да риза. Сөйлә!

...Тормыш күзгә күренмәгән, колакка ишетелмәгән батырлыклар тезмәсеннән тора. Батырлыклар һәм фаҗигаләр тезмәсеннән. Кемдер, кайдадыр көлсә – кемдер, кайдадыр елый. Берәүнең шатлыгы, кемнеңдер хәсрәте. Берәү туа, берәү үлә... Шулай, дөнья яңара, яшәү дәвам итә... Тормыш алга тәгәри.

Вакыты җитми туу булмаса да, үлем-әҗәлнең вакытсыз килгән чаклары еш була. Моңа мисаллар бик күп... Шагыйребез Тукай үлемен генә алыйк. Нибарысы 27 яшьтә! Анасы Мәмдүдә абыстай 22 яшьтә тол кала, 30 яшендә инде ул дөнья куя.

Куз яшең дә кипмичә егълап
вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның
ник китердең ят кеше?!

– ди шагыйрь «Өзелгән өмид» шигырендә.

Иң гайрәтле чагында өметләре өзелеп, гомерләре киселә. Шагыйрьнең дә, әткәсе-әнкәсенең дә.

Бибимәмдүдә абыстай, авылда яшәгәч, өметләндерерлек табибы да, киңәшчесе дә булмагандыр, дип үзебезне ышандырырга тырышсак та, күрә торып шагыйрьләренең сүнүенә юл куйган, өметләре өзелүен үләренә 3 ел кала игълан итсә дә, аны терелтү өчен асылда берни эшләмәгән иптәшләрен ничек аңлыйк? Ул вакытта да медицина булган бит! Акчалы «дуслары» да күп булган.

Үзендә горурлык һәм яшәү өмете уяткан шагыйрен даирәсе өметсезлеккә төшерә. Хәер, нигә әллә кайчан булганнарга карарга! Бүген очрамыймы арабызда гамьсезләр һәм гамьсезлекләр?! Тулып ята!

Әмма безнең сүзебез «өмидләрне» өзүчеләр турында түгел, «өмидләрне» ялгаучылар, «өмид» чаткылары кабызучылар, өметсезләрнең ышанычлысы, дусты, киңәшчесе турында.

Игелекнең олысы, кечесе юк. Ул фәкать, онытылып, бәһасен җуймасын.

Игелекнең әҗере – бары игелек. Игелекле кеше – изге кеше!

«Вөҗдан», «намус», «гаделлек», «игелек»... дибез.

Бу сүзләр еш кабатлаудан кайчак гадәтиләнеп, тирән мәгънәләре беразтоныкланып китә кебек. Әмма вөҗдан, намус, гаделлек, игелек – дөньяны, тормышны, кешелекне яшәтә, тота, тәрәккыяткә илтә торган төп әхлакый категорияләр. Кешенең дә, кешелекнең

кешелеге дә шулар белән үлчәнә һәм бәһаләнә.

«Төп һөнәрең кем?» – дигән сорауга һич икеләнмичә: «Кешеләрне бәхетле итү!» – ди ул.

«Ә бәхет нәрсә ул?» – дигәнгә: «Тигез гомер кичерсәң, максатларыңа ирешсәң, дөньяга сокланып туймасаң – шул бәхет. Ә иң бәхетле кеше үзенең башкаларга кирәк булуын белеп яшәгән кешедер, мөгаен. Мин тоям – мин гаиләмә генә түгел, мине белгән башкаларга да кирәк», – ди Ринат Харисович.

Әйе, башкаларның да бәхетле булуы өчен яши ул. Үзен белә башлаганнан бирле шул юлда, шул хезмәттә.

– Кеше чикләнмәгән рухи көчкә ия. Ул беркайчан да «булмый» дип әйтмәскә, өметсезләнмәскә тиеш! Моның өчен ул иң кимендә гашыйк булырга тиеш! Чөнки бәхетнең бер канаты сәламәтлек булса, икенчесе – мәхәббәт!

Әй, мәхәббәт! Азмы язмышларны
Дөнья тәмугында яндырдың. –
Азмы исемнәрне күккә язып,
Мәңгелек җыр итеп калдырдың!

...Мәхәббәт ул шундый кодрәт, кешенең, гүя, бөтен барлыгын камап ала, яндыра-көйдерә, саргайта. Хәтта бөтен дөньяның тоткасы шуннан гыйбарәт кебек. Һәр җан иясе парлашудан, җенси кушылудан ярала. Хәтта үләннәр дә, чәчәкләр дә, төрле бөҗәкләр дә. Кайбер үсемлек, мәхлук җан иясе бары шуның өчен генә дөньяга ярала.

Чәчәк атып, җимеш бирә дә үлә, балык... уылдык чәчә дә үлә.

Фәкать кеше генә җаны-тәне, бөтен булганы белән сөя һәм... инстинкттан узып, рухи мәхәббәткә күтәрелә.

Шуның белән кеше барлык башка җан ияләреннән өстен, кешеләрчә олы мәхәббәте белән бөек, асыл зат.

«Мәхәббәтле кеше» дибез икән, аңа матурлык, акыллылык, игелеклелек мәгънәләрен дә салабыз. Шулай мәхәббәт әхлакый категориягә әверелә.

...Тормыш шуны раслый: ир белән хатын бар җирдә мәхәббәт бар. Мәхәббәт бар урында гаилә бар, гаилә булса – чын яшәү бар, үрчем бар – бала бар. Мәхәббәтсез тереклек юк, тереклек булмагач – яшәү дә, тормыш та юк. Баласыз тормыш – ул ясалма тормыш.

Гаиләне гаилә итеп тотып торучы, аның яшәү нигезе, яшәү кыйбласы, мәгънәсе, максаты, борчу-шатлыклары – иң беренче чиратта, әлбәттә, бала. Гаиләдә әти, әни, бала булганда гына ул тулы, чын мәгънәсендә бәхетле, мәгънәви эчтәлекле була.

Бу фикер Ринат Харисовичның иҗади яшәү платформасыннан.

«Баласызлыкның нинди фаҗига икәнен бала табудан мәхрүм ханымнар һәм аларның ирләре генә бөтен тирәнлеге белән аңлыйдыр», – ди ул.

Әмма, язмышлар төрле булган кебек, кешеләрнең фаҗигаләре дә төрлетөрле.

Берәү баласызлыктан хәсрәт эчсә, икенчеләре бала хәсрәтеннән кемгә барырга белми. Өченчеләре исә... Безнең сүзебез язмышлары ачы булса да, тормыш сукмаклары игелекле кеше белән очраштырып, яңадан туган кешеләр турында барды.

«Игелек эшлә дә – суга сал!» – дисәләр дә, без: «Игелек суда батмый, утта янмый!» – дибез.

– Кушылам! – диде дәгъватчы. – Инде сиңа бер үтенечем бар. Мин Ринат Харисовичка багышлап шигырь язган идем. Мөмкин булса, шуны катыштыр язмаңа:

Кеше кешеләргә кирәк булсын,
Беркайда да артык булмасын.
Эшләгәндә янып эшләсен дә,
Ял иткәндә көлсен, җырласын!
Сыкранмасын тормышыннан кеше,
Һаман бизәп торсын ул аны.
Куансын ул якты эзен күреп,
Акыллы һәм оста кулының.
Хыяллансын, янсын, канатлансын,
Тынгы белми алга омтылсын,

Сөйсен-көйсен, күркәм булсын кеше,
Халык гаме белән ул тулсын!
Үз кайгысын узар кайгы итеп,
Иң зур бәйрәм көтеп яшәсен.
Шундый бай, бәхетле булыр кебек
Киләчәкнең матур кешесе!

– Киләчәкнең? Бүген юкмыни андый кешеләр?

– Бар! Бар! Ул – Ринат Харисович Галиев. Безнең милләтнең горурлыгы. Мин шагыйрь түгел. Аның турында проза телендә сөйләү остаы кимсетәдер кебек.

Үтә еллар, үтәр күп гасырлар
Һәм ачылыр яңа дөньялар.
Безнең тормыш, безнең әкиятләр
Тарих битләренә оялар.
Бу тарихны карап, киләчәктә,
Киләчәктә, бәлки, көлерләр?..
Ә кем белә, бәлки, безгә кире
Кайтыр өчен сагынып йөрерләр!
Сагынмасалар да, сокланырлар:
Нинди көч, дип, нинди батырлык.
Шул батырлык – безнең матурлыкта!
Ә бит кабатланмый матурлык!

Хастаханәдән чыккач, бу гаҗәеп кеше белән очрашуым, оныгын күрүем турында Ринат Харисовичка шалтыратып әйттем. Ул минем авыруым турында ишетмәгән икән. Икенче көнне өйгә килде. Озак сөйләшеп утырдык. Мин аңа журнал өчен мәкалә язарга теләгем барлыгын белдердем. Бу хәбәргә, әлбәттә, исе китмәде: хупламады да, кире дә какмады. Шулай да кайбер урыннарны ачыклау кирәклеген сиздерде, дәгъватчының исемен әйтте: «Мөслимов Хәйдәр белән бер палатада яткансыз Сез», – диде.

Ә мин, үз чиратымда, «тел очымдагы» сорауларны бирдем:

– Ринат Харисович, әйтсәгезче, нигә авырулар башлыча сезгә эләгергә омтыла? Сез, остаз буларак, һөнәрегезне шәкертләрегезгә бирәсездер, тәҗрибә уртаклашасыздыр. Нигә сез һаман тәхеттә? Гомер уза, яшь бара. Сездән соң ни булыры Сезне борчыймы? Әллә ярышыр остаз (конкурент) булмау абруегызны төшермәү өчен уңай шартмы?

– Бу соравыңда мең ботак, йөз тамыр. Тотып алган кадәренә җавабым шул: менә син – режиссер. Элегрәк куелган әсәр буенча фильм төшергәндә яисә спектакль куйганда элек күргән спектакльдән ни дә булса күчерәсеңме?

– Бу мөмкин түгел, кирәге дә юк.

– Безнең эштә дә шулай.

Хирургның эшен мин режиссер эше белән чагыштырыр идем.

«Зәңгәр шәл»не Марсель* ничә тапкыр куйды. Фәрит** ничә тапкыр. Бер үк әсәр, ә төрле спектакльләр. Әгәр әсәрне һәр куйганда үзеңчә һәм өр-яңадан ачмасаң, кемгәдер иярсәң, стереотип булып чыга. Ә стереотип – «үле туган бала» ул. Аның беркемгә дә кирәге юк. Стереотипка талант тешләре коелган, иҗади гомерләре беткән режиссерлар таяна. (Артистларның да бар стереотипчылары.) Алар, дөресен әйткәндә, алга түгел, ә артка караучылар. Тормозлар. Белемле, яхшы хирурглар күп хәзер. Зирәк, иҗади хирурглар сирәк. Хикмәт – үз һөнәреңне яратуда! Һәр пациентның авыруына өр-яңа, таныш булмаган авыру дип карауда. Кешене яратырга өйрәтеп булмый, ә менә кисәргә, ямарга, беркетергә өйрәтеп була. Рату, күрәсең, Ходайдан.

Бүгенгә шулар җитәр. Калганнары турында син тәмам терелгәч һәм бу язмаң белән кызыксынучы табылса, шәрехләрмен... ■

*Марсель Сәлимҗанов.
**Фәрит Бикчәнтәев.

БЕЗ КИЛМЕШӘК ТҮГЕЛ БУ ҖИРДӘ!

2016 елның 12-16 ноябрендә Екатеринбургта һәм Свердловск өлкәсендә Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды.

Татарстан Республикасының Урал төбәгендәге даими вәкиллегендә узган очрашуда Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург Данил Салихов, «Безнең мирас» журналының баш редакторы, шагыйрь Ләбиб Лерон, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, язучы Нәбирә Гыйматдинова, филология фәннәре кандидаты, язучы һәм шагыйрә Рифә Рахман, ТРның Урал төбәгендәге даими вәкиллеге җитәкчесе Ринат Садриев, вәкиллек хезмәткәрләре Хәйдәр Гыйльфанов, Динария Алетдинова, төбәктәге «Саф чишмә» татар газе-

тасы баш редакторы Фәвия Сафиуллина, Уралдагы язучылар ассоциациясе координаторы Александр Кердан, Россиядәге язучылар берлегенең Екатеринбург бүлеге җитәкчесе Арсен Титов, Россия Язучылар берлегенең Екатеринбургтагы бүлеге җитәкчесе Евгений Касыймов, шагыйрь Вадим Дулепов, Свердловск Мәдәният министрлыгы белгече Светлана Ижгузина, вәкиллек карамагындагы «Каюм Насыйри» үзәге укучылары, «Заман» (Екатеринбург), «Курай» (Березовский), «Йолдыз», «Якташ» (Югары Пышма) иҗат коллективлары, татар эшмәкәрләре һәм башкалар катнашты.

Язучылар шулай ук Свердловск өлкәсендәге татар авылларында, аерым алганда Урта Бугалыш, Сыскы, Рахмангол, Әртә-Шигер, Әҗегол, Уфа-Шигер, Үрмәкәй, Аракай (Әрәкәй), Шәкүр һәм Төрештә булып, халык белән очрашты. Очрашу барышында сүз туган телебезне саклап калу, мирасыбызны барлау, үзара элемтәне тагы да ныгыту турында барды.

Урал төбәгендә милләттәшләребез

гомер-гомергә яшгән, аның үзенчәлекле мәдәнияты, традицияләре, гореф-гадәте формалашкан. Бу җирдә татар халкы һич тә килмешәк түгел!

***Фәвия Сафиуллина** һәм*
***Ләбиб Лерон** фотолары* ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

ҮГДЕЛМЕШ КӨНТУГДЫ ИЛБИКНЕ НИЧЕК АРЫТАБАН ИДАРӘ ИТӘРГӘ ӨЙРӘТӘ

Җавапта Үгделмеш әйтте: – И, илбик,
Һәр эшне чамалап, кулягып күрик.

Яраксыз сүз әйтмә, бу булыр яман,
Ходай мондый эшне һич хушламаган.

Билек алмас идең, хәтта бик теләп,
Бер Алла куймаса сине билгеләп.

Сине кадерләде, биреп билекне,
Шуңа шөкерләрең әйт син, белеклем,

Күңелеңне төз тот, Тәңреңә табын,
Халыкка шәфкатьле гаделлектә бул.

Һәвәсеңне белем белән киртәләп,
Нәфесеңне акыл белән куй бәйләп.

Ни ди, ишет, белек бирүче кешең
(Белек илә баскан һәвәсен – нәфсен):

«Һәвәс муйнын сындыр –
жан, тән сау калыр,
Мин-минлек бөгелсә, күңлең тураер»,

Җаның мин-минлеккә колың булмасын,
Һәвәс, нәфес икәү – бу дин угрысы.

Гаҗиз булдың нигә үзең и, илбик?
Кулыңнан килә ич барча игелек.

Нигә моңаясың бу кадәр каты,
Нигә яшәвеңне кыласың ачы?

Хәзинәң шактый һәм күп гаскәр – сүвең,
Бар эшкә юламан акыл-белемең.

Иратны сөендер – хәзинәң өләш,
Алардан үзеңә мең арзу телә!

Ни ди, ишет, әнә яугир-сугышчан,
Көмеш-алтын белән җиңелә дошман.

Кулың булсын дисәң дошманнан өстен,
Иратны сөендер һәм макта үзен.

Иратны сөендер һәм әйт теләгең,
Ират дошманнарның бирер кирәген.

Иратны күбрәк тот, сөендер аны,
Алар синең өчен бирәчәк җанын.

Ират – сүвең[1] илә кяферен яньче,
Ходайдан көч телә. Ул – таянычың.

Корал-ярак кирәк кяфергә каршы,
Кяфер бетте, димә, кяфер ул сансыз.

**Һәвәсеңне белем белән киртәләп,
Нәфесеңне акыл белән куй бәйләп.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.
[1] Ират – монгол сүзе «ирләр, профессионал хәрбиләр», сүв – «гаскәр».

Өен-җаен үртә, сындыр путларын[2],
Алар урынына мәчет сал тагын.

Углы кол, кызы kөң итеп алынгач,
Хәзинә тупла бар үлҗә малыңнан.

Шәригатьне өйрәт, мөселманлыкны,
Рухың изге булыр, атың – данлыклы.

Мөселманнарга кул тидермә, илбик,
Аларның якчысы Алла үзе бит.

Һәр мөселман кардәш һәр мөселманга,
Аңар каты булма, иге бул аңар.

Канун бир халыкка – тынычлык тапсын,
Кылсын, батыр, сиңа хәер-догасын.

Ходай бирер шуннан сөенеч-әҗер,
Шуннан сиңа ике дөнья да әзер.

ИЛБИКНЕҢ ҖАВАБЫ

Илбик әйтте: – Син бик матур сөйләдең,
Үзем дә нәкъ шулай эш итәр идем.

Бу кадәр эшкә тик ничек җитешим?
Син миңа ярдәм ит – шулай килешик.

Тәүләп илне сөзеп чистарту кирәк,
Күп эчке һәм тышкы эш күверәрәк[3].

Сөярне сөендер бүләкләр биреп,
Ә сөймәгәннәрне түк син себереп.

Сугыштан соң илне ил итү кирәк:
Арулансын эчке, тышкы кибетләр.

Соңра урнаштырыйк төгәл кагыйдә:
Чүбеге сөзелсен, калмасын илдә.

Ничек моны эшлик – уйлыйм йокысыз,
Эш өстенә эшләр ябрыла көндез.

[2] Пут – «Будда статуясы».
[3] Күверү – «башкару, хәстәрләү, булдыру».



Эшләсәң эшеңне шәпләп һәр көнне,
Халкыңа, үзеңә килер иркенлек.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавап, Үгделмеш башлады: – И, бәк,
Озайтма эшеңне, тотын җәһәтрәк.

Нигә сузасың син кылыр эшеңне,
Гомер узасы ич, кара яшеңне.

Бүген эш бетмәсә, кала шул килеш,
Һаман да өстәлә һәр көн яңа эш.

Эшләсәң эшеңне шәпләп һәр көнне,
Халкыңа, үзеңә килер иркенлек.

Яманлыкны кылсаң, яманнарга кыл:
Барча яманлыктан азат булсын ил.

Тугры бул, туры тот юсык-юрыкны,
Тугрылык турайта кәкре холыкны.

Ишет, нәрсә дигән күңле төз кеше,
Сүзе, эш-кылыгы керлексез кеше:

**Белекле һәм ушлы булса бер яугир,
Бүләклә, хөрмәтлә, аңар кулың бир.**

«Яманга юлама, туры юлдан йөр,
Бул яхшы, бул яман – хөкем көне бер».

Яманлыклар кылсаң, мәшәкатъ артыр,
Турыга туры бул, катыга – каты.

И, илбик, ираттан үзгә чара юк.
Гаскәр белән генә сөзелер болганчык.

Эшең – гаскәр җыю һәм тәртип кую,
Ярлыны баету, ачны туйдыру.

Эш өчен хезмәтче ял өмет итә,
Өмете киселсә, әлбәттә, китә.

Хезмәтче, илбигем, күптөрле була:
Син аларны күзәт – чыкмагай юлдан.

Абруйны сакларга тиеш кайбере,
Андыйны хурлама, сакла кадерен.

Кайберенә матди казаныш кыйммәт,
Бир әйбер шундыйга, күңелен кыйма.

Телидер кайбере дан һәм затлы тун,
Китәрмә син аның данын, йөз суын.

Шәп сәргаскәр тапсаң, аңар акча бир,
Кылыч орыр, сиңа улус арттырыр.

Белекле һәм ушлы булса бер яугир,
Бүләклә, хөрмәтлә, аңар кулың бир.

Исәр-усал булса аны күтәрмә,
Ил өстеннән аңар хакимлек бирмә.

Исәр горурны да көчәйтә күрмә:
Сиңа ул агу да бирәчәк бермәл.

Ләкин яхшының да, төшсә тарлыкка,
Холкы бозылачак, моңаер юкка.

Фәкыйрьлектә, төптән яхшы булса да,
Яман җене калкыр кайбер инсанда.

Исәр-ахмакларны күр дә тәкъдирлә,
Һәм акыллылыкны күр дә тәгъбирлә.

Рәхимле кешене күтәр һәрьяктан,
Оятсызны ерак тот, аннан саклан.

Нәрсә файдалы һәм ниләр хур итә –
Кешеләргә илбик үзе белдертә.
Сөюче-сөймәүче кемсәләрне бел,
Сөйгәнне сөяр бул, дошманга ут бул.

Синең шатлыгыңа сөенми икән,
Андый кешеләрне ерак тот эштән.

Әманәтне катма хыянәткә син,
Яхшы белән яман бергә ятмасын.

Бер эшне берьюлы әйтмә икәүгә:
Теләмәс берсе дә аны үтәргә.

Эшеңне белгәнгә, акыллыга бир,
Кулыннан килмәгән кайгы китерер.

Ашыкма эшеңә эштәш дәшәргә —
Файдалыны чакыр ярдәмләшергә.

Илең-үзең өчен файда телә син,
Кирәкмәгән кеше файда күрмәсен.

Кеше күңлен күреп, бозылмасын заң,
Илең мәнфәгате иң өстен калса.

Сиңа файда булсын һәм булсын аңар,
Файдасыз кемсәне читләт, ку, чыгар.

Кадерләп тот файда китергәннәрне,
Сине аңлап, илбик, эш күргәннәрне.

Шулай итсәк кенә, илбик, эш уңар,
Илеңдә кешеләр тыныч булсыннар.

Атың булыр изге, тынычлык табып,
Искә алыр сине, сүзеңне халык.

**Синең шатлыгыңа сөенми икән,
Андый кешеләрне ерак тот эштән.**

Халык баер шунда, тәхетең ныгыр,
Теләгәнең кадәр казна җыелыр.

Ни ди, ишет, әнә миһербанлы зат
(Табигате рыя – ялганнан азат):

«Каю илбик башлы һәм күңле изге,
Шуның көне якты һәм байый иле.

Ил – халык байлыгы – шәрәф илбиккә,
Шулчагында чыга ил иркенлеккә».

Азат ит илеңне син угрылардан,
Юлларда йөрсен куркусыз кәрван.

Ил эченнән китәр көчлекчеләрне,
Илбасар кермәсен – ныгыт чикләрне.

Кыйна да, кылыгын үзгәрт яманның,
Яманга яманлык бик тә таман ул.

Яманның урыны – ур[4], бикле төрмә,
Төзәлсен тәртибе, и, ныклы йөрәк.

Аер – илнең халкы төрле-төрле ул,
Аешын бел, ачык-аян булыр юл.

Бере – галим, белкә, иң өстен торыр,
Галим халык – илгә бәхет яудырыр.

Галимне хөрмәтлә, тот әйткәннәрен,
Гыйлем-шәригатьтән өйрәткәннәрен.

Болар хакын тыйма, ашат һәм эчер,
Барын бир, моңайтма, и, ил башы ир.

Алар тыныч кына гыйлем өйрәтсен,
Белексезләр андин гыйлем өйрәнсен.

Галимнәрдән сора, мөхтәсиптән – кем
Тәртип урнаштырыр көчле кул хәким.

Хөкемнәре кыска фасикъ-рәтсезгә,
Каты тота мәчет җәмәгатен дә.

Кыйна да, кылыгын үзгәрт яманның,
Яманга яманлык бик тә таман ул.

Аерым бер төркем – иярченнәрең,
Тыймасаң, беләсең сине чәйнәвен.

Болар йөк күтәрми, аларның йөге
Сиңа, «күтәреш», ди һәрбер имгәге.

Болардан тыш тагы кара халык бар.
Аларга гадел бер хөкем алып бар.

Аларда өч котый[5] ачык аерыла
(Көчләшсәң, һәркайсы давылдай була):

Байлар – беренчесе. Алар тавышчан
Һәм илдә иң көчле, и, рәхимле җан.

Болардан соң, күрче, килә урталар.
Байлар кылган эшне кылмаслар алар.

Болардан соң инде ярлы гаммәсе,
Боларның күзәтү кирәк һәммәсен.

Йөкләмә бай йөген урта хәллегә —
Бозылыр урталар, йөклә әз генә.

Фәкыйрьгә йөкләмә хәллеләр йөген:
Фәкыйрь ачтан үлер, өзелер мескен.

Фәкыйрьне куәтлә – уртадай булсын,
Урта исә, тынып, үзе бай булсын.

Ярлы урта булса, урта булыр бай,
Байларның күплеге илбиккә уңай.

Ил хәлләнер, рәхәт тияр халыкка,
Сиңа бар да рәхмәт әйтер байлыкта.

Ни ди, ишет, әнә Өч Урда ханы:
— Үлсәң дә калсын, ди, бер изге даның.

Изге даның барда, әгәр, чыкса җан,
Атың мәхрүм булмас изге догадан.

Дәвамы бар ■

[4] Ур – тирән окоп, хибесханә.
[5] Котый – кучерелмә «сорт» мәгънәсендә килгән.

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)

Йөзбашы Эрдене әлеге тирмәгә якынлашты, күрәсең, анда аны көтеп торырга тиешләр иде. Тирмәдән башына яулык бөркәнгән хатын чыкты һәм ишек төбендә аны каршы алды.

– Самбайну (исәнме – монголча), – дип, тавышын басып кына, хатынны сәламләде ул. Борчылып сорады:

– Йә, хәлләр ничек?

– Барысы да тәртиптә, Күк-Тәңрегә шөкер, бөтенесе әйбәт килеп чыкты. Хәзер инде борчылма, – дип пышылдады хатын. – Ул сине бик көтә. Ишетәсеңме, бик көтә.

– Мин үзем дә күңелем белән аңа таба ашкындым! – дип җаваплады йөзбашы. – Тик, үч иткәндәй, безнең нойон атларны кабат санарга булды. Өч көн буе шуннан котыла алмадым, ат көтүләре арасында югалып тордым.

– Йә, борчылмасана, Эрдене. Шундый хәл килеп чыккач, син ни кырган булыр идең?!. Монда кеше күзенә чалынып йөрүдән ни мәгънә? – Хатын аны тынычландырып башын чайкап алды һәм өстәп әйтте. – Иң мөһиме – шулай тыныч кына, җиңел генә тапты. Бер мәртәбә кычкырмады да, түзде. Ә иртән мин аны ябык олауга урнаштырдым. Берни дә булмаган кебек. Ул – синең менә дигәнең. Әй, нәрсә сөйләнеп торам соң әле! – дип, кинәт сүзен бүлде ул. Котлап:

– Кулыңа кунган лачын һәрвакыт синең белән булсын! – диде. – Инде улыңа исем тап!

– Сүзләреңне Күк ишетсен иде, Алтун! Догулаң белән үлгәнче сиңа рәхмәтле булырбыз, – йөзбашының тавышы калтырады. – Ә исемне уйларбыз, анысыннан гына тормас.

Хатынга атның тезгенен тоттырды.

– Борчылма, һәрвакыттагыча, күпме кирәк – шултикле сакларммын, – дип ышандырды Алтун. – Бар инде, бар, Догулаң сине зарыгып көтә..

Йөзбашы, кыюлыгын аяк табанына туплаган кебек, бераз таптанып торды, аннары тирмә авызына килеп, авыр тыгыз киез чаршауны аз гына ачты һәм, иеләтөшеп, эчкә узды. Тирмә уртасында кечкенә генә учак янып тора, ә шул учакның көчсез, тонык яктысында ул аны – иңнәренә сусар тунын салып, эчтә үк утырган Догулаңын күрде. Аның каршысында – сырган юрган капланган бишек, хатын уң кулы белән бишекне җиңелчә генә тирбәтә иде.

– Эрдене! Мин монда, – дип, йөзбашының керүен сәламләгәндәй, әкрен генә эндәште Догулаң. Аннары:

– Без монда, – дип, уңайсызланган кебек, елмая төшеп, үз-үзен төзәтте.

Йөзбашы тиз генә ук садагын, җәясен, кынындагы кылычын ычкындырды, коралларын ишек төбендә калдырып, кулларын сузып, хатын янына килде. Тезләнде һәм алар йөзгә-йөз орындылар, иңнәренә башларын куеп кочаклаштылар һәм шул көе тынсыз тордылар. Дөньялары бермәлгә шушы тирмә гөмбәзе астында йомылып калды. Бу тирмәнең тышындагы бар нәрсә әһәмиятен, кыйммәтен югалтты кебек. Бары тик алар икәве, аларны берләштергән бер-берсенә ашкыну хисе һәм өч көн элек дөньяга килеп, инде бишектә изрәп йоклаган йодрык хәтле җан иясе генә торып калды.

Эрдене беренче булып телен тибрәтте:

– Йә, хәлең ничек? – дип сорады ул, ешлаган сулышын көчкә тыеп. – Мин шулхәтле борчылдым.

– Инде барысы да артта калды, – дип җаваплады хатын, ярым караңгыда елмаеп. – Аларны уйлама. Аның турында – безнең улыбыз турында гына сораш. Ә ул шундый тере, нык булып чыкты. Имиемне шундый каты итеп суыра. Ул сиңа бик охшаган. Алтун да шулай ди.

Башы журналның 8 нче санында. Тәрҗемәче – Мөдәррис Вәлиев.

– Миңа күрсәт аны, Догулаң. Бер күз салыймчы?!

Догулаң читкәрәк тайпылды һәм, бишек өстендәге юрганны ачар алдыннан, ирексездән сагаеп, тыштагы авазларга колак салды. Тирә-юньдә тирән тынлык иде.

Йөзбашы йоклап ятучы нарасыйга, аның әлегә берни дә аңлатмый торган йөзендә үз чалымнарын табарга тырышып, озак карап торды. Тынын кысып яңа туган сабыена текәлгәндә, ул, бәлки беренче тапкырдыр, мәңгелектән бер хәбәр-билге булып, дөньяга нәсел дәвамчысы килүенең илаһи асылына төшенгәндер. Мөгаен, шуңа да, һәр сүзен бизмәнгә салып үлчәгән кебек әйтеп куйды:

– Менә мин хәзер һәрвакыт синең яныңда, Догулаң, хәтта минем белән ни генә булса да, һәрвакыт синең яныңда. Чөнки синдә – минем улым.

– Син – минем белән? Шулай булсачы! – Хатын сагышлы көлемсерәде. – Будда тәгълиматындагы кебек, сабый – синең икенче чагылышың, дип әйтмәкче буласыңмы? Мин, аны имезгәндә, бу турыда уйладым. Әле өч көн элек булмаган җан иясен кулыма алып, күңелем белән сиңа эндәштем: әй, Эрдене, бу бит – синең яңадан тууың! Үзең дә хәзер шулай дип уйладыңмы?

– Уйладым. Тик бөтенләй үк алай түгел. Мин үземне Будда белән чагыштыра алмыйм.

– Чагыштырмасаң да була. Син – Будда түгел, минем байрагымдагы аждаһа. Мин сине аждаһага охшатам, – Догулаң ягымлы итеп пышылдады. – Мин һоруңнарга аждаһалар чигәм. Аларның барысы да син икәнен берәү дә белми. Минем бөтен әләмнәремдә – син. Кайчак төшемдә дә күрәм, мин аждаһа сурәтен чигәм, имеш, ә аңа җан керә, тик син көлмә генә, төшемдә аны кочаклыйм икән, без бергә кушылабыз да, аждаһа мине үзе белән алып китә, без очабыз, мин дә аның белән очам, һәм иң татлы мизгелдә ул аждаһа син булып чыгасың. Төшемдә син минем янымда – әле аждаһа, әле адәми зат. Уянгач, мин нигә дә юрарга белмим. Сиңа бит, Эрдене, элек тә әйтә идем, син – минем утлы аждаһам, дип. Юк, шаярып түгел. Ул шулай иде дә. Мин сине, синең аждаһадагы чагылышыңны байракларга чигәм. Инде менә мин аждаһадан бала таптым булып чыга.

– Үзеңә ничек ошый – шулай булсын. Тик, тыңла әле, Догулаң, минем нәрсә әйтәсем килә. – Йөзбашы тынып торды да аннары телгә килде: – Менә хәзер, балабыз тугач, безгә ни кылырга икәнен уйларга кирәк. Һәм хәзер шул турыда сөйләшик. Әмма минем баштан ук, син белеп торсын өчен әйтәсем килә, хәер, болай да беләсең, шулай да барыбер әйтәм: мин һәрвакыт сине сагынып яшәдем һәм һәрвакыт сине сагынып яшим. Ә иң курыкканым – сугышта башымны җуюу түгел, шул сагынуымны югалту, аннан аерылу. Мин һәрвакыт уйлый идем, гаскәрләр белән йә бер, йә икенче якка киткәндә, сагынуымны, ул минем белән бергә һәлак булмасын, ә синең белән яшәсен өчен, үземнән ничек аерып калдырырга, дип. Һәм берни дә уйлап таба алмый идем, шулай да ул йә кошка, йә, бәлки, җанварга, шундыйрак берәр җан иясенә әверелсен, мин аны синең кулларыңа бирер идем дә, мә, ал, бу – минем сагынуым, ул һәрвакыт синең белән бергә калсын, дияр идем. Ул чакта мин һәлак булсам да курыкмыйм. Менә хәзер аңлыйм инде – минем сине сагынуымнан улым туды. Ул хәзер һәрвакыт синең белән булыр.

– Тик без әле аңа исем кушмадык. Син улыбызга исем уйлап таптыңмы? – дип сорады хатын.

– Әйе, – диде йөзбашы. – Син риза булсаң, аны яхшы исем белән атыйк – Кунан булсын!

– Кунан?!

– Әйе.

– Бик яхшы. Кунан! Яшь чабыш аты.

– Шулай. Өч яшьлек ат. Көченең иң куерып килгән чагы. Ялы да давыл кебек, тояклары да кургаштай.

Догулаң сабый өстенә иелде:

– Тыңла, атаң сиңа исемеңне әйтер!

Һәм йөзбашы Эрдене әйтте:

– Исемең синең – Кунан. Ишетәсеңме, улым? Исемең синең Кунан булыр. Дөрестән дә шулай.

Бу мизгелнең кабатланмас әһәмиятен тоеп, алар тынып калдылар. Төн тыныч иде, бары тик күрше табырда бер эт болай гына өргән булып алды даерактан озак итеп кешнәгән тавыш килде – мескен ат төн уртасында тауларын, йөгерек елгаларын, куе үләннәрен, башка атларның аркасында уйнаган кояш яктысын исенә төшергәндер, бәлки... Исемле булып алган нарасый тыныч кына йоклый һәм аның сабыйлык язмышы әлегә аның белән янәшә йоклап ята иде. Әмма озаккамы?

Йөзбашы Эрдене зур учы белән мыегын сыпырды, тынлыкны бозып, авыр сулап куйды.

– Мин балабызның исеме турында гына уйланмадым. Башкасын да уйладым, Догулаң. Үзең аңлыйсың, яңа туган сабый белән монда калырга ярамый сиңа. Тизрәк китәргә кирәк.

– Китәргә?

– Әйе, Догулаң, китәргә һәм никадәр тизрәк булса, шулкадәр яхшырак.

– Мин дә уйладым, тик кая китәргә, ничек китәргә? Ә син нишләрсең?

– Хәзер әйтәм. Без бергә китәбез.

– Бергә? Бу бит мөмкин түгел, Эрдене!

– Бары тик бергә. Ә башкача була аламы?

– Тик син, баравыл йөзбашы, ни сөйләгәнеңне уйла!

– Мин инде уйладым, ныклап уйладым.

– Әмма син хакан кулыннан кая китәрсең икән, дөньяда андый урын юк! Эрдене, акылыңа кил!

– Мин инде барысын да уемнан кичердем. Мине тыныч кына тыңлап бетер. Хәтерлисеңдер, без башта, күп кешеле, базарлы һәм сукбайлы калаларда туктап торганда, качып-посып йөрмәдек. Мин сиңа ул көннәрдә болай гына әйтмәдем ич, Догулаң: килмешәкләр чүпрәк-чапрагына төреник тә, шулар арасында югалып, илдән илгә йөрербез, дип.

– Нинди илләрдә, Эрдене? – Чигү остасы ачынудан кычкырып җибәрде. – Кайда ул безгә үзең теләгәнчә яши торган җир? Ханнан китүгә караганда, Ходайдан качу җиңелрәктер. Шуңа күрә без кыймадык та, үзең аңлыйсың. Гаскәрдән кем шундый адымга бара алыр икән?! Менә без курку һәм мәхәббәт арасында үзебезнең яшерен тормышыбыз белән калдык та – сиңа гаскәрдән китәргә ярамый, китсәң, башыңны җуясы идең, ә мин синнән китә алмадым, югыйсә, бәхетемне югалткан булыр идем. Инде хәзер без ялгыз түгел. Улыбыз белән бергә...

Өсләренә ябырылып килгән, тау-ташлар ишелгәнгә тиң шомны күз алдына китерүдән, аңлаудан тирмәдә авыр тынлык урнашты. Шулчак йөзбашы әйтеп куйды:

– Кешеләр хурлыкка калудан, мәсхәрәләнүдән, хыянәт өчен җавап тотудан качалар; аларга бары тик газиз башларын гына саклап калырга кирәк, – шулай еш булгалап тора. Безгә исә язмыш бала бәхете бүләк иткәнгә күрә качарга туры киләчәк, тик шундый ук корбаннар бәрабәренә. Рәхим-шәфкать көтәсе юк. Хакан үзенең боерыгыннан беркайчан кире чигенмәячәк. Әле соңга калганчы китәргә кирәк,

Догулаң, бүтәнчә котылу юлы күренми. Башыңны чайкама. Бүтән чара юк. Бәхет белән бәхетсезлек бер тамырдан үсә. Бәхетле чакларыбыз булды, инде бәладән дә куркып калмабыз. Китәргә кирәк.

– Сине аңлыйм, Эрдене, – дип, хатын әкрен генә әйтеп куйды. – Хаклысың, әлбәттә. Тик мин менә уйлыйм, кайсысы яхшырак – үлүме, әллә зур корбаннар хисабына исән калумы? Сүзем ул турыда түгел. Синең белән шулхәтле бәхетле мин, үземә-үзем әйткәнем бар: кирәксә, үләм, тик синнән миңа килгәнне үтерә алмыйм. Диванамы мин, әллә акыллымы, әмма мондый җинаятькә кулым бармады...

– Үзеңне газаплама, кирәкми, яшәргәме яки яшәмәскәме, – син болай өзгәләнергә тиеш түгел! Без әле тумаган җанны корбан итәргә теләмәдек. Хәзер ул туды. Инде без аның өчен яшәргә тиешбез. Качарга һәм яшәргә! Без икебез дә улыбыз тууын теләгән идек ләбаса.

– Үзем, димим. Мин – һаман башка нәрсә турында. Син әйтә аласыңмы, әгәр мине җәзаласалар, синең белән улыңны исән калдырырлармы?

– Алай ук кирәк түгел. Мине түбәнсетмә, Догулаң. Сүз ул хактамыни?! Иң яхшысы – син үз хәлеңне әйт: үзеңне ничек хис итәсең? Юлга чыга аласыңмы? Син арбада Алтун белән барырсың, ул безгә ярдәм кулын сузарга әзер. Мин, атка атланып, янәшәгездә булырмын, берәр хәл килеп чыкса, саклап калыр өчен...

– Ничек әйтәсең, – чигү остасы бу юлы сүзне кыска тотты. – Тик синең белән! Бергә, янәшә булырга...

Бишек өстенә башларын иеп, алар янә тынып калдылар.

– Әйт әле, – кабат сүз башлады Догулаң, – тиздән гаскәр Җаек ярларына чыга, диләр. Алтун кешеләрдән ишеткән.

– Ихтимал, ике көннән булыр, алай ерак калмады инде. Ә су баса торган урыннарга иртәгә үк барып җитәрбез. Анда әрәмәлекләр башланачак, куаклар да чытырманлыклар, алар артында – Җаек.

– Зур, тирән елгамы ул?

– Иделгә таба бару юлында иң зурысы...

– Тирәндәме?

– Теләсә нинди ат йөзеп чыга ала торган түгел, бигрәк тә каты агымлы төшләрендә. Култыкларында – саерак.

– Димәк, тирән инде, ә агымы?

– Көзге кебек ялтырап ята, кызурак аккан урыннары да бар. Син беләсең бит, минем балачагым Җаек далаларында узды, – безнең нәсел шул яктан. Җыруларыбызның да бөтенесе Җаектан. Безнең җырулар – айлы төннәрдә җырлана торган...

– Исемдә, – дип уйчан гына әйтеп куйды Догулаң. – Син, ничектер, миңа бер җыруыгызны җырлап күрсәткән идең, хәзергә хәтле оныта алмыйм, сөйгәненнән аерып алгач, Җаекта батып үлгән кыз турында иде ул.

– Бик борынгы җыру...

– Бер хыялым бар, Эрдене, ак ефәк тукымага шундый чигеш чигәсем килә: су тынган, җиңел дулкыннар гына аның өстен бераз шадраландырып тора, тирә-юньдә үсемлекләр, кошлар, күбәләкләр, әмма кыз инде юк, ул кайгысын күтәрә алмаган. Бу чигешне кем күрсә, шуңа сагышлы елга өстендәге хәсрәтле җыру ишетелсен иде.

– Бер көннән сиңа ул елганы күрү насыйп булыр. Мине дикъкать белән тыңла, Догулаң. Син иртәгәсе кичкә әзер торырга тиешсең. Алмаш атны иярләп, мин килеп җитүгә, теләсә кайсы сәгатьтә бишекне алып чыгуың кирәк булачак. Мыштырдарга ярамый. Озак кыймылдау хәтәр хәзер. Мин бүген, әле үк сезне теләсә кай якка

алып китәр идем. Тик әйләнә-тирәбез – ачык дала, беркайда күмелеп, яшеренеп тора алмыйсың, бөтенесе уч төбендәге кебек, өстәвенә, төннәре дә айлы бит әлегә. Ә арттан куа чыксалар, арба белән дала буйлап ерак китеп өлгерермен, димә. Менә алда, Җаекка табарак, куе әрәмәлекләр башлана, анда инде бөтенесе икенче төрле булачак...

Алар, бер кисәк кенә тынып калып, аннары яңадан үзләрен нинди билгесезлек, нинди язмыш көтәргә мөмкин икәнлеген тәфтишләп, – хәзер инде бу, яңа туган бала белән бергә, өчесенә уртак язмыш иде, – бик озак сөйләштеләр. Сабый да озак көттермәде, бу әңгәмәдә катнашасы килгән сыман, ыңгырашып, бишегендә кыштырдый башлады һәм, шыңшыган эт баласыдай чыелдап, бераздан елап җибәрде. Догулаң аны җәһәт кенә кулына алды һәм, әле ияләшмәгәнлектән уңайсызлана төшеп, ярым борылган хәлдә ими каптырды. Кайнар дәрт белән хисапсыз күп тапкыр үбелгән, ап-ак шома күкрәктән калкып чыккан ул имиләр йөзбашына шулхәтле таныш, якын, ул аларны, үзалдына гына, камыш арасында качып торучы үрдәкнең йомры аркасына охшата иде. Хәзер инде барысы да яшь ананың мәхәббәтеннән нур алып торачак. Йөзбашының күзләре гаҗәпләнүдән һәм сокланудан яктырып китте, нәрсәдер исенә төшеп, дәшми-тынмый гына башын боргалады, – соңгы көннәрдә ул шулхәтле күп кичерешләр эчендә яшәде һәм менә табигать билгеләгән мөддәт эчендә буласы эш барып чыкты: ул – ата, Догулаң – ана, аларның уллары бар, анасы әнә сабыена күкрәк сөтен имезә... Ул баштан ук шулай булырга тиеш иде. Табигать кушуы белән, үләннән үлән ярала, җанвардан җанвар туа, кеше генә, үз талымына карап, шул табигый кануннарның юлына аркылы төшәргә мөмкин...

Сабый, иреннәрен чупылдатып, ими суыра, үзенең күңелен күргән «ак үрдәк»нең тәмен-татын тоеп кинәнә.

– Әй, кытыкланам, – дип сөенеченнән көлеп җибәрде Догулаң. – Менә бит нинди җитез малай булып чыкты. Күрдеңме, ничек килеп ябышты, инде аерып алып булмый, – дип сөйләнде ул, үзенең бәхетле көлүеннән аклангандай. – Ә чынлап та ул, безнең Кунан, сиңа бик охшаган. Бәләкәй аждаһабыз, дәү аждаһаның улы! Менә күзләрен ачты! Кара инде, кара, Эрдене, күзләре дә синеке, борыны да шундый ук, иреннәре дә тач коеп куйган кебек...

– Охшаган, билгеле, бик охшаган, – дип рәхәтләнеп килеште йөзбашы. – Кемнедер таныйм мин анда, бик таныйм.

– Ничек кемнедер? – Догулаң, аптырап, аңа карады.

– Билгеле, үземне инде, үземне!

– Ә син менә аны кулыңа ал да бераз тотып тор. Нәкъ инде тере кечкенә йомгак. Шундый җиңел. Куян баласын тоткандай.

Йөзбашы баланы кыюсыз гына кабул итеп алды, – ул мәлдә үз кулларының көче һәм саллылыгы артык, урынсыз булып чыкты һәм ни кылырга, көрәктәй зур учларына нарасыйның мамык кебек гәүдәсен ничек җайлап куярга белмичә, ул аны сак кына күкрәгенә кысты, дөресрәге, йөрәк тибешенә якынайтты һәм моңарчы таныш булмаган наз тойгысын ни белән чагыштырып була икән, дип, шул мизгелдә биләп алган кичереш-тойгыларыннан бәхетле елмаеп, дулкынланган тавыш белән әйтте:

– Беләсеңме, Догулаң, бу – куян баласы түгел, кулларымда – минем йөрәгем..

Бәләкәч тиздән йоклап китте. Йөзбашына да инде гаскәрдәге үз урынына кайтырга кирәк иде.

Төн уртасында сөеклесенең тирмәсеннән чыгып, йөзбашы Эрдене көзге Сарүзәк өстендә сарымай кебек балкыган айга карап алды һәм үзенең тома ялгызлыгын тойды. Аяклары китмәскә карышты, яңадан Догулаңга, улы янына әйләнеп керәсе

килде. Төпсез дала төненең колакларны чыңлаткан серле авазлары йөзбашын сихерләгән кебек иде. Бүген бу тирмәдә акылга сыймаслык, шомлы хакыйкать ачылды: язмыш тарафыннан бөек хаканның гамәлләренә тартып кертелгәнгә, аның белән бергә Кояш баешына таба яуга чыкканга, аңа хезмәт иткәнгә күрә, үзләре үк куркыныч астында калдылар –теләсә кайсы мәлдә хаканның бала туган өчен котылгысыз җәзасы аларны бик зур кайгыга салырга мөмкин иде. Бәс, шулай булгач, аларны Дөньяның Дүрт Тарафына Әмер бирүче белән бәйләгән көч табигатькә каршы, моннан соң үз тормышлары белән сыешмый, берсен-берсе юкка чыгара торган нәрсә икән, шул нәтиҗә генә сорала – китәргә, ирек алырга, баланың тормышын саклап калырга...

Тиздән ул хезмәтче хатынны эзләп тапты, бу вакыт дәвамында Алтун, сәфәр капчыгыннан бөртек белән сыйлап, аның атын саклап торган иде.

– Йә, ничек, нәни улыңны күрдеңме? – дип каршы алды хатын.

– Әйе, рәхмәт, Алтун.

– Исем куштыңмы?

– Аның исеме – Кунан!

– Әйбәт исем. Кунан.

– Әйе. Күк ишетсен. Ә хәзер, Алтун, мин сиңа бер сүз әйтәм, аны башка вакытка калдырырга ярамый. Син миңа кыз туганым кебек, Алтун. Ә Догулаң белән аның баласы өчен – язмыш тарафыннан җибәрелгән тугрылыклы ана. Син булмасаң, без аның белән бергә сәфәр чыга алмас, аерылу газабы кичереп яшәр идек. Һәм кем белә, бәлки, бүтән беркайчан да очраша алмас идек. Чөнки яу белән баручы сугышны икеләтә каршы ала... Мин сиңа рәхмәтле...

– Мин аңлыйм анысы, – дип сүз кыстырды Алтун. – Нәрсәнең нәрсәгә икәнен бик аңлыйм. Син дә бит, Эрдене, шундый колак ишетмәгән эшкә бардың! – Алтун башын боргалап алды һәм өстәп әйтте: – Ходай биреп, барысы да яхшылык белән узып китсен... Мин аңлыйм анысы, – дип дәвам итте ул, – бу зур гаскәрдә син бүген йөзбашы, ә иртәгә меңбашы-нойон булуың да бар, бөтен гомереңә җитәрлек дәрәҗәле кеше. Ул чакта инде без хәзер серләшә торган нәрсәләр турында сөйләшмәс тә идек. Син – йөзбашы, ә мин кол. Шуның белән барысы да әйтелеп бетә, ләкин син башка юлны сайладың – күңелең кушканны. Сиңа ярдәмем бит – атыңны тотып тору гына. Үзең беләсең, мин Догулаңыңа хезмәт итәргә, аңа эшендә булышырга билгеләнгән кеше. Шулай да мин аңа бөтен күңелем белән бәйле, чөнки ул, – миңа шулай тоела, – матурлык алласының кызы. Әйе, әйе! Ул үзе дә чибәр, әлбәттә! Тик мин бу турыда гына түгел әле. Башка нәрсә турында. Догулаң кулында тылсымлы көч: җеп йомгаклары һәм тукыма кисәге теләсә кемдә булырга мөмкин, тик Догулаң чиккәнне берәү дә кабатлый алмас. Үземнән беләм. Аның аждаһалары, һоруңнар буйлап, тере кебек йөгереп йөриләр. Тукымасындагы йолдызлар да күктәге шикелле чекерәеп яна. Әйтәм бит, аның осталыгы Ходайдан килә. Мин дә аңардан аерылмас идем. Әгәр инде китәргә уйласагыз, мине дә үзегез белән алыгыз. Качып баргандагы сәфәрдә аңа үзенә генә кыен булачак, әле бит тапты гына.

– Сүзем дә шул турыда, Алтун. Иртәгә, төн уртасына таба, әзер булып торырга кирәк. Китәбез. Догулаң һәм бала белән син арбада булсаң, ә мин бер кырыйдан, атка атланып, алмаш атны иярләп барырмын. Җаек болынында китәрбез. Иң мөһиме – таң атканчы ераграк китеп яшеренергә, иртән иртүк куа чыксалар, эзгә басмасыннар берүк. Ә аннары үз юлыбызда булырбыз.

Тынып калдылар. Ияргә утырыр алдыннан йөзбашы Эрдене, башын иеп, Догулаң белән икесенә аның язмыш тарафыннан җибәрелгәнен аңлап, Алтунның, күп ел-

лар элек Кытай якларында әсирлеккә төшкән, шул көннән алып картаеп беткәнче Чыңгызхан олауларында хезмәтче булып калган бу кечкенә буйлы хатынкайның арык кына учын үпте. Әгәр уйлап карасаң, кем иде соң ул аңа – үзенең чоңгылына суырып алган Кояш баешына яу сәфәрендә очраган юлдаш кына бит. Әмма, асылда, гашыйкларның, алар өчен иң хәтәр вакытта, бердәнбер һәм тугрылыклы таянычы булды. Йөзбашы аңлый иде: дөньяда ул беркемгә дә, беркемгә дә түгел, бары тик аңа – хезмәтче Алтунга гына ышана алды! Бөек сәфәргә чыккан, дәһшәтле авазлар белән, корал чыңлатып сугышка ыргылган ун меңнәрчә коралдашлары арасында бары тик ул, бердәнбер ул гына, картаеп баручы олау хезмәтчесе, аның ягына баса ала иде. Бары тик ул гына, бүтән берәү дә түгел. Соңыннан шулай булып чыкты да...

Төн пәрдәсе сыеклана башлаган ул сәгатьтә кашка аты Акйолдызга атланып, аланнарда һәм олау табырларында йоклап яткан гаскәриләрне урап узганда, йөзбашы алда ни торганын уйлады һәм Ходайдан яңа туган сабый – гөнаһсызлардан гөнаһсыз җан иясе хакына булышлык итүен сорады, чөнки һәр яңа туган бала – ул Ходай хозурыннан вәхи-хәбәр; аның нияте буенча кемдер кайчан да булса кешеләр алдына, Ходайның үзе кебек, адәм кыяфәтендә килеп басачак һәм шулчакта барысы да алла бәндәсе нинди булырга тиешлеген күрәчәк. Ә Ходай ул – акыл ирешмәслек иксез-чиксез Күк. Кемгә нинди язмыш тиячәк – кемгә туарга да кемгә яшәргә – моны бер Күк кенә белә.

Йөзбашы Эрдене иярдә килеш кенә күзләре белән йолдызлы киңлеккә төбәлеп, күңеленнән Күкнең рәхим-шәфкатен сорарга тырышып карады, аннан язмыш җавабын көтте. Әмма Күк дәшмәде. Йокыга талган һәм төн сихрилегенә уралган Сарүзәк даласы өстендә ай гына миләүшә төсендәге яктылык агымы булып түгелә, берьялгызы иң югары ноктада, бөтен күккә хуҗа булып тора иде...

Ә иртәнге якта яңадан добулбаслар кешеләргә, торыгыз, коралларыгызны алыгыз, ияргә менегез, артык йөкләрегезне олауга ташлагыз, дип әмер биргәндәй, гөрселди, күкри башлады һәм хаканның беркем дә тыя алмаслык чиксез хакимлеге илһам биргән, куалап йөрткән дала чирүе янә Кояш баешына таба юл алды.

Бу инде сәфәрнең унҗиденче көне иде. Сарүзәк даласының аеруча авыр үтелә торган, ифрат та киң өлеше инде артта калды, алдагы Җаек болыннарына бер-ике көннән барып җитәрләр, ә аннан соңгы юл изге сулары белән дөньяны ике өлешкә – Кояш чыгышы белән Кояш баешына бүлгән бөек Иделгә таба алып китәчәк.

Барысы да бер салынган сукмактан, күнегелгәнчә иде. Иң алда – биеп барган чем-кара атларда – байрак йөртүчеләр. Алар артыннан кизүвыллар һәм яраннар Чыңгызханны озатып килә. Хаканның ияре астында, һәрвакыттагыча тигез адымнар белән, яраткан юргасы – ак яллы, кара койрыклы Хуба атлый, ә баш очында, күз карашын иркәләп, хаканның йөрәгендә болай да көчкә тыеп торган яшертен масаю хисен кыздырып, әлеге дә баягы аерылмас юлдашы – ак болыт йөзә. Кая гына юнәлмәсен – ул да шул якка таба. Җирдән исә, офыкларны тутырып, Кояш баешына таба кешеләр ташкыны – Чыңгызхан чирүе, аның олаулары ургыла. Аларның ерактагы диңгез шавыдай гөрелтесе күккә хәтле күтәрелә. Исәбе-саны булмаган, иксез-чиксез, кешеләр, атлар, олаулар, корал, мөлкәт, хайваннардан хасил бу агым бөтенләе белән аның – Чыңгызханның куәте һәм көченең гәүдәләнеше иде. Боларның һәммәсе дә аңардан килә, барысының да чыганагы – аның алдан ук билгеләп куйган ниятләре. Иярдә оеп барган шул мәлдә ул әле һаман, теләсә кем хыялланырга җөрьәт итмәгән, ә менә үзе зарыгып көткән нәрсә – бөтен дөньяны яулап алып, үлгәннән соң да хакимлек итә алачак, күк астындагы бер һәм бердәм, мәңгелек мәһабәт дәүләт кору уе белән яна. Ничек моңа ирешеп була? Кыя таш-

ларына хәзердән үк төшерелергә тиешле Аның боерыклары аша. Ул фәрман-боерыкларны саклап торган кыялар исән булганда, дөнья белән аның ихтыяры идарә итүдән тукталмаячак. Шул сәгатьтә менә ниләр турында уйланды хакан һәм, үлемсезлеккә ирешү ысулы буларак, ташлардагы язулар хакындагы кызыктыргыч фикер инде аның тынычлыгын алган иде. Ул моның белән кышын Идел ярында шөгыльләнергә карар кылды. Кичүне көткән арада галим-голәмәне, акыл ияләрен һәм көрәшчеләрне җыячак та мәңгелек дәүләт турында үзенең алтын фикерләрен җиткерәчәк, кыяларга уеп язылырга тиешле боерыкларын әйтәчәк. Бу сүзләр дөньяның астын-өскә әйләндерер һәм бөтен җиһан аның аяк астына егылыр. Ул шуның өчен яу сәфәренә чыкты да бит, җирдәге бөтен җан иясен әлеге максатка хезмәт иттерергә кирәк, ә моңа каршы килгән һәммәсен дә, уңышка ирешү юлында каршылык күрсәтүчеләрнең барысын-барысын – юлдан алып ташларга һәм юкка чыгарырга. Бугазына янә шигырь тыгыла башлады:

Дәүләтемнең алмаз түбәсенә
кадап куярмын күктән айны алып... Әйе!..
Чирүемнең чуен дагасыннан
сукмактагы кырмыска да исән калып
булмаслыгын белер... Әйе!..
Көч-куәтнең чын бәһасен аңлый барып,
атымның тирләгән савырыннан
чал тарихның аумакай хурҗинын
алыр әле
яхшылыкның кадерен белгән яшь буыннар... Әйе!..

Шулай булып чыкты ки, нәкъ шул көнне, төш авышкач, Чыңгызханга, олаудагы бер хатын, мондый эшне ханның катгый тыюын бозып, бала тапкан, дип җиткерделәр. Кемнән тапкан – анысы әлегә билгесез. Бу турыда хептевыл (шымчы) Арасан әйтте – йөгерек кечкенә күзле, һәрвакыт бөтенесен белеп торучы кызыл яңаклы тынгысыз хептевыл бу юлы да беренче булып хәбәр китерде. «Минем бурычым барысын да ничек бар – шулай сиңа белгертү, бөекләрдән бөек хан, чөнки син бит бу уңайдан инде бер кисәттең», – сүзләрен җил алып китмәсен өчен, хакан белән янәшә, өзәңгегә өзәңге тиеп барган хептевыл Арасан хырылдый төшеп кычкырды, – муенын май баскан, шул аның тынын кыса иде.

Чыңгызхан әллә аңышып җитмәде инде, хептевылга шунда ук җавап кайтарырга ашыкмады. Ул мәлдә, күңел төпкелендәге ташъязмалар турында хыялга чумып барганлыктанмы, кинәт ыргылып кергән күңелсез хәбәргә тиз генә бирешәсе килмәдеме, әллә ул аңа шулай тәэсир итәр дип көтмәгәнен сиздермәскә тырышыпмы – Чыңгызхан шактый озак дәшмәде, бары тик атын куалап, аның адымын ешайта төште, инде кеш тиресеннән тегелгән җиңел тун итәкләре, куркынган кош канатлары сыман, як-якка очып бара башлады. Ә хептевыл Арасан, аңардан калышмаска тырышты, нишләргә дә белмичә, уңайсыз бер халәт кичерде, үзенең янәшәдә булуы белән хаканның артык ачуын китермим, дип, атының тезгенен тартып туктатты, аннары, дәшә калса, аның сүзен ишетми калмас өчен янә өзәңгегә өзәнге тиеп барды, тик хакимнең ни өчен шулай озак телсез калуының сәбәбен, мәгънәсен барыбер аңламады, – югыйсә, аңа бит бары бер сүз генә әйтәсе иде, тик бер сүз: җәзалагыз! – Һәм бөек хаканның яу сәфәрендә бала табуны тыюын санга сукмаска батырчылык иткән әнчекне дә, ул дөньяга китергән эт баласын да шул ук сәгатьтә анда – олауларда буып үтерерләр иде. Башкаларга сабак булсын өчен, әдәпсез чәчбине киезгә урап тончыктыр, – шуның белән бөтен эшкә чик куела ләбаса.

Хакан кинәт җилкәсе аша гына шундый кистереп бәрде, хептевыл хәтта иярендә үрә катты:

– Соң нишләп, әле шул олау өстерәлчеге баласын тапканчы, берегез дә сизмәде-күрмәде аның көмәнле икәнлеген? Йә күреп тә эндәшмәдегезме?

Хептевыл Арасан моның ничек килеп чыгуын аңлатмакчы булып азапланды, тик әйтер сүзендә буталды, шуңа хакан аны тупас кына бүлдерде:

– Дәшмә ичмаса!

Бераз баргач, ул тагын зәһәр итеп сорады:

– Иясез икән, кем соң ул хатын: учак кабызучымы, пешекче яки мал караучымы?

Ә инде олауда бала тапкан хатынның байрак чигүче оста булып чыкканына чиктән тыш гаҗәпләнде, чөнки әлегә хәтле мондый эшләр белән кем шөгыльләнә, ничек кояш чыга һәм кайдан килеп яңгыр ява, – болар турында белмәгән кебек, кем тукымасын кисә дә аның алтын һоруңнарын чигә, кем аңа итек тегә яки гөмбәзләре астында бөтен тормышы аккан тирмәләрне кем кора, – бусын да беркайчан башына китергәне юк иле. Элек мондый вак-төяк турында ничектер уйланылмаган. Сәбәбе булмады: һәркайда – үз янында һәм чирүендә алан булып туктаган төшләрдә яки күңел ачу мәҗлесләрендә, ул килеп җиткәнче, ул күргәнче үк янып торган учаклар кебек, һоруңнар үзаллы җилфердәп каршы ала. Менә әле дә – алда, юлын яктыртып, байрак йөртүчеләр ат биетеп атлый. Ул Кояш баешына, ятларныкын таптарга, аларны аяк астына салырга дип, үз байраклары белән бара. Һәм шулай булачак та әле... Берни дә һәм беркем дә аны юлыннан бүләргә, аны туктатырга җөрьәт итмәс. Шул ук вакытта аның белән бергә дөньяны яуларга баручылардан кайсыныңдыр теләсә нинди, хәтта кечтеки генә буйсынмавы да үлем җәзасы белән киселәчәк. Буйсынмаган өчен җәза – берәүнең күпләр өстеннән хакимлеген алыштырмас корал. Ләкин бу очракта әлеге чигүче генә гаепле түгел, һичшиксез, баланы олауда яки гаскәрдә баручы кемдер ясаган бит... Тик кем соң ул?..

Шул сәгатьтән Чыңгызхан кара коелды, бу аның таш кебек каткан чыраеннан, керфек тә какмый торган селәүсен күзләренең авыр карашыннан һәм, җилгә каршы барган кебек, иярдә утыруының киеренке рәвешеннән үк күренде. Әмма әлеге очракның, нindидер чигүче һәм аның әлегә билгесез сөяркәсенең хакан сүзен ачу китергеч итеп тыңламавыннан бигрәк, күңелендә ачы, җуелмас, хурлыклы эз калдырган бөтенләй бүтән тарихны исенә төшерүе белән кәефен кырганын ашыгыч эшләр белән аңа якын килергә батырчылык иткәннәр арасыннан берәү дә белми иде.

Атасыз үскән бу ятимне һичкем дә, килер бер көн – ошбу үксез, тәрбиясез малай актыгы Дөньяның Дүрт Тарафы Әмире булыр дип күз алдына китермәгән, ул үзе дә мондый хәлнең булырын уйлый алмаган вакытта, әле үзенең чын Темучин исемен йөрткәндә кичергәннәре, йөрәкне яндырып, яңадан кабатлангандай булды. Ул чакта аңа гомерлек җәрәхәт салган бер вакыйга – авыр фаҗига һәм мәсхәрәләнү аша үтәргә туры килгән иде бит. Үсмер чагыннан ук «колагы киртеп куелган» яшь хатыны Бортэ ширбәт ае көннәрендә күрше меркитләр кабиләсенең һөҗүме вакытында урланып, әле аңа каршы һөҗүм ясап кире кайтарганчы әллә нихәтле, исәбе-хисабы булмаган, – ул чакта төгәл генә санарлык хәле дә юк иде, – көннәр һәм төннәр узды... Инде менә хәзер, күңел ярасы йомылган, берәүнең дә кулы мәңге ирешә алмаслык итеп үз исемен раслаган, бөтен дөньяны тетрәткән хаканның күпмеңле чирү башында Кояш баешын яуларга барган чагында шул аяныч хәлләр исенә төшәр, дип кем уйлаган?!.

Дәвамы бар ■

Остазымның хаты

Әнвәр Шәрипов

Атаклы галим Хатип ага Госман (1908-1992) миңа фәнни юл күрсәтүчеләрнең берсе булды һәм тормышымда гаять зур роль уйнады. 1968-1971 елларда аның җитәкчелегендә мин Казан университетының татар әдәбияты кафедрасында аспирантурада укыдым. Уку чорында Хатип агадан фәнни эш күнекмәләренә өйрәндем, текстология фәненең нинди икәнлегенә төшендем. Аның җитәкчелегендә «Габдерәхим Утыз Имәни мирасы һәм аның поэзиясендә дөньяви мотивлар» дигән темага 1973 елда кандидатлык диссертациясе якладым. Хатип аганың шәкертләренең берсе булуым белән мин чиксез горурланам.

Өч ел буена аспирантурада укыганда, әлбәттә, миңа аның белән еш очрашып, аралашып яшәргә туры килде. Хатип ага турында истәлекне тулырак итеп тә язарга мөмкин булыр иде, ләкин мин биредә аның белән аралашуымның бары ике генә очрагына тукталып китмәкче булам. Шуларның беренчесе болай булды.

Хатип ага җитәкчелегендә аспирантурада укып йөргән чагым. Ничектер шулай туры килде, беркөнне эштән соң университетның химкорпусыннан бергә чыктык. Шунда Хатип ага миңа: «Әйдә, бераз бергә кайтыйк әле», – диде. Мин аны озата киттем. Сөйләшә-сөйләшә җәяүләп «Кольцо»га төшкәч, ул үзләренә бара торган 2 нче трамвайга утырмады (Хатип ага «Школьный» тыкрыгындагы йортта тора иде), ә «Эрмитаж» бакчасына юнәлде. Бакчага керә торган баскычлардан мендек; монда һава да сафрак һәм шәһәр тавышы да алай нык ишетелми икән. Сөйләшә-сөйләшә әкрен генә аллея буйлап барабыз. Шунда Хатип ага кинәт: «Әйдә, бераз ял итеп алыйк әле», – диде дә, аллеядан бер читкә чыгып, газеталар җәеп, ямь-яшел чирәм өстенә утырды. Мин шундый зур, олпат галимнең үзен шулай гади итеп тотуына гаҗәпләндем һәм үзем дә аның янынарак урнаштым. Шунда ул миңа борынгы әдәбиятны өйрәнүнең халкыбыз өчен ни дәрәҗәдә кирәк, әһәмиятле булуы турында сөйләде һәм, канәгатьләнү белдереп, болай диде: «Менә бу өлкәдә дә соңгы вакытта «боз кузгалды», борынгылыкны яшьләр өйрәнә башлады. Әнә, Хатыйп Миңнегулов ничек алдырып китте; мин аңа зур өметләр баглыйм. Синең дә уңышларың булырга тора». Без шулай шактый гына сөйләшеп утырдык. Аннан соң ул: «Ярар, хәзер үзем генә кайтыйм инде», – диде дә әкрен генә үз йортына таба китте. Шулай итеп, мин шундый олпат, атаклы галимнең дә үзен гади тотуына, кешелеклелегенә сокланып калдым.

Икенче очрак. Ул чагында мин, аспирантураны тәмамлап, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшли идем. Габдерәхим Утыз Имәни иҗаты турында 1973 елда ук кандидатлык диссертациясен яклаган булсам да, әлеге шагыйрьнең әсәрләрен китап итеп чыгармый торып, күңелем тынычланмады. Шигырь текстларын Казан университеты Фәнни китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә сакланган кулъязмалардан алып, бер үк әсәрнең берничә күчермәсен үзара чагыштырып, фәнни-чагыштырма текстларын басмага әзерли идем. Ул чакта әле институтта Текстология бүлеге оештырылмаган, татар текстологиясенең фәнни нигезе эшләнмәгән, текстологлар да

берән-сәрән генә иде. Менә шунда бер мәсьәлә алдында аптырап калдым: «Гавариф эз-заман» поэмасының төрле вакытта язылган биш күчермәсе бар. Аларда бер үк фигыль формасы гарәп алфавитында төрлечә язылган. Мәсәлән: килер, кәлер, килүр, кәлүр һ.б. Ә басылачак китапта мин шул формаларның берсен генә бирергә тиеш идем. Шул формаларның кайсысын алырга? Минем эш шуңа килеп терәлгән һәм шуны хәл итмичә алга барып булмый иде. Ә Хатип ага кайсыдыр ял йортына киткән иде булса кирәк, һәрхәлдә, Казанда түгел иде. Һәм мин, ашыгыч рәвештә киңәш сорап, Хатип агага хат яздым. Хатип ага миңа җавап бирде. Бу хаттның татар текстология фәне тарихы өчен дә билгеле бер дәрәҗәдә кыйммәте булганлыктан, биредә аның тулы тексты китерелә.

«Әнвәр!

Хатыгыз өчен рәхмәт.

Хәзер сез сораганнарга кыскача гына үз фикерләремне әйтеп китим.

1. Китап институт грифе белән чыгамы, әллә грифсезме? Гриф булганда академик традицияләрне саклау тиеш, димәсләрме?

2. «Кәлүр – килер»ләр мәсьәләсе. Дөресен әйткәндә, безнең татарда бу турыда фәнни бер принцип эшләнмәгән. Русларда соңгы елларда бер үзгәреш күренә: алар борынгы әдәби әсәрләрен борынгыча итеп, әллә күпме борынгы билгеләр кулланып баса торганнар иде. Соңгы еллардагы басмаларда борынгы формаларны күзгә күренерлек итеп киметтеләр, хәзерге орфографиягә күбрәк якынайталар. (Сез элекке һәм соңгы басмаларны үзегез дә ачып карагыз әле.)

3. Безнең татарга килгәндә, ике нәрсәне аерып карау гамәлгә кермәгән: дөньяда җанлы сөйләшү теле бар, орфография бар. Татарлар озак заманнар борынгыдан калган орфографиядә язып, язганны хәзерге әйтелештә укый торган булганнар. Язуда «кәлүр», «килүр», «килер» формаларында язганнар, укыганда, әлбәттә, бер генә әйтелештә укыганнар: «килер» дигәннәр. Сез ничек итәрсез: бер сүзне текстта өч төрле язуга карап, өч урында өч төрле язарсызмы: «килер», «килүр», «келүр» дипме? Монда һәрхәлдә унификация кирәк – бөтен урында боларның берсен генә алырга кирәк. Минемчә шулай.

4. Телчеләр ни әйтәләр? Аларны да тыңлап карарга кирәк.

5. Күрәсең, мондый текстларны ничек басып чыгаруның үзен бер фәнни мәсьәлә итеп, киңәшеп, бер фикер булдыру кирәктер. Сез шуны күтәрмәссезме? Юзеевка әйтегез әле.

Х.Госман.
17. I. 78».

Хатип ага ял йортыннан кайткач, без аның белән очрашып, әлеге теманы уртага салып, тагын бер тапкыр сөйләштек. Һәм мин Утыз Имәни җыентыгын матбугатка остазым киңәшләрен истә тотып әзерләдем.

Журнал укучылары өчен монда бер генә искәрмә бирергә кирәк: хатның соңгы җөмләсендә искә алынган «Юзеев» – ул вакытта институтның әдәбият секторы җитәкчесе булып эшли торган күренекле галимебез Нил Гафур улы Юзеев.

Хатип ага Госманның бу хаты минем архивымда иң кадерле урында саклана. «Кулдан җитәкләп» диярлек текстология фәненә алып кергәне, ул фәннең үзенчәлекләрен аңлатканы өчен мин Хатип ага Госманга гомер буе рәхмәтле булып яшәдем.

РЕДАКЦИЯДӘН:

Әдәбият тарихы галиме, филология фәннәре докторы, педагог, публицист, шагыйрь Әнвәр Мәгъдәнур улы Шәрипов күптән түгел 75 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Әдәби мирасыбызны кайтаруга, татар әдәбиятын пропагандалауга, яшь буынны милли рухта тәрбияләүгә зур өлеш керткән даими авторыбызны гомер бәйрәме белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, игелекле олы хезмәтендә һәм иҗатында уңышлар теләп калабыз! ■

«ШТЫК ҺӘМ КАЛӘМ БЕЛӘН...»

Шаһинур Мостафин

«...Җанга якын җаннар китә тора...»

Бу сүзләрне заманында Зәки ага Нуриның ут күршесе булган, бер үк йортта яшәгән каләмдәше – Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин әйткән иде...

Әйе, җанга якын газиз җаннар, күңелләрне тетрәндереп, үзәкләрне өзеп, китә тора. Мәңгелеккә. Әмма алар, көннәр, айлар, еллар үткән саен, безнең йөрәкләргә якынайганнан-якыная баралар. Ни гаҗәп, хәтта Галиҗәнап Вакыт та аларның якты исемнәре, үлемсез эшләре каршында көчсез...

Зәки ага Нури (1921-1994) – әнә шундый олуг шәхесләребезнең берсе иде. Матурлык һәм Батырлык җырчысы, Яктылык һәм Яхшылык илчесе булып, гомер бакый күңелләрдә балкып яшәр әлеге ак күңелле, намуслы фронтовик-шагыйрь!..

...Ул Табигать-Анабызны, бигрәк тә аның сылу ак каеннарын, «таң кебек балкыган» миләшкәйләрен өзелеп ярата иде. Гомумән, урманга битараф түгел иде Зәки ага. «Урманым – җырым

Июнь, 1967 ел

оясы!» дип язуы да шуны раслый. Урманның тылсымлы-сихри дөньясы аңа кечкенәдән үк таныш. Ни әйтсәң дә, өч яктан имән, нарат, усак урманнары белән уратып алынган Татар Төкесе авылында (Татарстанның Чүпрәле районы) урманчы Шәрәфетдин абзый гаиләсендә туган ул. Моннан 95 ел элек – 24 декабрьдә...

Әйдәгез, биредә аның үз истәлекләрен дә укып карыйк әле:

«...Без, язын-җәен – төпсез ыштанлы, күзен-кышын чабаталы сабыйлар, өлкәннәргә ияреп, көн саен диярлек урманга йөрибез: йә җиләккә, йә юкә кисәргә, йә мунча себеркесе өзәргә, йә утын алып кайтырга... Күбрәк тәпи-тәпи элдертәсең; атка утырып, тантаналы кыяфәттә йөргән чаклар да аз булмады. Бөтен авыл диярлек бергә җыелып, өч-дүрт көн рәттән шунда торып печән чапканда һәм печән җыйганда Боталуй дигән зур аланга барасың да барасың инде. Ә ат саклап урман буенда кунуларның, шунда бару-кайтуларның рәхәте белән ләззәтен хәтта әйтеп кенә аңлатулары да кыен... Менә шунда инде, сине сихерләп һәм ымсындырып, ничәмә-ничә төрле кош сайрый, берсеннән-берсе тылсымлырак тавышларны бергә кушып, кара урман шаулый. Юлларда яки учак яннарында күпме әкият тыңлыйсың да нихәтле гыйбрәтле сүз ишетәсең!..

Кыскасы, шигырь әлифбасын танырга һәм ятлый башларга безнең барыбызны да, тәүге юлларның беренче адымнарында ук, шагыйрь җанлы туган табигать, шагыйрь рухлы халык, тормышның үз тавышлары һәм үз авазлары шулай өйрәтә икән.

Әлифба – дөреслеккә юл ул! Үзебезнең башлангыч мәктәпне тәмамлагач, без дә авылыбыздан алты бөртек «ташбаш» (бөтенебезгә кушамат шул иде), иңнәребезгә ризык тулы биштәрләрне асып, кулларга дәреслек тотып, Мунчәли тарафларына юл алдык. Ул чакта колхоз яшьләре мәктәбе дип йөртелгән сигезьеллык мәктәп шунда иде. Бездән унике-унөч чакрымда гына. Ял көннәрендә йөгерә-чаба атлап, ашарга алырга өйгә кайтабыз.

Югары әдәби курсларда укучылар. Мәскәү. 1957 ел

Карлы-буранлы кышкы көннәрдә колхоз аты белән дә илткәлиләр. Юл да кыскарсын, тел дә остарсын, дигәндәй, укытучыларыңны мактап сөйләшәсең, яңа укыган китапларыңның геройларын ярату-яратмавыңны да белдерәсең, бер-береңне бүлдереп, яңа шигырь дә укыйсың килә. Табышмак әйтешү дисеңме, җыр җырлаумы, такмаза чыгарумы – барысы да шунда. Нинди генә гәп кормадык та, ниләр генә уйламадык икән шул юлда без! Үзе бер дөнья, үзе чын шигърият иде ул...

Үзем дә сизмәстән, шул шигърият орлыкларының кайберләре минем күңелгә дә төште булса кирәк. Районыбызда чыга торган «Коммунар» исемле газетага хәбәрләр яза башладым...»

***

...Зәки ага белән без еш аралашып яшәдек. Ошбу дөньяда яшәвенең соңгы елларында (ул чакта мин СССР Язучылар берлегенең Татарстан бүлегендә Әдәбият фонд директоры булып эшли идем) – бигрәк тә... Табигать кочагында бергә сөйләшеп йөрергә дә, өендә кунакта булырга да, хастаханәгә барып, хәл-әхвәлен белешеп торырга да туры килде. 70 яшьлек юбилеен да якыннары, дуслары белән түгәрәк табын янында бергәләп билгеләп үттек...

Аеруча хисләнгән, дулкынланган минутларда, үзенең балачагын, яшьлек елларын искә төшерергә ярата иде Зәки ага:

—...Ә беләсеңме, Шаһинур туган, үземчә шигырь дип санаган һәм матбугатта дөнья күргән иң беренче әйберем дүртьюллык такмак иде. Үз колхозыбыздагы түбәсе тишек, нык тузган янгын сарае турындагы шул язмам район газетасында басылып чыкты. Нәтиҗәсе шул: сарайны тиз арада тәртипкә китерделәр! Менә мин шулчакта әдәби сүзнең нинди зур көчкә ия булуын аңладым... Соңрак мәктәптә әдәбият укытучыбыз оештырган драмтүгәрәкнең актив бер «артисты» буларак, авылларда концерт-спектакльләр белән еш йөрергә туры килде. Менә шунда халыкны, кичә башланыр алдыннан, «үз иҗатыбыз» – булачак шагыйрь Шәрәф Мөдәррис белән берлектә язылган чәнечкеле шаян такмаклар белән дә еш таныштыра идек. Әлеге такмакларны халык, үз авылдашларыбыз тормышыннан алып язылганлыктан, бик яратып кабул итә иде. Бары тик дөреслекнең генә халык йөрәгенә якын икәнлеген без әнә шулчакта ук төшендек һәм гомеребез буена шул кыйблабызга тугры булып калдык!..

***

...Сигез сыйныфлы авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, Зәки Нуретдинов Татарстанның Кукмара төбәгендәге Лубян урман техникумында тырышып укый. Бер үк вакытта «Яшь ленинчы» газетасы белән дә бик актив язышып тора яшүсмер егет.

1938-1940 еллар арасында Зәки Шәрәфетдин улы Ерак Көнчыгышта – Амур елгасы ярындагы Николаевск шәһәрендә диңгез порты төзелешендә эшли. Аннары яңадан Лубянга әйләнеп кайта. 1941 елның маенда Зәкине шуннан хәрби хезмәткә алалар. Һәм ул, илебезнең көнбатыш чигенә – Белосток төбәгенә җибәрелеп, сугышның беренче көннәреннән үк фашист илбасарларына каршы үз-үзен аямыйча көрәшә. 1941 елның августында, полкташлары белән бергә чолганышка эләгеп, З.Нури дошман тылында кала һәм Витебск өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннар отрядына кушыла. 1942 елның мартыннан 1944 елның августына кадәр атаклы Константин Заслонов җитәкчелегендәге белорус партизаннары берләшмәсендә – башта дошман көчләрен һәм коммуникацияләрен миналар ярдәмендә шартлатучы диверсант, соңыннан «Җиңү» («Победа») исемле разведка отряды башлыгы бу-

«Аккош» күле буенда. 1959 ел

лып хезмәт итә. Күрсәткән батырлыклары өчен, I дәрәҗә «Ватан сугышы партизаны» медале (1944) һәм II дәрәҗә «Ватан сугышы ордены» (1948) белән бүләкләнә.

Шул утлы-давыллы елларда да Зәки Шәрәфетдин улы иҗат итүеннән тукталмый. Көннәрдән беркөнне ул үзенең ялкынлы шигырьләрен, фронт сызыгы аша очып, партизаннар берләшмәсенә сугыш кирәк-яраклары алып килгән бер самолет белән, «Зур җир»гә озата. Бәхеткә, алар Казанга барып җитәләр. 1945 елда ул шигырьләр соңрак Татарстанның халык язучысы буларак танылган Гомәр ага Бәширов мөхәррирлегендә китап булып басылып та чыгалар.

Бу вакытта китап авторы әле һаман да Белоруссия җирендә була. Әлеге республиканы фашист-илбасарлардан азат иткәннән соң, Зәки Нуретдиновны, берничә иптәше белән бергә, Орша шәһәрен сугыш хәрабәләреннән арындыру һәм төзү-торгызу эшләрен җитәкләү өчен бiредә калдыралар. 1944 елның августыннан 1946 елның көзенә кадәр, хезмәт ияләре депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты рәисе урынбасары буларак, Зәки Шәрәфетдин улы үзенә тапшырылган җаваплы вазифаны зур тырышлык куеп башкара, халыкның тирән ихтирамына, олуг рәхмәтенә лаек була. Ә яхшылык, белгәнебезчә, еллар үтсә дә, онытылмый! 1975 елда – фашистлар Германиясен Җиңүгә 30 ел тулу көннәрендә Зәки Шәрәфетдин улы Нуретдиновка (әдәби псевдонимы – Зәки Нури) «Орша шәһәренең Почетлы гражданины» дигән мактаулы исем бирелә!

1946 елда Зәки Шәрәфетдин улы туган якларына әйләнеп кайта һәм 1946-1949 еллар дәвамында – башта Буа урман базасында, аннары Тархан урман хуҗалыгында директор булып эшли.

1949 елның ахырында З.Нури Казанга килә һәм «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасына мөхәррир урынбасары итеп билгеләнә. 1951 елда ул СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителә. 1951-1955 елларда Зәки Шәрәфетдин улы – Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар

әдәбияты редакциясе мөдире, аннары берникадәр вакыт Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант һәм идарәнең җаваплы секретаре хезмәтен үти. 1957 елда, Мәскәүдә СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлап кайтканнан соң, Зәки Нури алты елга якын – Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы секретаре, 1964-1971 елларда – «Казан утлары» журналының баш редакторы, 1971-1974 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе булып эшли. Җәмәгать эшлеклесе буларак, ул ике тапкыр – 1967, 1971 елларда Татарстан Югары Советына депутат итеп тә сайлана...

Кыскача анкета мәгълүматлары Зәки Нуриның сугыштан соңгы эшчәнлеген әнә шулай яктырта. Әмма бу юллар артында һәр минуты, һәр көне вә төне киеренкелек белән иҗади януда үткән еллар ята. Әдәбиятта иң актив эшләүчеләрнең берсе иде өлкән каләмдәшебез. 1945-1993 еллар эчендә аның алтмыш өч (!) китабы басылып чыкты.

Биредә Зәки ага Нури турында «Әдипләребез» дигән библиографик белешмәлекнең 2 нче томыннан (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2009 ел; төзүчеләре – Рәис Даутов, Равил Рахмани) аерым өзекләр китереп үтәсебез килә: «Иҗатчы буларак, ул – иҗтимагый тормышта, әдәбият-сәнгать дөньясында булган һәр мөһим вакыйгага, яңалыкка публицистик яки шигъри сүзе аша мөнәсәбәтен белдереп барган әдип. Аның әдәби мирасын зур дүрт төркемгә бүлеп карарга мөмкин: публицистик яңгырашлы һәм мәхәббәт лирикасы, балалар шигърияте («Син мәктәпкә йөрисең», 1954; «Аңлатыгыз миңа», 1956; «Таныш булыгыз», 1958; «Табышмак әйтеш», 1959; «Саный беләм», 1962; «Бу безнең китап», 1967; «Без инде хәзер зурлар», 1970; «Күп беләм китабы», 1988 һ.б. җыентыклар), сатира-юмор әсәрләре («Сезнең арада юкмы шундыйлар», 1960; «Туры карап күзегезгә», 1963; «Елмаябыз һәм көләбез») һәм төрле телләрдән тәрҗемәләр.

Тәрҗемәче буларак, Зәки Нури рус совет шагыйрьләре А.Твардовскийның «Дом у дороги» («Юл буендагы йорт», 1951), С.Щипачевның «Дом в Шушенском» («Шушенскоедагы өй», 1953), В.Саяновның «Ленин в Горках» («Ленин Горкида», 1954) исемле поэмаларын, украин шагыйре П.Вороньконың балалар өчен язган шигырьләрен («Синең китабың», 1955), кыргыз шагыйре К.Җунусов, белорус поэзиясе классигы Я.Коласның шигъри әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Ул шулай ук, үзе төзеп һәм татарчага тәрҗемә итеп, аерым серия басмалары рәвешендә, 1967-1975 еллар арасында совет чоры азәрбайҗан, белорус, казакъ, үзбәк, төрекмән, таҗик, кыргыз, украин, рус, латыш, эстон, әрмән һәм грузин поэзиясенең иң яхшы үрнәкләре тупланган махсус җыентыклар бастырып чыгара. Дөнья халыклары авыз иҗаты әсәрләрен (мәзәкләр, мәкаль-әйтемнәр һ.б.) үз эченә алган «Алтын хәзинә» (1973) «Күңелле китап» (1979, 1989) исемле күләмле җыентыклар да шагыйрьнең тәрҗемә өлкәсендәге нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге турында сөйли. Бер үк вакытта аның үз иҗат мирасыннан аерым басмалар булып рус теленә тәрҗемәдә егерме китабы һәм белорус, азәрбайҗан, казакъ, мари, якут телләренә тәрҗемәдә биш шигъри җыентыгы нәшер ителә.

Зәки Нуриның шигъри иҗат йөзен билгеле торган шигырь һәм поэмалары 1980 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Күңел яктысы» дигән күләмле җыентыгында урын ала.

Иҗатында яулаган рухи яңа биеклекләре, җәмәгать тормышындагы зур хезмәтләре өчен «Почет билгесе» (1971), һәм «Халыклар дуслыгы» орденнары (1981) белән бүләкләнгән Зәки ага Нури, гәрчә 1994 елның 18 февралендә вафат булса да, әле һаман безнең арада кебек. Шуңа күрә дә аның

Бер төркем әдипләр. Август, 1971 ел

«Үлгәннәр дә үч алды» («Партизан язмалары») дигән китабындагы (Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1962 ел) кереш сүзләр, изге васыять кебек, бүген дә бик актуаль, заманча яңгырый:

«...Ул елларны безнең беребез дә, беркайчан да онытмас!..

Немец-фашист илбасарлары туган җиребезгә басып керделәр. Ирегебезне буарга, бакчаларыбыз чәчәкләрен корытырга, эчкән суларыбызны агуларга, шат җырларыбызны моң-зарлы итәргә теләп, кара дәһшәт килде. Күкләребездә аждаһадай улаган самолетларына, юлларыбызда шыксыз дөбердәгән танкларына төяп, дошман безгә үлем ташыды...

Безнең авылларыбыз һәм шәһәрләребез дөрләп яндылар. Безнең күңелле бәйрәмнәребез тантанасы шаулаган, дәртле җырларыбыз яңгыраган мәйданнарга дар агачлары тезелделәр. Җимерелгән урамнарыбыз буйлап Гитлер солдатлары атлады. Аларның дагалы, авыр итекләре, әйтерсең, йөрәкләрне таптый иде. Җиребез тәнен һәм безнең күңелләрне бомбалар актарды, миналар телгәләде...

Көн белән төн көрәше, яшәү белән үлем тартышы башланды. Икенең тик берсен сайларга мөмкин иде: йә үләргә, йә җиңәргә!..

Һәм без, совет кешеләре, бер җан, бер тән булып, җиңү көрәшенә күтәрелдек. Төньяк диңгезләреннән алып Көньяк диңгезенә хәтле сузылган озын фронтларда фашистларның тетмәсен безнең гаскәрләребез тетте, ә тирән тылларда, вакытлыча басылып алынган җирләрдә исә гитлерчылар измәсен партизаннар изделәр.

«Без шартлап ярылган һәр урында дошманга тирән кабер казылыр!» Какшамас корычтан койган снаряд һәм бомбаларыбыз гүя шулай диделәр.

Әйтерсең, Җир-әнкә үзе телгә килде: «Дошман аягы баскан һәр карышым тетрәр минем һәм дошманны мин һәр адымда тирән упкыныма йотармын!»

Әйтерсең, челтерәп аккан барлык чишмәләр сүз куештылар: «Саф суларыбызны эчәргә дип фашист иелсә, без аның күзенә зәһәр агу булып чәчрәрбез!»

Басуларда башаклар да, әйтерсең, шуны ук әйтеп тирбәлештеләр: «Безнең һәр бөртегебез дошман бугазына кайнар кургаш шикелле булып кадалыр!..»

Гитлерчылар юлында күкләр күкрәп, халык нәфрәте яшеннәре яшьнәп торды. Алар аягы астында туфрак яна иде. Хәтта үлгәннәр дә алардан үч алды...

Сугыш безне дошман тылында,

СССР язучыларының V корылтае делегатлары. 1971 ел

белорус халкының батыр улы Константин Заслонов җитәкләгән партизаннар берләшмәсендә очраштырган иде. Урман шалашларында һәм окопларда, походларда һәм һөҗүмнәрдә үткәрелгән ул 1100 көн һәм төннең сугышчан эшләре һәм уйлары-хисләре бик күп булуын әйтеп тә торасы юк. Партизаннарның кырыс һәм киеренке тормышын, җиңүгә китергән озын юллардагы кайнар эзләрне күз алдына китерү өчен, шуларның меңнән бер өлеше хикәя ителсә дә, җитәрдер төсле.

Гитлерчы илбасарларның сыртларын сындырган, аларны үз өннәренә кысрыклап, дөмектергән көнебез бар. Без аны «Җиңү көне!» дип атадык. Ул, Рейхстаг ташына безнең штыкларыбыз очы белән уеп, Тарих битләренә безнең кайнар каныбыз белән язылды.

Бик күп сулар агып, бик күп еллар үтәр. Безнең Җиңү көнебез ел саен шулай иң матур, иң куанычлы бәйрәмнәрнең берсе буларак тантана ителер. Аның турында әле бик күп сүзләр сөйләнер, бик күп җырлар җырланыр. Җиңүебез турында һәм батырлык турында сөйләп, без җирдә канлы сугышларга нәфрәт белдерәбез, бөтен дөньяда тынычлыкны яклап сөйлибез...

Партизаннар уты шәүләсен без
Бу якларда бик күп уйнаттык.
Бу җирләрдә сөрем пәрдәсен без
Күп ябындык... Узды ул вакыт.

Җирдә күптән чәчәк исе аңкый —
Җиңеп туган язның саф исе!
Тыныч көннәр таңы булып балкый
Шәһәрләрдә цехлар яктысы...

Сагынып сезгә, дуслар, сагынып киләм,
Алып киләм Идел сәламен. —
Яклаштым мин сезне штык белән,
Бер төзүче булсын каләмем!..

Нинди иркен, нинди ямьле болын! —
Сукмагыңнан рәхәт атлавы!
Бүлдермәсен монда кошлар моңын,
Бүлдермәсен, бомба шартлавы!..

Тауларга менгәч

Зәки Нури

ЗУР МИРАС

Яшьлегем дә инде артта калды...
Ашыгып йөзә гомер корабы.
Кем урлады, дисәм, көннәремне,
Еллар икән аның карагы.
Тормыш – тәлгәш. Пешкән җимешләре
Бер-бер артлы тора өзелеп.
Әйтә кебек бар да: сине алда
Яна көннәр көтә тезелеп.
Шатлыгымны болай белдергәндә
Кайбер дуслар, беләм, көләчәк...
Үткәнемнең һәм бүгенге көннең
Зур мирасы миңа – Киләчәк.
Алда булыр яңа чәчәкләрнең
Бөреләнеп әле шиңәсе,
Алда әле, димәк, көрәшәсе,
Алда әле, димәк, җиңәсе.
Киләчәк бар – әле янармын мин,
Киләчәк бар – әле сөярмен,
Илем өчен очкын булалмасам,
Ил утында янып-көярмен.
Үткән инде үтте – аның исеме
Медальгә һәм ташка уелган.
Алда – кыя. Шунда менәсе бар.
Җыр маягы шунда куелган.
Әзер сукмак безгә кирәк түгел,
Уңышның без көтмик әзерен.
Киләчәк бар, дуслар, киләчәк бар,
Белү кирәк шуның кадерен!

1969

ТАУЛАРГА МЕНГӘЧ

Таулар, таулар... Тауда – ап-ак карлар...
Күз чагыла озак карасаң.
Кояш уйный таулар түбәсендә,
Тарлавыкта әле кара таң.

Таң балкышы тиздән җиргә төшәр –
Күктә юлын кыю яра таң.
Иңкү җирләр якты булган саен
Биеклеген җирнең яратам.

1970

ОРЕНБУРГ ЭКСПРОМТЫ

Кәрвансарай манарасы биек –
Тиеп тора якты күкләргә;
Пугачев та шундый бөек, диеп
Әйтеп тора гүя күпләргә.

Эзләре бар. Тора буш зинданы.
Тик үзе юк – кырыс атаман.
Тәбрикләве белән Пушкиннарның
Килә кебек аңа хат һаман.

Иркен дә син, киң дә, көчле дә син,
Мусаларны илгә биргән як.
Батырларың кабере өстенә син
Язлар саен яшел келәм яп!

1967 ■

Олы җанлы шәхес иде

Нәҗип Нәккаш



Дөнья гаме килә – ир булгач,
Дөнья яме килә – ир булгач,
Дөнья тәме килә – ир булгач...
Ах!
Дөнья кала –
Ирләр китә бара
ир булгач...
Гамь дә, ямь дә, тәм дә җирдә кала
Дөнья бәһаләре ир булгач...

Илдар Юзеев

Менә шундый дөнья бәһасе торган ир-егет, татар милләтенең күренекле матбугат әһеле, талантлы әдип, тәнкыйтьче һәм фикер иясе Фәиз Зөлкарнәйнең вакытсыз вафат булуына да 19 ел үтеп киткән икән. Исән булса, бу елның 4 декабрендә аңа 65 яшь тулган булыр иде...

Оста каләме, фикри егәре, заманча рухлы фәлсәфи-публицистик иҗаты белән Фәиз Зөлкарнәй 46 яшендә бөтен татар зыялылары каршында, халык алдында танылган иде инде. Соңгы елларда шәхси тормышы, гаиләкөнкүреше дә күп михнәт-җәфалар, мохтаҗлыклардан соң яхшырган, җайланган, хатыны Иркә, сөекле кызлары Ләйсән һәм Ләйлә белән яңа фатирда чөкердәшеп, бәхетле яши башлаганнар иде. Ләкин, ни кызганыч, очраклы юл-транспорт һәлакәте Фәизне якты дөньядан алып китте...

Шагыйрь Ркаил Зәйдулла Фәизгә багышланган мәрсиясендә тирән үкенеч, әрнү белән болай язды: «Мин беләм, Аллаһы Тәгалә яхшы кешеләрне үзенә тизрәк тартып ала. Ләкин безнең бәхетсез халыкның санаулы улларын аяса да яраган булыр иде...»

«Санаулы уллары» дип шагыйрь бик дөрес әйткән, Фәизнең санаулы, сирәк шәхес икәнлеген аның университет сабакташы, фикердәше, мәсләктәше һәм күп дусларының берсе булган мин фәкыйрегез – Нәҗип Нәккаш яхшы беләм. Андый шәхесләр онытылырга тиеш түгел. Шуңа күрә дә олы шәхес турындагы хатирәләремне яңартып, журнал укучыларга, Фәизне якыннан белмәгәннәргә тәкъдим итәм. Ә инде Фәизне белгәннәр аны сагынып, үз хатирәләрен яңартырлар.

Фәиз белән беренче танышуым болай булды: Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына, аның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кабул ителгәч, без яңа «пешеп чыккан» студентларны сентябрь башыннан ук Балтач районының Тимирязов исемендәге колхозына эшкә – бәрәңге алырга җибәрделәр. Төркемнең күбрәк өлеше колхоз үзәгендәге Кариле авылында калды, ә без өч егет, сигез кыз Кили авылына юл тоттык. Шулардан өч егет белән биш кызны ялгыз яшәүче бер апаның ике яклы өенә урнаштырдылар. Шул өч егетнең берсе мин булсам, икенчесе – Фәиз Зөлкарнәев, өченчесе Галимҗан Гыйльманов иде. Алар икесе дә Башкортстаннан: Фәиз – Бакалы, Галимҗан Дүртөйле районыннан икән. Галимҗан әле быел гына урта мәктәпне тәмамлаган булса, Фәиз инде колхозда тракторчы булып эшләп, аннан соң армия хезмәтен үтәп кайткан, Азнакайда янгын сүндерү депосында эшләп килгән чандыр гәүдәле, озынча йөзле, юка иренле, бераз очлырак иякле, куе кара чәчләре дулкынланып торган, тормышны шактый күргән тәҗрибәле егет иде.

Шундук аның фамилиясенә игътибар иттем: Зөлкарнәев! Яңгыравыклы, сирәк очрый торган фамилия. Гарәп сүзе «зөлкарнәйн» ике мөгез иясе дип тәрҗемә ителә. Көнчыгыш әдәбиятында ярты дөньяны яулап алган Александр Македонскийны шулай атап йөрткәннәр. Ни өчен дигәндә – Александр-Искәндәрнең башына киеп йөргән очлымы ике мөгезле булган.

Кайвакыт исем, фамилия кешенең бөтен киләчәген билгели яки үз-үзен тотышына, омтылышларына тәэсир итә. Фәизнең дә бу үзенчәлекле фамилиясе аның татар әдәбияты галәмендә, татар матбугатында акрынлап булса да, тайпылышсыз югары дәрәҗәләргә күтәрелүенә, танылган шәхес булып җитешүенә азмы-күпме, аңасты кимәлендә булса да, йогынты ясагандыр, дип ышанам.

Юлда килгәндә үк, танышуыбызның беренче мәлендә мин, үземнең өч яшькә өлкәнрәк булуымнан файдаланып, аннан көлебрәк бер сүз әйткән идем, әмма

Балтач районының Тимирязов исемендәге колхозына эшкә – бәрәңге алырга җибәрелгәч. Нәзирә, Розалия, Нәҗип, Рәфинә һәм Фәиз. 1974 ел, сентябрь

Фәиз оста һәм үткен җавап кайтарып, шундук авызымны томалады, кимсетеп башка сүз әйтерлекне калдырмады.

Бергә туры килгән өч егет ничектер бер-беребезгә ияләшеп, якынаеп киттек. Халык телендә «җеннәре туры килә» дигән сүз бар. Шуның кебек, безнең өчебезнең «җеннәре», серләре бер булды, чөнки өчебез дә китап сөюче, әдәби иҗатка, фәнгә омтылучы затлар икәнбез. Университетның шундый бүлеген сайлап килүебез дә тикмәгә булмаган.

Сугыштан соңгы 40 нчы еллар ахырында, 50 нче еллар башында туган безнең буын китап укып үсте. Тормыш никадәр авыр булса да, без китаптан аерылмадык. Телевидение, интернет, хәтта электр уты да юк чагында бердәнбер мавыгу, җанга рухи азык эстәү, дөньяны танып-белү бары тик китап аша иде. Керосин лампасы яктысында безнең күзләр аша күпме генә китап үтмәгәндер...

Без колхозга килеп төшкәндә әле урып-җыю эшләре төгәлләнмәгән иде, шуңа күрә «бәрәңге алырга керешкәнче» дип, безне ындыр табагындагы эшкә куштылар. Без өч егет ашлык төяп килгән машиналарны агач көрәкләр белән бушата идек, ә кызлар исә аларны көшелгә өеп, ашлык чистарта торган машинаның транспортерына биреп торалар иде.

Ул елны көз коры килде, күркәм генә әбиләр чуагы башланды. Ял сәгатьләрендә яки төнге сменага барасы булганда без өч егет, авыл читендәге инеш аша чыгып, чикләвек, артыш куаклары үсеп утырган калкулык итәгендә чирәмгә ятып ял итә идек. Шунда Фәизнең дә, Галимҗанның да шигырь язу белән мавыгулары ачыкланды, алар төш кесәләрендә йөрткән кечкенә генә блокнотларына күңелләрендә туган шигырь юлларын сызгалап куялар иде. Соңыннан, шигырь тәмам язылып беткәч, укып фикер алыштык. Фәизнең шигырьләре үзенчәлекле шәкелдә, кайберләре ирекле шигырь калыбында булып, беренче укылышта бик үк аңлашылып җитмәгән бу тезмәләргә фәлсәфи мәгънә салынган иде.

Фәиз университетта шактый җиңел

Иркә һәм Фәиз Зөлкарнәевләр. 2 ноябрь, 1978 ел

укыды. Яшьтән үк тупланып килгән көчле эрудициясе, аналитик фикерли белүе, лекцияләргә сирәк йөрсә дә, имтиханнарын уңышлы тапшыруга ярдәм иткәндер. Имтихан тотуның үзе эшләгән методикасы, теориясе бар иде аның. Гел «бишлегә» укуга ул омтылмады да, стипендия алырлык билгеләр булса, аңа шул җитә иде. Матди яктан ул шактый кысынкы яшәде, туган авылы, әти-әнисе еракта – Башкортстанда, анда кайтып йөрү чикле булганга, азык-төлек алып килү сирәк эләгә иде аңа. Әти-әнисеннән акчалата ярдәм сорамый иде ул, ирлек горурлыгы, мөстәкыйльлеге моңа юл куймады. Икенче курста укыгандамы икән – аңа университетның гомумторагыннан урын бирмәделәр. Ул сабакташыбыз Әнәс белән бер чуаш карчыгының почмагында яшәргә мәҗбүр булды, шул елны, азмы-күпме акча юнәтер өчен, каравылда эшли башлады. Ә җәйге каникулларда төзелеш отрядларында эшләп, матди тормышын алып бару өчен сәрмая туплый иде.

Фәиз үз-үзен карый, тәртиптә тота белде, өс-башын, кием-салымын һәрвакыт чиста, пөхтә йөртте, модадан да калышмады. Китап җыюга бик һәвәс булды, бүлмәдәше Галимҗан белән ярыша-ярыша китап җыйдылар.

Гомумторактагы Фәиз бүлмәсеннән кеше өзелеп тормады: сабакташ кызлары нинди дә булса авыр мәсьәләне аңлатып бирүне үтенеп яисә сорауларына җавап табу өчен керсә, шигырь язып әвәрә килүче Рәшит Минһаҗ, Газинур Морат кебекләр исә шигырьләрен күрсәтеп, аның фикерен ишетергә керә иде. Тыштан караганда үз эченә бикләнгән, аз сүзле, кырыс кеше кебек күренсә дә, чынлыкта Фәиз Зөлкарнәй олы җанлы, күңел җылылыгына, күңел сизгерлегенә ия булган, ярдәмчел һәм эчкерсез бер зат иде. Шуңадыр да аңа тартылучылар күп булды.

Дүртенче курста укыганда Зөлкарнәйнең йөрәген бер гүзәл зат – журналистика бүлегендә укучы Буа кызы Иркә яулап алды. Аларның садә-эчкерсез, романтик мәхәббәт тарихлары безнең күз алдында узды. Шактый

еллар үткәч, Фәизнең вафатыннан соң, башкалар ул тарихны төзелеш отрядында эшләгән вакытында Иркәгә язган гаҗәеп хисле хатлары басылып чыккач белде. Ул мәхәббәт ялкыннары дөрләп китеп, 5 нче курсны башлаганда алар кавышып, гаилә учагы барлыкка килде. Ә аны җил-яңгыр сүндермәсен өчен ни кирәк? Әлбәттә, түбә, «түбә» дигәнебез – фатир. Ә кем авыл балаларына фатир әзерләп куйган? Шәһәрдә якын туганы яисә «йонлы куллы» әшнәсе булмаганнарга нишләргә кала? Әлбәттә, берәр гомумторак бүлмәсенә сыенырга яисә кемнәндер фатир «снимать» итәргә кала. Фәизләргә шулай торак «снимать» итеп, байтак күченеп йөрергә туры килде. Ә һәр күченү, халык әйтмешли, ярты янгынга тиң. Аларның мин белгән дүртенче яшәү урыны гаиләм белән яшәп яткан «Казаньпромстрой» гомумторагы булды. Бүлмәле булу өчен Иркә анда кастелянша (урын-җир кирәк-ярагы белән тәэмин итүче) булып урнашты. Менә шунда яшәгәндә Фәиз һәм аның гаиләсе белән еш аралашырга туры килде. Ә бер елны (01.01.1984) сабакташларыбыз Фәрһад белән Нурия гаиләсе, Иркәнең сеңлесе гаиләсе һәм безнең гаилә гомумторакның «кызыл почмагы»нда Яңа ел бәйрәмен бергәләп үткәргән идек. Фәизләр үз фатирларына шактый соң – язучы Әхмәт Гаделнең Журналистлар урамындагы «хрущевка»да ике бүлмәле фатиры бушагач тиенде. Фәизнең кулы «алтын», һәрбер торган урынында ул тәртип урнаштырып, ремонтлап, үз зәвыгына туры китереп, бизәп куя белә иде. Әхмәт Гаделдән калган фатирны да ул бөтенләй үзгәртеп, яңалыклар кертеп, яңа киштәләр, шудырмалы ишекләр ясап куйды.

Фәизнең «Ялкын» журналында эшләгәнен мин бик үк хәтерләмим, ә менә Бауман урамындагы элекке нәшрият йортында редактор булып эшли башлагач, аның белән еш күрештек, чөнки минем эш урыным – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты – нәшриятка бик якын иде. Фәиз белән бер бүлмәдә сабакташ дустыбыз Галимҗан Гыйльманов, Фәүзия Бәйрәмова һәм тагын бер яһүдә ханым эшләде. Соңыннан атаклы милләтче, сәясәтче, публицист һәм танылган язучы булып җитешкән Фәүзиягә югары эрудицияле, тарихны яхшы белгән Фәиз белән Галимҗанның йогынтысы зур булгандыр, дип беләм, чөнки әле Фәүзиянең ул вакытта «Казан утлары» журналында корректор булып эшләп, мондагы редакторлык эшенә яңа гына керешкән вакыты иде. Шуны хәтерлим: фәнни җитәкчем Хатип ага Госман архивтан алдырган һәм «кириллица»га транскрипцияләп (күчереп) чыккан атаклы «Батырша хаты» текстын тулысынча хәзерге әдәби телгә күчереп, Фәизләр бүлегенә тәкъдим иттем. Алар өчен ул зур яңалык булды, чөнки башкорт галиме Гайсә Хөсәенов әзерләгән һәм бастырып чыгарган текст бик нык кыскартылган иде.

Фәиз Зөлкарнәй китап нәшриятында җаваплы зур эшләр башкарды: «Татар шигърияте антологиясе»нең ике томы (өлешчә), «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче 3 томы аның редакторлыгында басылып чыкты.

Фәиз шигъриятне сөюче, аны тирәнтен аңлаучы, сизгер тоючы, татар шигъриятен генә түгел, ә бәлки рус һәм бөтендөнья поэзияләрен дә яхшы белүче иде. Шуңа да аның 60 нчы еллар ахырында мәйданга чыккан яшь татар шагыйрьләренең иҗатларына биргән бәһаләмәсе, тәнкыйть мәкаләләре тирән анализ, чагыштырмалы тикшеренү, фикерне җиткерүдәге сүз байлыгы һәм дөреслек белән аерылып тора. Студент елларында ук (1974-1979) ул язып бастырган мәкаләләр, Р.Фәйзуллин, Р.Гатауллин, Г.Рәхим иҗатларына багышланган бәһаләмәләре зур әдипләрнең дә игътибарын җәлеп итте.

«Идел» журналханәсендә. 1990 нчы еллар

Алар әдәбият мәйданына зур белемле, талантлы һәм өметле тәнкыйтьче, әдәбият галиме чыкканын күрде: моны берәүләр сөенеп, икенчеләре исә шүрләп кабул итте.

Фәиз Зөлкарнәй 1989 елдан яңа барлыкка килгән «Идел» журналында эшли башлады. Аның иҗади мөмкинлекләре, оештыру таланты шушы журналда мөхәррир урынбасары, 1992 елдан баш мөхәррир булып эшләгәндә ачылды. Фәиз җитәкчелек иткәндә кыска гына арада «Идел» халык арасында иң абруйлы, кызыклы һәм игътибарга лаек басмага әверелде. Мин үзен «меланхолик» санап йөргән Фәизнең шундый журнал белән җитәкчелек итә алуына бераз шикләнеп, булдыра алырмы икән, дип караган идем. Әмма шикләрем урынсыз булып чыкты, аның мин белмәгән оештыру сәләте ачылып, ул хуҗалыкчан, икътисад һәм финанс эшләрен алып барырлык кешеләр табып, көчле иганәчеләр җәлеп итеп, хуҗалык эшләрен көйләп җибәрде. Шигырь язып кына тамак туйдырып булмаганын белгән Фәиз яшь иҗатчыларны үзенең редакциясенә хезмәткәр итеп алып, аларны эшкә өйрәтеп, дисциплина ягы чамалы шул шагыйрьләрне дә эшләтә белде, аларга иҗади егәрлекләрен ачарга мөмкинлек бирде. Мин алар әле дә Фәизгә рәхмәтледер, дип уйлыйм.

Фәиз журналның нинди булачагын алдан ук белә иде, чөнки Мәскәүдә Әдәбият институтында укыганда Балтыйк буе илләреннән килгән әдипләр, редакторлар белән танышып, аралашып, аларның үз милли телләрендә чыгара торган яшьләр журналларын күреп, шулардан үрнәк алып, Аурупа дәрәҗәсендәге татар журналы нинди булачагын күз алдына китерә алды.

90 нчы еллар башында татар галәмендәге җанланыш, милли бәйсезлеккә омтылыш, ислам диненә йөз белән борылыш, үткәндәге мәдәни мирас, бүгенге заман сәясәте, яшьләр проблемалары, шәхесләр – һәммәсе дә «Идел»дә ачык чагылыш тапты.

Фәиз кешеләрне сайлый белә иде, журналга ул талантлы, зыялы шәхесләрне тартып китерде. Аның бүлмәсендә Туфан Миңнуллин,

Мөхәммәт Мәһдиев, Флүс Латыйфи, Җәүдәт Сөләйманнар еш булды.

«Идел»нең ул вакытта башка журналларда күренмәгән бер гаҗәп үзенчәлеге бар иде: монда әсәрен китергән авторга алдан ук каләм хакын түләп куялар (әгәр ул талантлы әсәр булса), кайбер авторларга алдан ук кирәкле тема буенча заказ биреп, әле язылмаган әйбергә дә аванс бирәләр иде. Ә аванс алгач, язасы әйбереңне вакытында тапшырырга мәҗбүр буласың.

Фәиз безнең институт галимнәре белән дә ныклы элемтә урнаштырды. Язган мәкаләләрен кая бирергә, кайда бастырырга аптырап йөргән галимнәргә журналда мәйдан ачылды.

Үземнең дә, еш катнашмасам да, кайбер мәкаләләрем, мин әзерләгән борынгы татар прозасы үрнәкләре, гарәби каллиграфия әсәрләрем басылып чыкты. Заманында мин ясап биргән өч шамаилне Фәиз, 50шәр мең данәдә, «Идел» журналы билгесе белән бастырып чыгарды. Алар матбугат киоскларында арзан гына хакка сатылып, исламга йөз тоткан халыкның бүлмәләрен бизәде.

Фәиз Зөлкарнәйнең «Идел» белән бәйләнеше хакында шагыйрь Ркаил Зәйдулла аңа багышланган мәрсиясендә бик төгәл әйткән иде: «Фәиз «Ялкын»да да, Татарстан китап нәшриятында да эшләде, әмма Фәизне «Идел» ФӘИЗ итте, ә аңарчы Фәиз «Идел»не Идел итеп тирәнәйткәч, ярларын без кызыккан офыкларга этәргән иде инде».

Шәхеснең олылыгы, кыйммәте ул киткәч, аралар ерагайган, вакытлар узган саен ачыграк күренә. Фәиз белән дә шулай. Тормышка гашыйк, кешеләргә гаҗәеп игътибарлы, олы җанлы талант иясе Фәиз Мәүлит улы Зөлкарнәйне без – дуслары, замандашлары сагынып искә алабыз, якты хатирәсен күңелләрдә саклыйбыз.

ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЙ
(1951-1997)

ДИЛЕММА

Күп кирәк күңелгә, күп кирәк...
Өстә-өстә зәңгәр күк кирәк,
Һәм күктә якты кояш кирәк,
Һәм янында җырчы кош кирәк,
Һәм кошларга хас
Ирек кирәк!

Күп кирәк күңелгә, күп кирәк...
Мөлдерәмә зәңгәр күз кирәк,
Күзнең төбәп каравы кирәк,
Карашында кайнар нур кирәк,
Нурдан – богау...
– Әсирлек кирәк!..

***

Көзге көннең качкан чырае,
Күз яшьләренәме төелә?
Болытлардай авыр тойгылар,
Укмашкан кан гына – бу йөрәк.

Кыштырдашып аяк астында,
Сары яфрак түгел, үй кала.
Котылырга теләсәм дә, юк,
Тавыш сала шундук юктан да.

Җилме йолка чаган яфрагын,
Китереп сала аяк астына?
Шулай...
Үзең теләп түбән төшкәнче
Егылып төшү күпкә яхшырак...

Үзең теләп түбән төшкәнче
Егылып төшү күпкә яхшырак! –
Кем беләндер бәхәсләшкәндәй
Үҗәтләнеп җаным кычкыра.

Күреремнең тәүге аһы бу,
Гомеремнең уйлы минуты.
Сәерсенеп текәлмә, мин бу,
Гамьнәремә төренеп мин уттем.

Фәиз Ләбиб Лерон һәм Ләис Зөлкарнәй белән. 1990 нчы еллар



КАРА ҺӘМ АК МУНЧА

Ләис Зөлкарнәй

(Хикәя)

Иске өйнең карама ниргәләреннән сипләнгән кара мунча әле дә урынында тора. Астан – дүрт, өстән ике ниргәсен алыштыргач, менә дигән кетәклек чыкты аннан.

И, ул кара мунчаның тәмнәре!

Тау башындагы ферма чишмәсеннән су ташыганда ук кара мунчаның пары бишмәт эчендә тулыша башлый. Чананы тауга тартып менгәндә дә йөгерергә кирәк. «Үсәм, дисәң, йөгер!» – дип, алдан абый үсендереп бара.

Тау төшкәндә, чана бавы абый кулына күчә. Флягага атланып, мунча ишек төбенә килеп туктаганчы, «яхшы ат»ны куалап кайтам.

Кара мичнең «төпсез» казаны, идәндә тезелешеп утырган ләгәннәр, ниһаять, су белән тула. Тәрәзәдән кереп, корымга буялмаган урын эзли-эзли йөдәгән тонык яктылык су өсләренә кунаклый, ә мин ләүкәгә үрмәлим.

Кисәүгач, соскы, колагы купкан калай тас үзара нидер сөйләшеп ала, борынны көл исе кытыклый. Казан эргәсендә ятып сөяккә әйләнгән сөянне әтәйнең иске сугым пычагы чатыр-чатыр телә башлый. Чырагачка ут эленә. Ут теле үрләгән саен, абыйның йөзе яктыра, елмаю булып иреннәренә, күзләренә елтыр балкыш куна. Бераздан дөрләгән чырагач та, абый да юкка чыга – мунча эче тагын караңгыланып кала. Абыйның, зур мич авызына билгә тиң тыгылып, утыннарга ут үрләткәнен белгәнгә генә курыкмый утырам. Менә хәзер ул, күзләрен кысып, йөткерә-йөткерә, кабат мич каршында калкыр да, корымнан бәрхетләнгән стенада кызгылт учак яктысы аның рәсемен ясап куяр.

Мунча ташлары арасыннан, җиде башлы аждаһа булып, төтен күтәрелә – мин, буылып, идәнгә тәгәрәп төшәм, мүкәләп барып, сыкылаган мунча ишеген төртәм. Көттереп, төтенгә уралып, абый да чыга. Күзләреннән яшь акса да канәгать үзе:

– Кабынды, чәй эчкәнче әзер була мунчаң!

Мин төннек янына киләм. Төннектән сузылып чыккан төтен иңемә ак сөлгесен сала.

Беренче пар – безнеке! Мунча чардагыннан, кыштыр-кыштыр, җитәкләшеп, каен себеркеләре төшә. Гөмбәзләп өелгән мунча ташлары сулый – беренче чүмеч су кунып та өлгерми, зәңгәр рәшәле исне алып, төннектән тышка ургыла. Эзләренә басып, мескен бүрек төннеккә кереп оялый. Хәзер нәрсә буласын мин генә түгел, ләүкә астында тынып калган чурылдык бака да чамалый: колакларымны, лепкәмне капларга тырышып, сулы ләгәнгә кереп утырам...

Хәл алырга мунча алдына бергә чыгып кергәлибез. Утыргыч, бозланып, миңа береккәнче, абый яңа гына уйлап тапкан әкиятен сөйли.

Ис-мазар тимәдеме, дип, инәй мунча тирәсен берничә кат урагач, әтәй килеп җитә:

– Кайтасызмы-юкмы, корчаңгы тайлар?!

Канәгатьсез генә җыена башлыйбыз. Нигә инде ашыктырырга – бездән соң кем дә мунча кереп тормый ласа: мунча миче агып киткән була...

Ак мунчаны алма бакчасы уртасына салдылар. Кыш көне иркенләп карда аунарлык булсын, диде абый.

Мичне тимердән ясаттылар. Тамчы су да тәгәрәп китәрлек итеп, идән астына таш түшәделәр.

Бу малайларга ышаныч юк, монысын да черетерләр, дипме, әтәй аскы ниргә буйлап электр җылыткычы сузды. Мәңгегә дип эшләнде ак мунча.

Ә без үстек. Таралдык.

Яллар бергә туры килгәндә, кара мунчаны искә алып, тимер мич урыныннан купканчы чабынган да булды, алмагач төпләрендә карның сыңар карышын да калдырмый аунаган да булды, мунча алдында бал мичкәсе бушаганчы сөйләшеп утырган да булды – ләкин бик аз, бик аз иде ул мәңгелек мунча өчен.

Юл фаҗигасенә каршы кич абый ак мунчага улымны күтәреп китте. Мөгаен, балачакта миңа сөйләгән әкиятләрен исенә төшергәндер...

Абыйны җирләп кайткач, мунча яктым. Пар салып та җылы үтмәгәч, ләүкә буйлап мичкә таба, гадәттә, абый чабына торган урынга күченәсе иттем – тетрәндергеч салкынлык баштанаяк куырып алды...

1997 ■

Киң сибелгән безнең халык жир йөзенә

Киң сибелгән безнең халык жир йөзенә,
Язмыш шулай сипкәндер жир йөзенә,
«Беркемнән дә ким түгелбез!» –
дигән дә ул,
Тугры калган шулай үзенең сүзенә.

Кая барса, орлык булды шул урында,
Хуш исләнеп чәчәк атты жир йөзендә.
Афәтле, фаҗигаи зилзиләләрдән
Саклап калды исемен дә, җисемен дә.

Һөнәр, белем, аң-акыл да алга барган,
Байтак милләт бабалардан үрнәк алган.
Бу дөньяның галимнәре, шагыйрьләре
Төрле телдә татарларны мактап язган.

Асыл тарихыбыз бик тирәндә безнең,
Төшә алсак иде берчак шул тирәнгә.
Белер идек бабаларның эш эзләрен,
Мирасыбыз кат-кат ята шул тирәдә.

Бу байлык, бу мирасны жир йөзеннән
«Безнең мирас» сакланышыннан белгән.
Төрле телдә, төрле илдә язмаларны
Җыеп, туплап, саклап килә жир йөзеннән.

Сөенәсең, шатланасың бу журналга,
Шаккатасың һәр сандагы язмаларга.
Яңартып тарихны, яшәртеп Казанны,
Эшләргә, яшәргә мәңге язсын аңа!

«Безнең мирас»ны укып хәбәрдар булам
Татарымның үткәненнән, бүгененнән.
Чирек гасыр буе тырыш эшләп бара –
Рәхмәтлемен бу журналга чын күңелдән.

Уңыш, гомер, ак юл телим бу журналга,
Барсын ул мәңге армастан алга таба!
Теләп калам саулык-шатлык вә бәхетләр
Бу журналда эшләүче һәрбарчагызга!

Гыйззәтулла Әнвәр улы Хәсән,
Кытай Халык Республикасы. ■

«Безнең мирас» журналының К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында узган 25 еллык юбилее кәнендә. 10 октябрь, 2016 ел

ТАТАРСТАН РӘССАМНАР БЕРЛЕГЕНӘ – 80 ЕЛ

МИЛЛӘТНЕҢ КҮҢЕЛ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Розалина Шаһиева, Расиха Фәизова

«Зур Идел» төбәк күргәзмәсен ачу. Казан, 1991 ел

Рәссамнар берлеге турында сөйләгәндә, бу очракта сүзне аның чишмә башыннан – оешу тарихыннан башлау мәслихәт булыр. Дөрес, олыдан кубып, берлек оештырыла икән, димәк, моның өчен инде өлгергән җирлек булган дигән сүз. Бу җәһәттән күз алдына беренчеләрдән булып, дөньякүләм мәшһүр рәссамнар Николай Фешин, Павел Беньков, Фаикъ Таһиров, иҗатының колачлылыгы, шәхесенең олпатлыгы ягыннан яңарыш чоры иҗатчыларына тиң Бакый Урманче килеп баса.

Әнәс Тумашевның шәхси күргәзмәсе ачылышында

ТАРИХКА КҮЗ САЛСАК

Татарстанда Рәссамнар берлеге оешуга беренче карашка нәкъ менә шундый шәхесләрнең күләмле иҗаты, алар булдырган Казан сәнгать мәктәбе алшарт булып торса да, боерык «өстән» төшә. ВКП(б) өлкә комитеты бюросының «Татарстан Рәссамнар берлеген оештыру турында»гы карары (1935 ел, 3 август) бу җәһәттән беренче рәсми документ санала. Оештыру бюросы (А.Камалетдинов, С.Ахун, Ф.Ильясов, Ш.Мөхәммәтҗанов, В.Родионов, М.Сокольский, К.Счастнев) җитәкчелегендә Казан сынлы сәнгать мәктәбен тәмамлаучылар, клубларда шөгыльләнүче рәссамнар – җәмгысы алтмышлап кеше беренчел берләшмәнең нигезен хасил итә. Иҗади көчләрне үстерү, сынлы сәнгатьнең дәрәҗәсен күтәрү бурычы йөкләнә аларга. Әлеге берлекнең тәүге күргәзмәсе 1936 елда Яшел Үзәндә, ә чираттагысы Казанда – Октябрь революциясенең 20 еллыгына багышлап Менжинский клубында ачыла.

1936 елның 25 июнендә ТАССР Рәссамнар берлегендә составына А.Камалетдинов, С.Ахун, Ш.Мөхәммәтҗанов, В.Родионов, К.Счастнев кергән беренче идарә сайлана. Берлекнең рәисе итеп мәшһүр сәнгать белгече П. Дульский, урынбасары итеп Ф.Ильясов кандидатурасы күрсәтелә. Шушы ук елның декабрендә ТАССР Үзәк башкарма комитеты ТАССР Рәссамнар берлегенең Уставын раслау турында карар кабул итә. Берлек яңа әгъзалар бәрабәренә куәт ала бара. Алар арасында Бакый Урманченың шәкертләре – Казан сәнгать мәктәбендә укыган Х.Алмаев, Г.Мусин, Тукай әсәрләренә иллюстрацияләр ясаган Г.Арсланов, нәкышчеләр Д.Архипов, И.Князьков, К.Максимов, Н. Прытков, С.Федотов, Е.Частихина була.

1939 елның 21 июнендә СССР Халык комиссарлары советының «Рәссамнар берлегенең оештыру комитетын булдыру турында»гы карары чыга. Июльдә аның пленумы уза. Берлек эчендә милли комиссия формалаша һәм шулай ук өлкәләр, автономияле республикалар буенча бер һәм сюздаш республикалар буенча икенче бюро оеша. Шулай итеп, ТАССР Рәссамнар берлеге локаль иҗат оешмасыннан Бөтенсоюз оешмасының бер өлеше булып китә. СССР Рәссамнар берлегенең I съездына әзерлек башлана. Әмма сугыш бөтен планнарны

Бакый Урманче Флора ханым белән (уртада) Рәшит Имашевның шәхси күргәзмәсен ачуда. 1986 ел

челпәрәмә китерә. Съезд бары тик 1957 елның февраль-март айларында гына уза. ТАССР Рәссамнар берлегенең хисаплары Мәскәүдә – СССР Рәссамнар берлегендә тыңлана, әгъзалык составы да шунда – югарыда раслана. Оештыру съездыннан соң, ТАССР Рәссамнар берлеге СССР Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлекчәсе дип үзгәртелә. Һәм ул 1960 елга кадәр шул тәртиптә дәвам итә. РСФСРның оештыру съездында РСФСР Рәссамнар берлеге оеша. Лотфулла Фәттахов, Харис Якупов идарә әгъзасы итеп сайлана. 1968 елда СССР Рәссамнар берлегенең III съездында әлеге берлекләрнең иҗат көчләре союздаш республикаларныкы белән тиңләштерелә. Автономияле һәм союздаш респубикаларның берлекләрендә югары җитәкче орган булып рәссамнар съездлары кала. Татарстан рәссамнар берлегенең I съезды – 1971, II – 1975, III – 1980, IV – 1983, V – 1986, VI – 1989, VII – 1991, VIII – 1996, X – 1996, XI – 1999, XII – 2002, XIII – 2005, ә XIV – 2008 елларда уза. 1968 ел ахырында РСФСР Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлекчәсе ТАССР Рәссамнар берлеге дип үзгәртелә. 1991 елда СССР таркалгач, берлек Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге булып кала. Шул чорда СССР Рәссамнар берлеге әгъзалары Россия Рәссамнар берлеге әгъзалары дип йөртелә башлый.

ДИЛБЕГӘ КЕМ КУЛЫНДА?

П.Дульскийдан соң, 1938 елда берлекнең рәисе итеп Н.Фешинның укучысы, күренекле нәкышчы В.Тимофеев сайлана. Сугышка кадәр бу урында Сәнгать академиясен тәмамлаган талантлы милли рәссам, булачак академик Х.Якупов һәм РСФСРның атказанган рәссамы Л.Фәттаховларның остазы Н.Вәлиуллин да эшләп ала. Кызганыч ки, ул Бөек Ватан сугышында һәлак була. Казаннан сугышка киткән 100гә якын рәссамның, өчтән бере яу кырында ятып кала. 1941-1951 елларда иҗади көчләр «Хезмәт – дөньяның илаһы» композициясе (1930), Куйбышев мәйданындагы Г.Тукай һәйкәле (1958), шул ук вакытта гаҗәеп ыстанлы композицияләр авторы Садри Ахун тирәсендә туплана. Тарихи күләмле эшәре белән «Зур Идел»

төбәгендә генә түгел, ил күләмендә дә танылу алган кылкаләм остасы Харис Якупов Рәссамнар берлеге белән иң озак идарә иткән рәисләрнең берсе буларак тарихка кереп калды (1951-1975). 70 нче еллар урталарында берлек рәисе булып сайланган Әнәс Тумашев исә берлек тормышына яңалыклар кертүчеләрнең берсе буларак таныла. Ул сынлы сәнгатьне һәрьяклап үстерүне алга сөрә. Васил Маликов, Әмир Мәҗитов, Надир Әлмиев рәислек иткән 80-90 нчы елларда сынлы сәнгатьтәге төрле агымнар, юнәлешләр үсүгә юл ачыла. 90 нчы еллар сынлы сәнгатькә гомумән дә алгарыш ритмы бирә. Бу чорда «Тамга», «Дастан», «Әлиф» кебек яңа иҗат төркемнәре калкып чыга.1993-2008 елларда монументалист, ыстанлы картиналар һәм фәлсәфи композицияләр остасы Абрек Абзгильдин иҗатчыларның әйдаманы була. Аннан соң бу җаваплы постка Зөфәр Гыймаев сайлана һәм иҗади берлекне 2013 елга кадәр җитәкли. Шактый ыгы-зыгылы, тынгысыз чор була ул. Биналар, остаханәләрне даулап-яклап, Зөфәр Гыймаевның үзенә дә, идарә әгъзаларына да мәхкәмә юлларын шактый гына таптарга туры килә. Үзгәртеп коруның шаукымы, гомумән вазгыятьтәге тотрыксызлык, билгесезлек берлекнең эчке структурасында да, рәссамнар иҗатында да чагылмый калмый. Тора-бара республикада рәссамнарның берничә иҗади оешмасы барлыкка килә: Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан бүлекчәсе (рәисе В.Аршинов), Татарстан Рәссамнары берлеге (җит. З.Гыймаев), Россия рәссамнарының Татарстандагы иҗади берлеге (И.Самакаев), Россия Рәссамнар берлегенең Чаллы бүлекчәсе (Ф. Гайфетдинов) һ.б.

ИҖАДИ ДУЛКЫНДА

Нинди генә дәвер булмасын, иҗат көчләрен үз канаты астына алган Рәссамнар берлеге һәр чорда заман таләпләренә үз телендә, үз ысуллары белән җавап биреп килә. Үткән елларның иҗади сулышын, кайтавазын без бүген музейларның йөзен билгеләүче, тарихка кереп калган шаһ әсәрләрдә, шәһәр панорамасын тәшкил иткән сын-ансамбльләрдә, һәйкәлләрдә, сәнгать музейлары-галереяларда күрәбез. Милләтебезнең үткәнен, туган җирнең гүзәллеген, бүгенге көндә барган үзгәрешләрне эпик хикәяләр рәвешендә Идел, Россия киңлекләренә, шәрык-мәгърип тарафларына җиткерүдә Рәссамнар берлегенең әһәмияте бәхәссез. Аның әйдаманлыгы бигрәк тә узган гасырның 1930-50 нче елларында – бүгенге татар сынлы сәнгатенең нигезе формалашкан вакытта аеруча ачык чагылды. Нәкъ шул чорда ул, иҗади академик реализм юнәлешенең лидеры буларак, Идел белән Урал арасындагы этник иҗат оешмаларына өлге булып торды.

Иҗатта төрле агымнар баш калкыткан 20 нче еллар ыгы-зыгысы шартларында әлеге оешма кешелеклелек, ватанпәрвәрлек традицияләрен саклауда ышанычлы механизм һәм милли кадрларны туплау, осталыкларын үстерү мәктәбе булып тора.

Эшчәнлегенең башлангыч чорында ук Рәссаммнар берлеге хакимияткә сукырларча хезмәт итүне түгел, ә чын милли, рухи яктан камил һәм сәнгати яктан өлгергән, алдынгы идеяләрне алга сөрүне һәм зәвыклы әсәрләр тудыруны максат итеп куя. Бу чын мәгънәсендә милли рәсем сәнгате мәктәбенең нигезен кору була. Дәүләт ярдәме, төпле белем һәм югарыдан төшкән заказлар булмаса (соцзаказ), яңа сәнгать үзәкләре дә булмас, төбәкләрдән сәләтле милли рәссамнар дә үсеп чыкмас, моңарчы ислам кануннарының сурәткә табынуны тыюы аркасында йөз еллар дәвамында тоткарланып килгән сурәтчелек тә үсеш алмас иде. Хаталанган, абынган-сөртенгән чаклар булса да, рәссамнар каршылыклар аша барыбер алга омтыла. Тагын шунысы игътибарга лаек:

Рәссамнар берлеге шәхеснең үзгәлеген юкка чыгаручы, тормышның караңгы якларын сурәтләүче бюрократик машинага әверелми, ә киресенчә, сәяси конформизмга бирешмичә, кешене изә торган җәмгыятьне тәнкыйтьләп, тормышның яңа әхлакый кануннарын, үсешен пропагандалаучы зур көчкә әйләнә.

Иҗат ысулы булган соцреализмны примитив аңлаудан узып, символларга һәм гомумиләштерүгә, дөнья сәнгатенең гүзәл үрнәкләрен үзләштерүгә йөз тота. Алга таба да ул, җәмгыяттәге иҗтимагый һәм иҗади әһәмиятле мәсьәләләрне чишүдә, авылларны һәм шәһәрләрне эстетик яктан үзгәртеп корудa, кешенең рухи дөньясын матурлык белән баетуда төп плацдарм һәм әйдәүче көч булып кала. 50-70нче елларда берлекнең көче совет җәмгыятенә хас булган үзгә сәнгать дөньясын – үзенең архитипларын – юлбашчылар, инкыйлаб каһарманнары, милли хәрәкәт лидерлары образлары тудыруга (В.Ленин, Г.Тукай, М.Җәлил, М.Вахитов); сугыш һәм авыл темасы, тарих һәм иҗат әһелләре, замандашлар галереясын булдыруга юнәлтелә. Бу чорда сәнгать билгеле бер идеология һәм пафос кысаларында яктыртылса да, барыбер ул шул җәмгыятнең яшәеш хроникасын сурәтли. Шунысын да әйтергә кирәк, бу заманда татар сынлы сәнгатендә тыныч тормышның кадерен белеп, глобаль үзгәрешләр яктылыгында эшләнгән иң саллы эпик әсәрләр дөнья күрә. Нәтиҗәдә, илгә җиңү яулаган, тыныч тормышка мәдхия укучы җир кешесе образы алга чыга (Харис Якупов «Һөкем алдыннан», «Көтүчеләр», «Көчле рухлылар», «Татарстанның кара алтыны»; Лотфулла Фәттахов «Сабантуй», «Яңа буралар», Исмәгыйль Хәлиуллов «Җир хуҗалары», Валерий Скобеев «Кама өстендәге акчарлаклар», «Юл», Илдар Зарипов «Өйдә», «Нефтьче Әхәт абый», Шамил Нигъмәтуллин «Чишмә буенда» һ.б.)

Татарстан сынлы сәнгатенең йөзен билгеләүче сюжетлы, тематик картиналар белән беррәттән, таләпчән күргәзмә комитеты аша узып, тамашачыга табигатьнең лирик күренешләре, замандашларның сөйкемле йөзләре, узган дәверләрнең күренер-күренмәс образлары, XX гасыр башы мәдәниятенең тамга-символларын, борынгы мифология, фольклор, ислам һәм тәңречелек пантеонын сурәтләгән әсәрләр туа. Бу чор – чыннан да, югары идеяләр хакына, «куып җитәргә һәм узып китәргә», «коммунизм төзибез» дип хыяланып йөргән, яшәгән заман. Бинаһая идеаллар, рухи күтәренкелек зур әсәрләр тууга сәбәп була. Ни гаҗәп, әлеге әсәрләр бүгенге көндә дә үз кыйммәтләрен югалтмый.

XX гасыр сәнгатенең икенче яртасында, 1958 елда Казанга кайткан Бакый Урманче иҗади мохитнең формаль булмаган лидеры булып тора. Ул, Урал мәрмәреннән уеп, татарның күренекле шәхесләренең портрет галереясын булдыра. Тукайга багышланган иллюстрацияләрдән алып, гасырлар дәвамында кыйммәтен җуймаган «Сагыш», «Язгы моңнар», «Сөембикә» (агач сын) кебек әсәрләр иҗат итә. Аның әлеге эшләре Татарстан сынлы сәнгатендә яңа чор башлануын гәүдәләндерә. Милли тарих яңадан кайта. Бер чор эчендә генә кайнау инстинкты бетә, бүгенгегә үткән чорлар килеп кушыла, яңа киң тарих форматы, яңа вакыт ритмнары, киң сурәтләү географиясе, дөньяның глобальлеген тою һәм элек кагылгысыз булган темалар «казып чыгарыла». Урманченың иҗаты башка рәссамнарны да кузгатып, уятып җибәргәндәй була. Шушы дулкында кыйммәтле, зиннәтле әсәрләр туа: Илдар Зариповның «Шагыйрьнең тууы», «Кырлай моңнары», Абрек Абзгильдинның «Тукай һәм Шүрәле», «Тукай төше», Рөстәм Килдебәковның «Дүрт сеңел», Тавил Хаҗиәхмәтовның «Йосыф вә Зөләйха» әсәренә иллюстрацияләре, Васил Маликов,

СССР Сынлы сәнгать академиясенең иҗат остаханәсе рәссамнары (сулдан уңга): Станислав Слесарский, Олег Сильянов, Шамил Шәйдуллин, Зөфәр Гыймаев, Харис Якупов һәм Фәрит Якупов. 1978 ел

Рада Нигъматуллинаның сыннары дөнья күрә. Бу берлекнең иҗат дәверендә яулаган иң бөек ноктасы булып тора. Әлегә! Чаллыда КамАЗ төзелеш индустриясе үсеш алган һәм респубикадагы башка илкүләм алгарышлар сынлы сәнгатьнең үсешенә, берлекнең ныгуына китерә. КамАЗ «симфониясе» белән рухланып яшәү сәнгатьтә репортаж стиле тууга сәбәп була. Шул ук вакытта төзелештә дивар бизәмнәре, витражлар, ял итү урыннары, музейлар, иҗтимагый үзәкләр калкып чыга. Монументаль сәнгать, тарафдары Илдар Ханов белән бергә, Чаллыдан Казанга да килеп җитә. Борынгы Казанны төзекләндереп яңартуда, мәдәният сарайлары, кунакханәләр, кафе, предприятие холларында борынгы фреска, мозаика, инкаустика өслүбләрендә башкарылган заманча сәнгати мифлар туа башлый (Игорь Башмаков, Абрек Абзгильдин, Виктор Федоров, Рөстәм Килдебәков). Практика күрсәткәнчә, иҗади оешманың көче, аның төрле юнәлештә иҗат итүче рәссамнарының күмәк иҗаты (сынчылар, нәкышчеләр, графиклар, кулланма гамәли сәнгать) тирәлеккә, яшәешкә үтеп керүе бәрабәренә үсә, ныгый. Иҗаткярларны биналарның эчке-тышкы бизәлеше дә, урам дизайны, театр куелышлары, китап бизәү эше дә битараф калдырмый. Оешманың зур тәрбияви эше булып, төрле югарылыкта барган федераль һәм җирле күргәзмә сәясәте тора. Ул рәссамнарны туплау, яңаларын ачу, сәнгатьнең күптөрлелеген күрсәтү, мирсабызны торгызу, музейларда яңа тупланмалар булдыру мөмкинлеге бирә.

Декада, юбилей, шәхси, Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия күләмендә барган күргәзмәләр белән беррәттән, бөтен Идел буе цивилизациясен туплаган, профессиональлекне үстерүче, мил-

Күргәзмә комитеты булачак экспозициягә эшләр сайлый. Март, 1987 ел

ли горурлыкны саклаучы «Зур Идел» күргәзмәсенең әһәмияте бик зур. Татарстан сәнгатен баетуда, аның борынгы этногенетик (кан бәйләнешын) күзәнәкләрен-тамырларын барлаган, сурәтләгән Уфа, Ташкент, Нукус, Бакуда һ.б. калаларда узган күргәзмәләрнең бәһасе әйтеп бетергесез. Патриотик һәм әхлак тәрбиясе өлкәсендә Бөек Җиңүнең түгәрәк даталарына багышланган күргәзмәләрнең кайтавазы горурлык тудыра. Аларда тарихи хәтер темасы фәлсәфи, метофорик яңгыраш таба. Ниһаять, 80 нче елларда Рәссамнар иҗат берлегендә бөтен актуальлеге белән милли сәнгать тудыру проблемасы калкып чыга. Үзгәртеп кору, җәмгыятьне либеральләштерү, дөнья мәдәниятенә һәм тарихына юл ачылу, дөнья мәдәнияте эталоннарына йөз тоту – сәнгать формасы белән генә түгел, ә эчтәлеге белән дә самими, милли була ала, дигән яңа инкыйлаби фикер тудыра. Дөньяны яңача күзаллауның чагылышы аксакалыбыз Бакый Урманченың 85 еллыгына багышланган юбилей күргәзмәсендә ачык күренә. Шәрык миниатюраларына йөз тоткан, катып калган калыплар һәм күрү стереотипларын җимерүче истәлекләр эпосында автор йөзьеллыкларны бер учка җыеп-туплап, нәфис сәнгать югарылыгында ачыктан-ачык сурәтләп, ниһаять, милли омтылышларны билгеле бер чор идеологиясе кысаларыннан иркенлеккә чыгарды.

Дөньяны киң итеп күзаллау Тукайның 90, 100, 130 еллыгына багышланган күргәзмәләрдә дә чагылыш тапты. Әлеге тема өстендә эзлекле рәвештә эшләүче рәссамнарыбыз да шактый.

Мәңгелек темалар СССР Сынлы сәнгать академиясенең Казандагы нәкыш остаханәсендә академик Харис Якупов кул астында иҗат иткән шәкертләре – Станислав Слесарский, Фәрит Якупов, Зөфәр Гыймаев, Шамил Шәйдуллин, Фиринат Халиков, Олег Сильянов, Владимир Акимов, Дания Шәймәрданова, Равил Заһидулиннарга һ.б.га да шөһрәт тажы кидертә... Идел һәм Урал төбәгендә рәссамнарга канат куйган Казан сәнгать мәктәбе кебек, Харис Якупов остаханәсе дә (1976) бөтен төбәктә югары әзерлекле рәссамнар тәрбияләү мәктәбе була һәм югары уку

йорты системасына бәрабәр булып, иҗат берлегенә ныклык һәм осталык иңдерә. Әлеге остаханәдә тәрбияләнгән яшьлек дәрте ташып торган талантлар дулкыны хисабына Рәссамнар берлеге Чаллы һәм Түбән Камада берлекнең секцияләрен оештыра.

Бүгенге көндә Сәнгать академиясенең Казандагы остаханәсе белән Фиринат Халиков җитәкчелек итә.

Түбән Кама шәһәрендә үз вакытында техноген мәдәниятен татыган һәм табигый матурлыкка йөз тоткан тәңречелеккә (җир, урман, су, йорт, абзар ияләре) багышланган картиналар сериясе эшләгән Тукай премиясе лауреаты Әхсән Фәтхетдинов кебек киңкырлы фәлсәфәче рәссамнар иҗат итә (Зиннур Миңнәхмәтов, Рабис Сәлахов, Хәмзә Шәрипов). Кама аръягынының данын Владимир Акимов, Виктор Анютин, Виктор Сынков, Хәмзә Шәрипов, Факил Гайфетдинов кебек рәссамнарның иҗаты билгели.

90нчы елларда Рәссамнар берлеге өчен катлаулы чор башлана. Моның сәбәбе беренче чиратта СССР таркалуга бәйле. Һәртөрле чикләүләр, тыюлар бетерелеп, берлек киң иҗат дәрьясына чыга. Шушы шартларда рәссам үзенең мөстәкыйльлеген, яшәргә сәләтлелеген, үз йөзен күрсәтергә тиеш иде. Хөррият һавасы әкренләп иҗат егәренең яңа мөмкинлекләренә юл ача. Тарихны бербөтен итеп карап эшләү, үзеңнең башкаларга охшамаганлыгыңны күрсәтү мөмкинлеге туа. Бу чорда Татарстан сәнгатендә ике юнәлеш өстенлек итә: авангард һәм реализм. Күргәзмәдән күргәзмәгә алар бер-берсен тулыландырып килә. Меңьеллык Казан, Борынгы Болгар һәм Алтын Урдага багышланган тарихи картиналар белән беррәттән, иронияле һәм төртмәле соц-арт, «этнофутуризм» яки «татавангард» һәм реализм бер-берсе белән чиратлашып килә. Агымнар киселешендә Татарстан сәнгате өчен гаҗәеп күренеш – Әлфия Ильясованың иҗатына моңа кадәр хас булмаган дини тематика (мөселман апокрифлары), Булат Гильвановның алтай-төрки һәм болгар мифлары, Фәридә Хасьянованың сабый күңеленә туры-дан-туры юл салган тылсымлы китап бизәмнәре; Канәфия Нәфыйков, Фиринат Халиков һәм Рөстәм Хуҗинның тарихи эпопеяләре, Владимир Поповның гарәби графикасы, Ирик Мусинның хисле, зур динимик көчкә ия ретролары, Альфрид Шәймәрдановның самими, халыкчан сурәтләре, Анатолий Егоров һәм Евгений Голубцовның «храм бизәмнәре», Илгизәр Хәсәновның үзенчә яңартылган модерны, Әнвәр Сәйфетдиновның үзенчәлекле техникасы (пуантилизм), Михаил Кузнецовның бизкләре, Роберт Гайсинның «эзотерик» табышлары, Мәхмүт Гасимов һәм Рөстәм Габбасовларның мәһабәт сыннары, Александр Шадрин һәм Александр Дорофеевның һәркайсы җырлап торган «шигъри кыйссалары» дөнья күрә. Бердниковлар гаиләсе дә эшләрендә кешелеклелек тойгыларының ныклыгы, Рәшит Газеев нәзәкатьлелек белән, Анна Куртева теләсә-кайсы бинага затлылык сирпүче витражлары; Владимир Акимов юморга төрелгән фәлсәфәсе; Виктор Тимофеев кабул ителгән үлчәмнәрдән тайпылышы белән иҗат мохитенә үз йогынтыларын ясый киләләр.

Кул һөнәре сәнгатен торгызуга рәссамнар шулай ук зур өлеш кертә. Нәкъ менә 90нчы елларда зәркәнчелек, каюлы күн, алтын җепләр белән чигү һәм каллиграфия-хаттатлык үткәннәр белән хәзерге заман сәнгатен тоташтыру дәверен кичерә (Наилә Кумысникова, Софья Кузьминых, Светлана Гарбузова, Илдус Гайнетдинов, Нәҗип Нәккаш, Владимир Попов, Рәфкать Мөхәммәтшин, Шамил Хәялиев, Ирина Васильева, Луиза Фәсхетдинова, Земфира Бикташева, Наилә Галәвиева, Зөфәр Низаметдинов һ.б.).

Татарстан мәдәнияте тарихында күренекле чор дип ТАССР Сынлы сәнгать музее экспозициясе ачылуны

санарга кирәк (1959-1967). Биредә рус һәм Көнбатыш Европа сәнгатен күрсәтү белән беррәттән, Болгар чоры һәм 1920-1930 еллардагы татар сәнгате бүлекләре, Казанның мәшһүр рәссамы Николай Фешин иҗатына багышланган зал да ачыла. Меңьеллыкка аяк баскан-да бөртекләп җыелган милли мирас һәм Татарстан, Россия рәссамнарының иң яхшы әсәрләреннән Милли мәдәният музее формалаша. Шул ук вакытта аның струтурасында Казанның 1000 еллыгы музее барлыкка килә. Анда соңгы дистә елларда «Нурлы Казан», «Татарстан табигатенә мәдхия», «Тарих дулкынында Болгар чоры» дигән, Россиядә һәм дөнья буйлап сибелеп яшәүче татар рәссамнары иҗатына багышланган эшләр туплана.

1997 елда «Казан» милли мәдәният үзәге базасында, Рәссамнар берлеге белән берлектә, Бакый Урманче музее, 2003 елда Илдар Зарипов, 2005 елда Әмир Мәҗитов галереялары ачыла. «Казан Кремле» тыюлыгы территориясендә 2005 елдан эшли башлаган «Хәзинә» милли сәнгать галереясы җирле сәнгатьне эзлекле рәвештә мәрҗән кебек бер җепкә тезеп күрсәтә башлады. Биредә милли бизәк традицияләрен үз эченә алган кулланма гамәли сәнгать үрнәкләре белән беррәттән, классик сынлы сәнгать үрнәкләрен дә күрергә була. Бүген дә Татарстан Милли музее, Болгар дәүләт тарихи-архитектура тыюлыгы, Габдулла Тукай әдәби музее, Җәлил музее һ.б. бүлекләре рәссамнарның яңадан-яңа эшләре белән тулылана бара.

Рәссамнарның иҗатын респубика дәрәҗәсендә билгеләп узу традициясе дә үз җимешләрен бирә. Төрле елларда Харис Якупов, Лотфулла Фәттахов, Сергей Лывин, Виктор Куделькин, Васил Маликов, Әнәс Тумашев, Тавил Хаҗиәхмәтов, Илдар Зарипов, Әхсән Фәсхетдинов, Шамил Шәйдуллин, Зөфәр Гыймаев, Искәндәр Рәфыйков, Фиринат Халиков, Абрек Абзгильдин, Николай Индюхов, Софья Кузьминых, кызлары Изабелла Рогожина һәм Марина Нигъмәтуллина белән Рада Нигъмәтуллина, Виктор Аршинов, Илдар Ханов, Сергей Скоморохов, Асия Миңнуллина, Владимир Попов, Ирина Колмогорцева, Нәҗип Исмәгыйлев (Нәккаш), рәссамнар төркеме – Фәрит Вәлиуллин, Александр Леухин, Илья Артамонов, Рәшит Шиһабетдинов һ.б. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булдылар.

1999 елда Татарстан мәдәният министрлыгы сынлы сәнгать өлкәсендә уңыш казанучылар өчен Бакый Урманче премиясен гамәлгә куйды. Рәссамнардан Григорий Эйдинов, Анатолий Егоров, Зөфәр Гыймаев, Илдар Зарипов, Абрек Абзгильдин, Булат Гильванов, Игорь Башмаков, Наилә Кумысникова, Фәридә Хасьянова, Зөфәр Низаметдинов, Нияз Хаҗиәхмәтов, Ирина Васильева, Равил Заһидуллин, Рәшит Газеев, Рабис Сәлахов; сәнгать белгечләреннән Динә Вәлиева, Розалина Шаһиева, Роза Солтанова, Йолдыз Нигъмәтҗанова, Лилия Саттарва, Рөстәм Шәмсутов, Ольга Улемнова һ.б. төрле елларда ия булды әлеге бүләккә.

Рәссамнар еллар дәвамында иҗади дулкында яши. Сынлы сәнгать музеенда шәхси, тематик, күпжанрлы күргәзмәләр берсе үкчәсенә икенчесе басып килә. Үзебезнекеләр белән беррәттән, Бөтенроссия һәм дөнья дәрәҗәсендәге осталар да читләтеп узмый Татарстанны. Елның-елында узучы Республика һәм шәһәр көненә багышланган күргәзмәләрдә катнашу шулай ук дәрәҗә санала. Рәссамнарның эшләре чит илләрдә дә куела. Көнбатышта, Көнчыгышта, Франциядә, Голландиядә, Финляндиядә, Венгриядә, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә, Пакыстан, Төркия һәм Кувейтта уңыш белән узган күргәзмәләр аша рәссамнар татар дөньясын, милли рухыбызны чит илләргә таныта. Чит кыйтгаларда күргәзмәләр элек тә булган. Татар

Татарстан рәссамнары Кувейтта. («Татарстан сәнгате» проекты). 2010 ел

графикасының 1931-33 елларда Парижда, Чикагода күрсәтелүе турында үз вакытында сәнгать белгече Пётр Дульский илһамланып язган. Казанның 1000 еллыгына багышланган күргәзмәләр исә төрле мәйданнарда еллар дәвамында барды.

Шөкер, әле булса рәссамнарны рухи берләштереп торган урын булып остаханәләрне атыйбыз. Зур Кызыл урамында урнашканына 1980 елда узган «Зур Идел» төбәк күргәзмәсенә әзерлек барышында реконструкция ясалды. Иске бинага заманча күргәзмәләр залы өстәп салынды. Әлеге зал бүгенге көнгәчә сәнгатькә хезмәт итә. Хәзерге вакытта биредә Заманча сәнгать галереясы эшләп килә. Остаханәләр дә чын мәгънәсендә иҗат лабораторияләре булып кала бирә. Елдан-ел яңа проектлар гамәлгә аша бара. Әйтик, Кырымда, Болгарда, республика районнарында пленэрлар уздыру, өр-яңа галереяларның нигезен тәшкил итәрлек эшләр бүләк итеп калдыру, галереялар ачу инде матур традициягә әйләнеп бара. Казанлылар күз алдында күргәзмәдән күргәзмәгә сынлы сәнгать күгендә яңа исемнәр калкып чыга. Эстафета әкренләп Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтының Казан филиалы, Н.Фешин исемендәге сәнгать училищесы аша узып, Татарстанның сынлы сәнгать ташкынына яңарыш рухы алып килүче яшьләр кулына күчә бара. Югарыда Рәссамнар берлеге тарихында иң беренче булып уздырылган күргәзмә уңаеннан Яшел Үзәнне телгә алган идек. Быелның 16 ноябрендә, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлекчәсенең яшьләр секторы (җит. Илнур Сираҗиев), моннан 80 ел элек булган прецедентны кабатлап, янә Яшел Үзәндә күргәзмә ачты. Ул көнне экспозициягә куелган барлык эшләр, җуелмас хәтер символы булып, Яшел Үзән галереясына бүләк ителде. Бер сүз белән әйткәндә, рәссамнарның иҗат эпопеясы дәвам итә.

Фотолар Рәссамнар берлекләре архивыннан алынды. ■

Һади Атласи
(1876-1938)

Һади Атласи.
1920-1930 нчы еллар

Тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Һади Атласи (Мөхәммәтһади Мифтахетдин улы Атласов) инкыйлабка кадәр үк үзен «татар патриоты» (академик В.В.Бартольд сүзләре) итеп танытa, хөкүмәтнең шовинистак законнарын каты тәнкыйть итә, татар халкы тарихын яктырткан китаплар яза. Эшчәнлеге өчен аңа патша заманында шактый кыен ашарга, берничә мәртәбә төрмәдә утырып чыгарга туры килә. Мондый шәхес, хакимият формасы нинди генә булмасын, Россия өчен һәрвакыт дошман саналачак, билгеле.

1935 елның 22 маенда Һади Атласи Сталинга хат аша мөрәҗәгать итеп карый. «Хәзер мин эшсез, ач, минем адреска гаепсезгә төрле җәберләүләр күрсәтелә», – дип яза һәм илбашыннан эшкә урнаштыруда, пенсия билгеләүдә ярдәм сорый. Ләкин, әлбәттә, җавап алмый. Хатта мондый юллар бар: «Мин, карт иҗтимагый һәм фәнни хезмәткәр, төрки-татар дөньясының революционеры, бу өлкәдә үткән гасырның соңгы елларыннан бирле эшлим... Мин татар революционерларының беренчеләреннән, урыс самодержавиесенә һәм мөселман руханиларына каршы күп булмаган көрәшчеләрнең беренчеләреннән, татар мәктәпләрендә география, табигать белеме, физика һәм арифметика фәннәрен укытуны башлап җибәрүчеләрдән. Иҗтимагый тормышта зур гына урыннар биләдем: II Дәүләт Думасы депутаты буларак, эсерлар фракциясендә идем. Бу партиядә мин 1905 елдан 1918 елга кадәр булдым. Аннан чыгуымның сәбәбе эсерлар белән Брест-Литовск килешүе һәм сугыш мәсьәләсе буенча каршылык иде. 1906 елда язган брошюра һәм революцион эшем өчен 1909 елда мине хөкем итеп крепостька яптылар, шул ук елны эшемнән алдылар. 1908 елдан 1917 елга кадәр полиция күзәтүе астында һәм хокуклардан мәхрүм ителгән идем».

Бөгелмәдән Казанга килеп ике ел да тормаган килеш – 1936 елда Атласи тагын кулга алына. Тикшерү эшләре башлана. Тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесенә контрреволюцион оешма төзү, солтангалиевчелек, Төркия файдасына шымчылык итү гаепләре тагыла. Алай гына да түгел, тулы бер «Атласов эше» булдырылып, тагын егерме дүрт кеше кулга алына, аларга да «төрек шпионнары» ярлыгы тагыла.

Казанның НКВД базларында 1936 елның августыннан 1937 елның маена кадәр Һади Атласидан уналты тапкыр сорау алалар. Аларның кайберләре өчәр сәгатькә сузыла. «Ничек булдыра аласыз, шулай эшләгез!» – дигән күрсәтмә нигезендә палачлар татар мәдәнияте, тарихы, әдәбияты һәм сәнгате әһелләре өстеннән ил күләмендә шау-шулы процесс ясарга уйлый. Татар зыялыларының Һади Атласи җитәкчелегендәге гаять зур яшерен оешмасы, имеш, эшче-крестьяннар властена каршы көрәш алып барган, совет җитәкчелеген террорчылык белән җиңәргә омтылган!

Тикшерү барышында Атласи үзенең вак-төяк гаепләрен таный: «География дәресләрендә союздаш республикаларның үсү мөмкинлекләре күп, автономияле республикаларда бу мөмкинлекләр юк, чөнки ул бары тик автономия генә, дип сөйләдем». Бу, билгеле, совет хакимиятенә каршы чыгу дип бәяләнә. Ләкин «кирәкле мәгълүмат» алынмаганлыктан, ә гаепләнүчеләр барлык гаепләрне кире какканлыктан, «зур процесс» була алмый кала. Сорау алулар туктатылып, Һади Атласига бер айлык «ял» бирәләр, ягъни эш тикшерүче бүлмәсендә түгел, ә төрмә камерасында дәвам итә. Нәтиҗәдә, аны 1937 елның 3 маенда, ниһаять: «Милли контрреволюцион оешма төзедем, бары тик мин генә оештыручы булдым, мин – пантюркист, милләтче, солтангалиевче. Бөтен төрки-татарларны берләштереп, мөстәкыйль буржуаз-демократик дәүләт төзергә теләдем. Чит илдәге совет дошманнары белән элемтә тоттым», – дип таныклык бирергә мәҗбүр итәләр.

Шул ук елның 23-28 октябрьләре аралыгында Идел буе хәрби округы хәрби трибуналының ябык утырышлары Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы, 26 адресы буенча урнашкан бу бина бүген Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Мәдәният үзәге буларак билгеле. – *Р.М.*) «Атласов эше»н карый. Медицина эксперты судка китерелгән Һади Атласи турында «невроз һәм гәүдә тотышы зәгыйфьләнгән, ләкин сорау алуга яраклы» дигән белешмә бирә. Тоткынның соңгы сүзе кыска була: «Мин беркайчан да шпион, террорчы булмадым, бернинди яшерен оешмалар, заговорлар оештырмадым. Мин – хәзерге вакыт кешесе түгел, үткән заманныкы».

Хәрби трибунал карары белән тугыз кеше – Һ.М.Атласов, Р.Я.Яруллин, К.К.Туйкин, Б.Ф.Фәттахов, Ф.К.Туйкин, Г.А.Алтынбаев, К.Л.Исхаков, С.Ш.Уразманов, З.Б.Фәттахов атып үтерелергә хөкем ителә. Хөкем карары 1938 елның февралендә гамәлгә ашырыла.

Шул рәвешле, Һади Атласига карата патша хөкүмәте башлаган эзәрлекләү эшен совет хөкүмәте «уңышлы» рәвештә тәмамлый.

Рүзәл Мөхәммәтша әзерләде. ■

Әдәбият

Казан ханлыгы / Һади Атласи. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.

P.S. Һади Атласиның тормышы һәм эшчәнлеге турында тулырак мәгълүматны Фәүзия Бәйрәмованың «Соңгы туранчы...» мәкаләсеннән («Казан утлары»ның 8, 10, 11 саннары, 2016 ел) алырга мөмкин.

В.Зотов фотосы

БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ

Минвәгыйз Зәйнетдинов

Бу рәсемгә күз салгач, журнал укучыбызның: «Нинди хәрабәләр уртасында басып тора икән болар?» – дип уйлап куюы бар. Юк, ялгышасыз, хөрмәтлем. Г.Камал театрының Кабан күле буенда төзелүче, киләчәктә җилкәнле корабны хәтерләтеп торачак матур яңа бинасы төзелешендә өмә көнне, 1985 елның апрелендә алынган рәсем бу. Ә анда мин (сулдан икенче) обкомда бергә эшләгән хезмәттәшләрем Равил Йосыпов (сулдан беренче), Салих Гарипов һәм Дина Свирская белән бер-ике минут ял итеп алган мизгелдә сурәтләнгәнбез. Ул заманда Ленин туган көнне өмәләр ел саен, илнең һәр шәһәрендә һәм авылында үткәрелә иде.

Рәсемне әле дә кадерләп саклыйм. Ул миңа яшьлегемдә театр әһелләре белән аралашкан елларны искә төшерә. Университетны 1959 елда «Шәриф Камалның «Козгыннар оясында» драмасының сәхнә тарихы» дигән темага диплом эше яклап тәмамладым. Моның алдыннан миңа театрда күренекле артистларыбыз Хәлил ага Әбҗәлилов, Хөсәен ага Уразиков, Нәҗип ага Гайнуллин, режиссёр Шерияздан ага Сарымсаков белән очрашып сөйләшергә туры килде. Чөнки аларның әлеге драманы сәхнәләштерүдә турыдан-туры катнашы булган.

Ни кызганыч, аларның барысына да М.Горький урамыннан яңа бинага күчеп, иҗади эшчәнлеген дәвам итәргә насыйп булмады. Сәхнәдә өлкәннәрне Мәскәүдә укып кайткан щепкинчылар, яшь талантлар алмаштырды.

Театр-сәхнә җене үземә дә кагылган иде. Укуымны бетереп, Камышлыга эшкә баргач (Самара өлкәсе), авыл яшьләре белән өч татар драматургының пьесасын сәхнәгә куйдык. Без яшь чакта спектакльләр уйнап торган театр бүген дә исән, аңа хәтта халык театры исеме бирелгән.

Г.Камал театры бинасының ишеген ачып кергәндә, кылт итеп әлеге өмә көне, дусларым-хезмәттәшләрем, студент чакта аралашкан бөек артистларыбыз хәтергә төшә. ■

Үткәннән хат

Күптән түгел республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Тәүфикъ Әйдинең тууына 75 ел тулуны билгеләп үтте. Игътибарыгызга язучының замандашы, дусты Айдар Хәлимнең моннан нәкъ унҗиде ел элек Тәүфикъ Әйдигә язган хатын һәм аның вафатына нисбәтле мәрсиясен тәкъдим итәбез.

Айдар Хәлимнән – Тәүфикъ Әйдигә

Сөекле Тәүфикъ дустым!

Таң калырлык! Әле кичә генә без синең белән әллә «Татарстан яшьләре»ндә, әллә Тукай клубында, әллә башка берәр урында танышкан һәм, эт балалары шикелле иснәшеп, гомерлеккә дуслашкан идек, инде менә... безгә дә алтмыш! Безме бу? Бәлки без түгелдер? Синең тетрәткеч хатыңны укыганнан соң берничә атна һушыма килә алмый йөрдем, дисәм дә хак булыр.

Дустым, сиңа эш белән үзеңне кисү чамасын бераз кыскартырга иде. Унбер томлыклар, алар безгә никадәр газиз булса да, бетмәс. Бәлки без, бер унлап кеше табылсак, дуслар булып, ул син әйткән 160 долларны пай башлангычында ай саен таба да алган булыр идек. Ул аена биш мең сумга якын, дип әйтергә мөмкин инде. Дүрт мең с чем-тодыр инде. Ун кешегә аена бишәр йөз сум, әйтик. Мин аны арттыра алыр идем. Калганнарын каян табасың мондый дусларның? Тәүфикъ, син бик яхшы врачлар белән киңәшеп кара әле, без ярдәм итә алырлык берәр нәрсә юкмы? Әйтик, нинди дер бик шәп санаторий. Анда барып, җитәкчелек белән сөйләшеп, сине урнаштырып булыр иде. Мәсәлән, «Ижминводы». Ул шулкадәр яхшы санаторий икән! Күптән түгел анда анасы белән минем кече кызым ял итте. Баш врачы татар, диделәр. Әгәр син миңа добро биреп хат язасың икән, мин анда барып, сине берәр айга бушка урнаштыра алыр идем бәлки. Югыйсә, анда хаклар 15-20шәр мең, диләр. Уйлап кара әле. Һәрхәлдә ял – ял инде, эш түгел.

Фото өчен рәхмәт. Аны миңа Га-

СССР Язучылар союзының Югары әдәби курсларында укучылар Горкидагы Ленин музее янында. Икенче рәттә – Тәүфикъ Әйди (уңнан бишенче), Айдар Хәлим (уңнан дүртенче) янәшә. 1983-1985 еллар

таш биргән иде. Фото яхшы булмаса да, фотограф идән астыннан «төшерә белгәч», борыннар югары чыккан. Бер Казанга барганда сиңа керәм, кунам һәм, Алла боерса, матур итеп фотога төшәрбез, яме?

Ташкент тарафларына баруым турында «Мәдәни җомга»га кәмпүтердә 30 битләп «материал» язып бирдем. Туракламасалар, матриалы яхшы – «аглицкий коверкот»тан. Аннан мин Гарәф Фәхретдин, Рушад Хисаметдин, Исхак Зәбировларның архивларын, Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафиннарның Гарәф абзыйга язган хатларын күтәреп алып кайткан идем, шуннан Кашшафның егерме хатын шәрехләп, «Шәһри Казан» гәзитенә тапшырдым. Күз салгалап тор, яме? Моннан биш ел элек Гарәф абзый Рафаэль Хәкимовка үз архивыннан 64 иске китап тапшырган булган. Шуның очыкырые юк икән. Шуңа да запрос ясадым әле. Уйгырстандагы татарлар тарихы, уйгырлар тарихы буенча китаплар алып кайтып, Милли китапханәбезнең Сирәк китаплар фондына тапшырдым. Такташның, Сүнчәләйнең, Җәлилнең латинча чыккан китапларын әлегә үземдә калдырып тордым.

Синең минем Нажар абзый каберенә багышланган мәкаләмне укый алмавың кызганыч. Ул 29 сентябрьдә чыккан иде бугай.

Әле күптән түгел Сәгыйть Рәмиевнең 120 еллыгына багышлап Таткитнәшр (молодцы) бер кечкенә мәҗмуга чыгарган. Мин Сәгыйть Рәмиевнең иҗатын яңадан укып чыктым. Заманның фаҗигале шәхесе, башкалар котыра, дип, ул да Аллага каршы гыйсъянга ташланган, «җәдитчелек яктысында» милләтебезне бүгенге караңгылык һәм урыслашу баткагына алып кертешкән Сәгыйть абзыйны кызганып зар җыладым... Ул бит нибары, ялгышмасам, кырык алты яшендә үлгән шикелле. Менә мин аның, малай, «Кеше» дигән бер шигырен сиңа китерәм әле:

...Шулай, әрни, көя-көя,
Тора татар арасында.
Үзем дә шул татарның бер
Баласымын баласын да...
Торам, әрним, кинәт сөйнәм,
Тагы каным кибеп көйнәм,
Елаганда елый алмый,
Кара кан яшенә төйләм.
Эче гел кер малайларның,
Мирасы шул бабайларның,
Кара күңле, кара юлы
Белән үткән бабайларның.
Нәләт сезгә, малайларга!
Нәләт сез дик бабайларга,
Нәләт барлык миңа каршы
Туган йолдыз һәм айларга!
Нәләт, әй, син, кара көч, кем
Дип әйтим, белмим исмеңне,
Кисәкләп ташласын кошлар
Җәһәннәмнәргә җисмеңне!
Кирәкми һич миңа моннан
Болай Алла вә саф вөҗдан:
«Кеше» төсле булам мин дә –
Елан – эчтән, болай – тыштан...

Менә шундый-шундый хәлләр, дускай. Минем уемча, синең бу бөереңне гаилә хәлләре, атап әйткәндә, безнең ятимлек, өзлегү һәм башкалар ашамадымы икән? Күптән түгел Казанда көнендә генә Язучылар берлегенең идарә утырышында булып кайттым. Идарә, димәсәң, теле корыр инде... Сиңа Фәүзиядән (Бәйрәмовадан) күп сәлам. Күптән түгел без һәм Миргазиян Юныс Бөгелмәдә, Чаллыда, Түбәнәйтелгән Чулман шәһәрләрендә «Милләт, милләт!» дип тел чарладык.

Хәзергә хуш булып торсак, ярыйдыр, шулаймы? Бер килгәндә керәм. Әмма синең телефон булмау начар. Килерсең әллә кайларга эзләп, ә син юк тек юк.

Хуш. Үзеңне үзең сакламасаң, без генә саклый алмабыз.

Айдар ибне Нәҗметдин ибне Габделвәли.
Чаллы. 04.12.2000

Тиз генә үтмәс

(Мәрсия)

Милләтебезнең асыл улы – язучы, публицист, милли хәрәкәт каһарманы, милли социологиянең сирәк гамәлчесе Тәүфикъ Әйдинең гомере көтмәгәндә генә өзелеп куйды. Бер айдан аңа нибары алтмыш яшь кенә тулачак иде әле...

Авыр. Бик авыр. Без аның белән утыз еллап иңгә-иң торып перестройка таңын якынайткан һәм без аз гына булса да тын алдык дигәндә, перестройканы урыс чынбарлыгының тагын да чираттагы соры эңгере ашагач, тагын да реакция томаннарына кереп уралган идек. Менә хәбәр...

Тәүфикъ Әйдинең милләт язмышындагы урынын белү һәм бәяләү өчен, милләтнең үзен аның кебек белергә һәм аның кебек яратырга кирәк. Тәүфикъ Әйди йөрәгендә милләтенә сирәк ярату йөртте, ә мондый сирәк ярату җиңел генә бирелми, шуңа да каһарман җаннар фани дөньядан иртәрәк китә. Мин белгән милләтпәрвәрләр арасында Тәүфикъ Әйди, күптән түгел безне ташлап киткән Әбрар ага Кәримуллин белән беррәттән, икенче бер иң зур һәм сирәк талантка ия булган йолдыз иде.

Мин аны 1964 елдан ук белә идем. Без озак еллар милләтнең ике бөртек «яшь диссидентлары» булдык, гәрчә алар соңыннан күбәйсә дә. Без милләт дип әйтергә җөрьәт итеп булмаган елларда милләт дип әйтергә базнат иттек һәм аның өчен көрәшкә кереп, шуның өчен кыйналдык. Йөрәк яралары безнең өчен иң бәяле орденнар булды.

Тәүфикъ Әйди – Россия империясенең чираттагы корбаны.

Тәүфикъ Әйди – безнең милләтебезнең «күрмичә» генә йотып җибәргән чираттагы эчке сагышы. Милләт турында кайгыртканга, бар байлыгы – язган китаплары һәм алмашка кигән ак күлмәкләре генә булганга күрә, аны үзе исән чакта бәяли алмадылар, дөресрәге, тырышмадылар. Ул, дәүләтебезнең бер рәхмәт кәгазен дә ала алмыйча, безне ташлап китте. Хәер, аларга табынмады да, дауламады да. Әгәр ул аларны дауласа, татар язучысы, милләтнең шәхес фәненең йөзек кашыдай елъязмачысы, галиме, тарихчысы, телчесе, илчесе була алмаган булыр иде...

Тәүфикъ мәрхүм намусның да намусы иде. Шуңа күрә дә, үзе кыйналып булса да, мине нахак сүздән, барча нәҗестән араларга тырышып, утка керде. Миңа Уфага һәм Чаллыга язган дистәләгән хатлары – аның милләт достоинствосы өчен көрәшенең якты көзгеләре.

Ул миндә ниндидер тарихи өмет күрә һәм шуңа да саклый вә яклый иде. Исән чагында мин аңа бу хакта әйтеп тә өлгерә алмадым. Шуның өчен генә дә рәхмәт сиңа, Тәүфикъ дустым.

Миңа аның белән бергә Мәскәүдә Югары әдәби курсларда укырга туры килде. Бу чор минем күңелемдә иң бәхетле елар булып саклана. Әмма инде болар – истәлекләр өлкәсеннән. Хәзергә Тәүфикъны соңгы юлга адәмчә озатырга кирәк.

Хуш, кадерле дустыбыз, көрәштәшебез, каләмдәшебез! Синең идеалларыңа тугрылык – милләткә тугрылык, синең бөек, керсез исемеңә һәм җисемеңә җавап булып торырлык яшь көрәштәшләребезне үстерү дигән сүз. Татарны бары тик көрәш әдәбияты гына йок тәртәләре арасыннан чыгарачак.

Хуш, Тәүфикъ. Синең исемең безнең күңелләрдән беркайчан да җуелмас.

Айдар Хәлим,
төнге сәгать 12. 02.04.2001

РЕДАКЦИЯДӘН: Танылган әдип, публицист һәм җәмәгать эшлеклесе **Айдар Хәлимгә** киләсе елның 1 гыйнварында **75 яшь** тула. Айдар аганы гомер бәйрәме белән котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз. ■

Татар җыры – ул мәңгелек!

Гөлзадә Сафиуллина,
Татарстанның халык артисткасы, М.Җәлил бүләге лауреаты,
Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе

Мәшһүр шагыйребез Зөлфәт татар җыры турында заманында:

«Татар җыры,
Бер юлдашның әйткәне искә килә:
Сезнең җырларны
Тыңлавы авыр бит,
Җанга тия!» – дип язды.

Димәк, җыр ул Ватан, милләт, туган җир, туган тел, ата-ана, бала кебек мәңгелек кыйммәтләрнең асылында ята.

Халык: «Менә хәзер мин сезгә җыр язам әле», – дип утырып газапланмаган. Җыр ул үзе халык күңеленнән чишмә кебек ургылып чыккан. Ул – Алладан, ул – изге! Дөньяның мәшһүр композиторлары Бах, Бетховен, Моцарт һ.б.ның әсәрләре дә көй язам дип утырып язылмаган. Җанны әзәрлекләгән моңны алар кәгазь битләренә ноталар гармониясе итеп төшергәннәр. Шуңа күрә дә әлеге мәшһүрләр менә йөзәрләгән ел яшиләр. Халык аларның әсәрләрен бүген дә тыңлап хозурлана, көч таба, чистарына. Халык җырлары да менә шушы бөек әсәрләргә тиң. Шуңа күрә дә алар, гасырдан-гасырга күчеп, халыка хезмәт итәләр. Кемнәр аларны иҗат итте, кемнәр аларга күңел бизәкләрен өстәде, нотага салмаган килеш, ничек бүгенге көнгә кадәр килеп җиттеләр?! Ул хакта тәгаен генә әйтеп булмый. Әмма шунысы хак, һәр җырның үз тарихы бар, нигездә, аларда халык язмышы, хәтере ята. Халык бер җырны да югалтмады, безнең җанга диеп саклады.

Безне инде күпме еллар радио-телевидениеләрдән көйсез, мәгънәсез җырлар белән «сыйлыйлар». Менә бу татар җыры, заман җыры, хәзерге заман форматы, дип, халык җырларын читкә этәреп, яңа җырлар тәкъдим итәләр. Татар халкының җырлары шундый булгач, халкы да шундый инде, дип безне ышандырырга тырышалар. Безне, түбән вибрация дулкынында тибрәтеп, зомбиләштерү бара. Әнә шул җырчылар үзләренең йолдыз булуына ышанып, табигать биргән матур тавышларын өч көнлек җырлар җырлап, эголарын үстерделәр, бәхетсезлеккә тардылар. Ә үсеп килүче буын шушы шаукымга кушылып, деградация кичерә. Инде уйлый белгәннәре, татар җыр сәнгатенең нинди түбән булуын, үзләрен башка халыклардан ким күреп, үз милләтеннән

Профессиональ сәхнәдәге иҗат эшчәнлегенә – 20 ел. Сулдан уңга: Гөлзадә Сафиуллина, Резедә Сафиуллина, Фәүзия Бәйрәмова

йөз чөереп, башка «бөек» милләтләр сафына кушылу чарасына керешәләр. Катнаш никахлар да шуңа килеп терәлә. Ә концертларда килешмәгән сүзләр сөйләп, телебезне бозып күрсәтергә дә чирканмыйлар. Татар халкының меңьеллык язма мирасына төкереп, пычратып, бөек Тукаебыз, Мөхәммәт Мәһдиевләр, Әмирхан Еникиләр, Туфан, Такташ һ.б. әдип, галимнәребезнең рухын рәнҗетәләр.

Шушы урында аз гына читкә китеп, Яңа ел тамашасын алып баручылар турында берничә сүз әйтәсем килә. Каян тапканнар ул шамакайларны? Әнә шуларның берсе менә мондый җыр җырлап бирде:

«Алмагачның алмасын,
Тырыша-тырыша утадым...»

Әлбәттә, ахыргы юлларын җырламады. Әмма безнең буын аның икенче яртысын бик яхшы хәтерли. Халыкны болай мәсхәрәләү инде 20 елга якын дәвам итә. Әле без бит исән, хәтеребез исән. Халык көйләре – безнең җанда, хәтердә. Ата-бабаларыбызның рухи байлыгын аяк астына салып таптыйбыз түгелме?! Редакторлар, режиссерлар ни карый? Бөек шагыйрьләребез, композиторларыбыз иҗат иткән тормыш-көнкүреш, көрәш җырлары, Ватан турында, туган ил турында, Казан турында һ.б. хакындагы җырлар кайда? Радио фондында алар меңәрләп иде. Кемнәр шул асыл мирасыбызны юк итте?! Булсалар, нигә аларны радио аша тапшырмыйбыз? Нигә соң әле гасырлар буе тәрбия чарасы булган җыр бүген нәҗескә әйләнде. Нигә үсеп килүче буын җыр тәрбиясеннән мәхрүм? Юк, мактый алмыйм мин бүгенге эстрада халәтен. Ул халык акчасына, халыкның үзенә каршы эшли. Бу минем генә фикерем түгел, бу – халык фикере дә. Сез – халык җырчылары ник дәшмисез? Нишләттеләр безнең бөек сәнгатебезне? А.Ключарев, Җ.Фәйзи, М.Мозаффаров, Ә.Бакиров, Ф.Әхмәтов, С.Садыйковалар язган җырлар кайда? Боларның барысы да Татарстан радиосы фондында бар иде ләбаса. Нигә аларны тапшырмыйлар?

Мөнәҗәтләр кичәсендә

Җыр сәнгатебезнең түбән дәрәҗәдә булуының сәбәпләреннән берсе – җыр дәресләренең башка фәннәр белән алмашынуы. Ә югары уку йортларында профессор дәрәҗәләренә ирешеп, татар җырына бәя бирүчеләр авызыннан: «Халык җырларын җырламагыз, алар хәзер модада түгел, алар белән акча эшләп булмый», – дигән сүзләр ишеткәч, әллә без акылдан яздыкмы, дигән уйлар башка килә. Шундый корткычларның мирасыбыз тамырына балта чабуларын күреп, без дәшми кала алабызмы? Сәнгать башында шундый педагоглар торгач, нинди җыр җырлыйсың инде. Әлбәттә, бөтен педагогларны да бер калыпка салырга ярамый. Бүген Казан музыка көллиятендә менә дигән педагоглар балаларга халык җырларының серләрен өйрәтәләр. Зур репертуар төяп чыга алар көллияттән. Ә менә укуларын тәмамлап, тагын шул профессорлар «арбасына утырып», халык җырларын җырламаска үзләрендә көч табарлармы? Заманыбызның мәңгелеккә калырдай матур, моңлы җырчылары да бар. Милли мәдәни үзәк җитәкчеләре алар өстендә бик нык эшли, күрәсең. Халык җырлары безнең геннарга, ДНКларга кереп урнашкан. Авыл урамнары буйлап армиягә китүчеләрнең өйдән-өйгә кереп саубуллашып, тальян гармунга кушылып җырлап йөрүләре әле дә күз алдында. Күңел тула, җырның бүгенге халәте өчен җан әрни.

Шөкер, безнең буынга татар җыр сәнгатенең чәчәк аткан чорында яшәргә насыйп булды. Безгә кадәрге буын һәм без – урта буын халкыбызның алтын фондын җыеп, җыр тәлинкәләренә,

радиога яздырып, ул җырларның берсен дә югалтмыйча үзебез яшәгән заманга китереп җиткездек. Әйе, һәр заманның үз җыры, ләкин бу әйтем халык җырларына һич тә кагылмый. Алар һәр буын тарафыннан җырланып, тагын да матураеп киләчәк буынга тапшырылырга тиеш. Халык җырларын башкару осталыгы – ул Аллаһы Тәгаләнең бүләге. Алар җаныңны гына түгел, тәнеңне дә чистарта. Мин шуны Мәскәүдә музыка белән дәвалау курсларын үткәндә аңладым. Иң моңлы көй – азан, иң тәэсирле олы дәвалау көченә ия сүз – Коръән сүзе. Аннан кала – халык җырлары, мөнәҗәт, бәетләр. Фольклорның потенциаль мөмкинлекләре искиткеч зур, чөнки анда – халыкның яшәү рәвеше. Халкыбыз арасында зәвыклы кешеләр дә күп. Алар мирасыбыз сагында торалар. Бөек көч – Аллаһы Тәгалә бар. Шуның өчен илаһи моңны сатып та, бетереп тә, үзгәртеп тә булмый. Ул – мәңгелек. Безнең татар халкындагы бәетләр, мөнәҗәтләр турында аерым әйтәсем килә. Алар дога сыман. Кеше тормышындагы фаҗигале хәлләр турында Аллаһы Тәгалә белән киңәшүдән, аның белән кайгы-хәсрәтләрне уртаклашудан гыйбарәт ул. Мөнәҗәтләр кешенең шәхси, иң тирәнгә яшеренгән психологик кичерешләре турында сөйләсә, бәетләр ил һәм халык язмышының да фаҗигале якларына кагыла. Башка халыкларда безнең бәетләргә тәңгәл бер генә жанр да юк. 1990-1992 елларга кадәр мөнәҗәт, бәет турында авыз ачарга да ярамый иде. Әле дә хәтеремдә. 1992 елда радиода качып, ишекне бикләп, җыр яздырабыз, дип алдап, мөнәҗәтләр, бәетләр яздырып, татар тарихында беренче тапкыр мөнәҗәтләр, бәетләрдән генә торган пластинка чыгарган идем. Ул вакытта пластинка чыгару өчен Мәдәният министрлыгыннан рөхсәт кәгазе кирәк иде. Кая ул рөхсәт бирү, ул хакта хәтта сорарга да ярамый иде. Бәхетемә, Мәскәүдә коммерция юлы белән пластинка чыгару мөмкинлеге ачылды. Шунда барып, үз акчама меңәрләгән тираж белән берничә тапкыр пластинка чыгардым һәм дөнья татарларына бушлай өләшеп тә бетердем. Менә шулвакыттан башлап, 23 ел элек, мөнәҗәтләр югары сәхнәләргә менделәр, халык арасында өлкәннәр һәм балалар тарафыннан әйтеләләр, җырланалар. Минем пластинкаларны кулланып, консерваториядә фольклор дәресләре үткәрәләр. Соңгы елларда «Илаһи моң» дип аталган мөнәҗәтләр фестивале үткәрү дә халыкның үзаңын үстерүдә зур роль уйнады. Юкка гына галимнәребез ач-ялангач чакларда авылдан-авылга йөреп, халык авыз иҗатын җыеп йөрмәде. Бүген алар тарафыннан татар халык авыз иҗатының 12 томлыгы дөнья күрде. Ә Нәкый ага Исәнбәтнең халыктан җыйган 3 томлык мәкаль һәм әйтемнәрендә – халкыбызның аңы, акылы, тапкырлыгы, шаян-шуклыгы. Мондый мирас бер генә халыкта да юк.

Кеше күңеле җыр аша чагыла. Җансызлар гына халык җырларын тыңламый да, җырлый да алмый. Җыр ул һәр заманда тәрбия чарасы, агартучы булды. Һәм моннан соң да ул шулай булып калсын иде.

Сүземне шагыйрь Харрас Әюповның шигырь юллары белән тәмамлыйсым килә:

Җырлар кала
Чиксез мәңгелеккә
Сәфәр чыккан Бөек Агыштан –
«Әллүки»е, «Тәфтиләү»е кала,
Карурманы кала, Сакмары.
Бер моңны да югалтмады чорлар,
Безнең җанга диеп саклады.
Үткәннәрдән киләчәккә кадәр
Җаны булып җирнең җыр бара.
Син югалта күрмә ул тавышны,
Йөрәгеңдә сакла, ир бала!

Фотолар Гөлзадә Сафиуллинаның шәхси архивыннан алынды. ■

Урау юллар гизеп табылган бәхет

Марс Макаров
(1939-2016)

Хәтерегездәдер, мәшһүр җырчыларыбыз элегрәк елларда халкыбызның борынгы озын көйләрен тамашачыга, Тукай таләп иткәнчә, үзенчәлекле моң белән җиткерә килделәр. Хәер, моң-сагыш үзе дә милли җырларның эталоны иде бугай. Сәхнәне аркылыга-буйга йөреп, тавышларына төрле хәрәкәтләр белән куәт биреп башкару аңарчы театр спектакльләрендә генә очрый иде шикелле.

Әменә 60 нчы еллар азагында жыр кинәт кенә хәрәкәткә килде. Сәхнә түрендә һәрвакыт шат елмаючан, җиңел сөякле, кыска гына буйлы бер чибәр егет калыкты. Аны дәррәү алкышладылар, чәчәкләр бүләк иттеләр, болай да җырлап була икән, дип, хуплау сүзләре әйттеләр. «Татарстанның халык артисты» дигән мәртәбәле исемгә лаек булган Зиннур Нурмөхәммәтовның (1941-2003) эстрада эшчәнлеге әнә шулай башланды.

Чүлмәкчедән күрмәкче, дигәндәй, иншаллаһ, Зиннурга иярүчеләр дә табылды. Аларның иң мәгълүме, мөгаен, Эльвира Розалидыр.

Бер карадым күзләреңә,
Икенче – йөзләреңә.
Бер карауда мәхәббәтле
Күренденң күзләремә.

Халкыбызның шундый ягымлы жыры, ике буын башкаручыларын берләштергән кебек, бу артистларның үз шәхесләренә дә карый бугай. Зиннур да, Розали да беренче чыгышларыннан ук тамашачыга чыннан да мәхәббәтле булып күренделәр бит. Хәзер инде үзләрен шулай яраттыра алган эстрада җырчыларыбыз җитәрлек.

Зиннур белән миңа гастроль сәяхәтләрендә байтак йөрергә туры килде. Бик хәрәкәтчән булса да, әңгәмәдәшен ул сабыр гына тыңлый белә, күзләреңә мөлдерәп карый, сүзе һәрвакыт мәгънәле, түрәләр алдында җебеп төшми – анысы инде нәселеннән үк килә торгандыр.

З.Нурмөхәммәтовның шәхси тормышы катлаулы гына түгел, фаҗигале дә була. Ул – Әстерхан шәһәрендә туган 41 нче ел малае. Сугышка кадәрге репрессия алар гаиләсенә дә кагыла. Әнисе Мәрьям апа, сабыен күрергә тилмереп, 1949 елга кадәр Сталин төрмәләрендә интегә.

Аннан үги әтисе Нәбиулла абзый белән бергә Сахалинның Горнозаводск шәһәренә күченеп китәләр. Әлбәттә инде, Зиннурга урыс мәктәбендә укырга туры килә. Ләкин татар моңы барыбер үз дигәнен итә. Туган җирләреннән, кыерсытылып, бирегә – шахталарга килеп урнашкан татар гаиләләре ниндидер юллар белән татар пластинкалары алдыралар, күңелләрен милли җыр белән юаталар. Нечкә күңелле малай патефоннан мәшһүр артист Рәшит Ваһапов башкаруында «Кара урман», «Әлфия» җырларын тыңлый. Моңнар йөрәккә языла бара. Әнисе сөйләве буенча, Зиннур кечкенәдән бик моңлы итеп җырларга яраткан. Шахтада эшләүче немец әсирләре дә аны таң калып тыңлый торган булганнар – курчаклар ясап, бәләкәй Зиннурга бүләк тә иткәннәр.

Соңрак язмыш аларны Приморье тарафларына илтеп ташлый. Тормыш шактый кысынкы еллар. Гаиләдә тагын ике үги сеңел. Үсмер Зиннур гаиләгә булышырга мәҗбүр. Ул Лесозаводск шәһәренең агач эшкәртү комбинатында кара эшләрдә эшләп йөри. Буш вакытларын үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә уздыра. Бу аның сәхнәгә ныклап аяк басарга җыенган еллары.

1961 елда Зиннур Нурмөхәммәтов Владивосток музыка училищесының вокал классына имтихан тота. Ләкин ике елдан аны армия сафларына алалар. Монда да ул җыр-моңнан аерылмый. Тын океан Хәрби диңгез флоты ансамблендә солист була. Музыкаль коллектив Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә еш кына концертлар бирә. 1964 елда мәшһүр композитор Долуханянның Владивосток шәһәренә килүе яшь җырчының алдагы язмышын ачыклауда хәлиткеч роль уйный.

Танылган композитор Зиннурның саф һәм көр тавышына игътибар итә, аны үз төркемендә чыгышлар ясарга чакыра. Яшь җырчы, Долуханянның «Ой, ты рожь» җырын башкарып, рус тамашачыларын да таң калдыра. Кызганыч ки, бу иҗади дуслык, композитор автомобиль һәлакәтендә үлгәч, тукталып кала.

Зиннурның күңеле күптәннән инде Казанга тартыла. Әнисе дә сирәк кенә очрашкан чакларда гел шул турыда сүз кузгата. Ниһаять, җырчы зур өметләр белән Казанга юл ала. Әмма аны биредә беркем дә белми, беркем дә көтеп тормый. Күңеле шактый төшкән Зиннур үзе туган якларга – Әстерханга китеп бара. Аңа өлкәнең кинофикация оркестры белән берлектә концертлар биреп йөрергә туры килә. Әлбәттә, эшләнгән эш эзсез югалмый – аның осталыгы арта, репертуары байый бара.

Ә Казан барыбер күңелне алгысытып тора. Әлгәсе иде бит шунда, каһәр! Күп икеләнүләрдән соң, яшь җырчы тагын бәхетен сынап карарга була. Бу юлы инде ул иҗат әһелләренә карата үтә игътибарлы кешеләргә юлыга. Филармониянең ул вакыттагы сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов аңа Мәскәүдәге Бөтенсоюз эстрада сәнгате мәктәбенә барырга тәкъдим итә. Бер төркем талантлы яшьләр, ике елдан соң шул мәктәпне тәмамлап, республикабызның данлыклы иҗат көчләренә килеп кушылалар. Ул елларда бер көпчәкле велосипедта Равил Таишевның сәхнә буйлап тызбыз йөрүләрен, яшь һәм чибәр Римма Ибраһимованың күңелләрне сафландырып җырлавын күпләр хәтерлидер әле. Аларның сабакташы Клара Хәйретдинова инде бүген опера йолдызы булып кабынды. Ә Эльба Закирова, Виктор Шәрәфетдинов, Зәйтүнә Яруллина, Надия Гыймадиева, Зиннурның тормыш юлдашы Татьяна Романова - төрлесе төрле жанрда эшләсәләр дә, аларны берләштереп торган бер көч бар. Ул – талант галәмәте. Бу төркемне ул елларда «Нурмөхәммәтов бригадасы» дип йөртәләр иде. Зиннур әлеге коллективның җаны да, юнәлеш бирүчесе дә булды.

Җырчы, укып кайткач, беренче чыгышларыннан ук халык иҗаты үрнәкләрен яңарта башлады, аларга бөтән аһәң, башка яңгыраш өстәде. Ул башкарган «Бер карадым күзләреңә», «Ай, былбылым», «Бөрлегән», «Җаныем, бәгырем» кебек җырларга игътибар итегез әле. Алар аның үзенчә – нәкъ менә Зиннурча яңгырадылар. Шуңа күрә аңа беркем дә: «Гел иске җырларны җырлыйсың», – дип дәгъва белдермәде. Үз репертуарына ул үзешчән авторлар иҗат иткән җырларның да иң асылларын гына сайлап алды. Башка милләт җырларын да үги итмәде. Аның 1970 елда Бөтенсоюз эстрада артистлары конкурсында дипломант исеме алуы башлыча шуңа да бәйләнгән иде. Ә 1976 елда ул М.Җәлил исемендәге мәртәбәле бүләккә лаек булды.

Тормыш борылышларында үзе булып калган, сөйгән халкының җырмоңнарына яңа төсмерләр өстәгән Зиннур Нурмөхәммәтов егетләрчә дәрт белән иҗат итте, сәхнә түрләрендә нур булып балкыды, кешеләргә шатлык һәм бәхет өләште.

Ни кызганыч, якты дөнья белән ул вакытсыз хушлашты. Аның образы күңелләрдә якты нур булып яшәр.

РЕДАКЦИЯДӘН: Аяныч ки, даими авторыбыз, күренекле музыкант, композитор ***Марс МАКАРОВ*** *үзе дә якты дөньядан китеп барды. Һәр икесенең дә рухларына хәер-догаларыбыз ирешеп торсын.* ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

РЫХ – электә кара белән язылган язуны киптерү өчен кәгазь өстенә сибелә торган бик вак ком төре. Аны суда кайнату юлы белән әзерләгәннәр. Киптергеч комны капкачында борыч савыты кебек вак-вак тишекләре булган махсус савытта тотканнар. Кәгазь өстендәге комны селкеп төшерергә туры килгән.

Борында Кашгар белән Яркенд арасында урнашкан җирдәге үтә вак комны Баграм комы дип атаганнар. Шифалы сыйфатларга ия булган (имештер) бу комны язу киптергеч сыйфатында куллану турында мәгълүмат тапмадым.

Рых сүзе төрекчәдән булса кирәк.

РЯСЯНЕН АРВА МАРТТИ ОКТАВИАНУС (1893-1976) – фин лингвисты, төркиятче. 1915 елда Гельсингфорс университетын тәмамлаган. Казанда (1913-17), Лейпцигта (1922), Будапештта (1924-25), Берлинда (1926) һәм Парижда (1930-31) тюркология *(төркият фәне)* буенча стажировка үткән. Идел буенда һәм Төркиядә төрки телләрне өйрәнү буенча фәнни экспедицияләрдә катнаша. Төрки телләрнең беренче этимологик сүзлеген төзүче (нимес телендә, 1969).

Фасмерның этимологик сүзлеген рус теленә күчереп, Мәскәүдә ике тапкыр бастырып чыгарган шикелле, Рясяненның әлеге сүзлеген дә рус һәм татар телләрендә Казанда нәшер итү төркият фәнен үстерү өчен гаять әһәмиятле адым булыр иде.

СИМСИМ МАЕ – киндер мае. Ибне Фазлан: *«Болгарларда балык маеннан башка май юк. Алар аны зәйтүн мае вә симсим мае урынына тоталар, алар шул сәбәпле исле булалар»*, – дип әйтәдер. Г.Әхмәров.

«Мең дә бер кичә»дәге «Гали баба һәм кырык карак» әкиятендә юлбасарларның хәзинәләре саклана торган мәгарә «Симсим, ач ишекне!» дигәч, ачылып китә торган була. Ихтимал, бу әкиятне киндер чәчәгеннән алынган наркотик тәэсирендә «зиһене ачылып», матур галлюцинацияләр күргән кеше беренче булып сөйләгән булгандыр. Монда симсимнең, мәгълүм дәрәҗәдә, *Җәмшид җамаягына* охшашлыгын төсмерләп була. Әкиятнең русчага тәрҗемәсендә «Сезам, откройся!»/«Сезам, отворись!» сүзләренә тап булабыз. Грек теленнән алынган *сезам* исә *кунжут* («Биологиядән русча-татарча аңлатмалы сүзлек»тә татарчасы «көнҗет» дип тәкъдим ителә, бусы фарсыдан килә торган сүз) үсемлеге. *Культу-*

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче санынннан басылып килә.

ралы көнҗет шулай ук майлы үсемлек буларак игелә. Ләкин аңардан наркотик матдә алу турында мәгълүматым юк.

Әкияттәге «парольне», ягъни ачкыч сүзне аңлату өчен башка фараз да бар. 967-1049 елларда яшәгән күренекле суфи ***Әбү Сәед Әбелхәйрә Мәйхани***, без Аллага: «Син! Син!» – дигәндә генә догабыз нәтиҗәле була, дип санаган һәм әлеге әкияттәге тылсымлы гыйбарәнең Аллага мөрәҗәгать сүзләре булуы да ихтимал.

СИМФЕРОПОЛЬ – Кырым Республикасының башкаласы. Яңа эрага кадәр III гасырдан алып яңа эраның III гасырына кадәр Симферополь урынында скиф дәүләтенең башкаласы *(Скиф Неаполе)* торган. Аннары ул *Кирмәнчек* дигән татар кальгасы, XV гасырда *Ак Мәчет* исемле татар шәһәрчеге була. Аның урынында 1784 елда Симферополь шәһәренә нигез салганнар. Хәзерге вакытта халкы 348 меңнәр.

XX гасыр башларында Симферопольдә шактый күп мөселман яшәгән. Аларның унике мәчете, мәктәп-мәдрәсәләре булып, Руханият идарәсе (Духовное управление) дә шушында урнашкан була.

СИМЕОН БЕКБУЛАТОВИЧ (?-1616) – Касыйм ханы (1568-73). Чукындырылганга кадәр *Саин-Булат (Сәин-Булат)*. Ханзадә Бик-Булатның углы, Алтын Урда ханнары нәселеннән (Әхмәт ханның оныгы). Әтисе белән бергә Явыз Иванга хезмәткә күчкән. XVI гасырның 70 нче елларында Ливон яуларында катнашкан. 1573 елда чукынган. Кенәз Мстиславскийның кызына өйләнгән булган. 1575 елның көзендә Мәскәү Кремлендәге Успенье чиркәвендә таҗ кидерелеп, бөтен ***Русьның Олуг кенәзе*** дип игълан ителә. Ә Явыз Иван, патша титулыннан тыш, ***Мәскәү, Псков, Ростов кенәзе Иван Васильевич*** дип атала башлый. Ил олуг кенәз Симеон Бекбулатович биләмәләренә һәм Иван «удел»ына бүленгән, ләкин чынлыкта дәүләт белән идарә итү Иван Васильевич кулында калган. Хакимлекне Явыз Иван үзендә саклаган хәлдә оештырылган бу «сәяси маскарад»ны замандашлары да, тарихчылар да аңлатып бирә алмый. 11 айдан соң Симеон Бекбулатовичка Тверьдә һәм Торжокта җир бүлеп бирелә, ә Иван яңадан патша булып кала. Борис Годунов патшалык иткән чорда Симеон Бекбулатович үзенең җир биләмәләрен югалта. Бу вакытка аның сукырайганы мәгълүм. 1606 елда, Ялган Дмитрий заманында, монахлыкка китәргә мәҗбүр ителә, анда Стефан исемен кабул итә.

1616 елда (инде Романов патша итеп сайлангач) Мәскәүдә үлгән, Симон монастырենда җирләнгән. Аның хатыны патшабикә Настасия (монахинялыкта Александра) 1607 елда вафат булган.

СИНДБАД – «Мең дә бер кичә» әкиятләренең һәм башка күпсанлы шәркый хикәятләрнең каһарманы.

Фарсы Синдбад исеме *һинди* хәким *Сидд-хапати* исеменнән килә. Бу зат патша улының тәрбиячесе булган һәм аңарда тарихка, җәгъръфиягә, төрле сәяхәтләргә мәхәббәт тәрбияләү өчен мавыктыргыч хикәятләр язган. Бу хикәятләр төрле телләргә тәрҗемә ителеп, төрле вариантларда Шәрык дөньясында киң таралган. XII гасырда ***«Синдбаднамә»*** исемле шундый бер хикәятне Сәмәркандта яшәүче ***Заһири*** дә яза һәм соңыннан ул әсәр «Мең дә бер кичә»гә барып кергән. «Синдбаднамә»дә Синдбад маҗаралар эзләүче тынгысыз диңгезче итеп сурәтләнә.

Синдбад турындагы әкият татар теленә дә тәрҗемә ителгән, аның киноверсияләре дә бар. ■

Фатих Кутлу Мәгъния әби белән. 2016 ел

Еллар кайтавазы яки бер сәфәр[1]

Фатих Кутлу

Яңадан Мәгъния әбинең әнисе турында сөйләшеп киттек. Мин шунда, алдан ниятләгәнчә, Рәшит Әхмәтҗанның «Карачкы» поэмасыннан[2] «Әменнең туган илен сагынуы» бүлеген укырга теләдем. Бәхетемә, ул бу әсәр белән таныш булмаган әле. Димәк, әнисе турындагы юлларны иң беренче миннән, төрек кешесеннән ишетәчәк. Билгеле, әңгәмәдәшем күз яшьләрен тыя алмады...

Тууына 75 ел тулу уңаеннан шагыйрьне дә яд итү булыр, дип, әсәрдән өзекне журнал укучыларына да тәкъдим итик...

Яр буенда,
Тал куенында,
Кер бәләкли хатыннар.
Шул хатыннар арасында
Төрек кызы Әмен бар.

– Уйнап түгел, уйлар уйлап
Ага, – ди ул, – суыгыз...
Сәфәр чыккан аякларым
Сынсын, әйдә, сугыгыз!

Көтмәгән идем җәзаның
Мондыен мәхәббәттән, –
Сизми дә калдым, ул мине
Тәмугка тәгәрәткән.
Мине илдән урлап киткән
Мәхәббәткә сугыгыз!
Шомлы ага суыгыз... <...>

Башны су төбенә тарта
Әллә нинди авырлык.
Төшсә әгәр, кешесе юк
Аны тартып алырлык.
Су төбенә төшим дигән
Уйларыма сугыгыз!
Ай-һай, тирән суыгыз...

[1] Ахыры. Башы журналыбызның 11 санында.
[2] Рәшит Әхмәтҗанов. Әсәрләр. Икенче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014.Б. 161-189.

Дөньямның җылысы калган
Әнкәм учакларында,
Тәмугка китеп барганмын
Егет кочакларында.
Түенчегемне күтәргән
Кулларыма сугыгыз!
Тынычланыр суыгыз...

– Саҗидә әни безне бер дә кимсетмәде, ятимлекне сиздермәде, – дип сөйләде Мәгъния әби. – Үз балаларыннан аермады. Тигез күреп үстерде. Шулай да, кайчак күңелдә: «Әнкәм булса, шулай булыр иде, тегеләй булмас иде», – дигән уйлар да бөреләнмәде түгел... Уйлап та куйгалыйм: әни мәрхүмәнең дә ата-аналары булган бит, нигә алар кызларын күрергә монда килмәде икән?

...Бу сорауга җавабым бар иде, билгеле. Хәер, Мәгъния апаның да җавабы булгандыр: СССР дигән корыч җанлы мәмләкәттә гомер кичергән кеше бит ул.

Үзем дә сизмәстән, халык көенә язылган моңлы төрек җырын сузып җибәрдем[3]:

Очып киттең бу яклардан,
Бәгырь җимешем, кайда син?
Очып киттең бу яклардан,
Күземнең нуры, кайда син?
Барган юлың бик еракмы?
Кайтмый торган җирдәме син?

Кайт! Яңгыр булып кайт!
Кайт! Җил булып кайт!
Болытлар юлдашың булсын,
Ходаем сине сакласын,
Юлың имин, якты булсын,
Торналарга тотын да кайт!

Мәгъния әби җырны бирелеп тыңлады да: «Алар да тегендә шулай җырлаганнардыр инде», – дип көрсенеп куйды.

Без ул көнне Татар Кандызында куна калдык. Мәгъния әби монда берүзе түгел. Улы Нурулла, килене, оныклары белән бергә гомер кичерә.

Икенче көнне иртән Әминә ана килен булып төшкән, яшәгән һәм, ниһаять, җан тәслим кылган төп йортка юл тоттык. (Ул Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗаннар туып үскән нигез дә бит әле.) Анда бүген мәрхүм Ильяс абыйның (Рәшит абыйның энесе) хатыны Асия апа тора икән. Йорт урнашкан урам Рәшит Әхмәтҗан исемен йөртә. Өйгә беркетелгән калайда гүзәл сүзләр тезмәсе: «Бу йортта Г.Исхакый премиясе лауреаты, шагыйрь-милләтпәрвәр Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗан туган (1941-1994)».

Капкадан уздык. Шактый үзгәрешләр кичерсә дә, йорт-курада яңалык орынмаган урыннар да шактый икән әле. Асия апа (аны «җиңгәчәй» дип йөртәләр) безне йорт-җир белән таныштырып йөрде. Мәсәлән, ишегалдындагы таш келәт узган гасыр башында ук салынган икән. Мәрхүм Әминә ана монда кереп-чыгып йөргән. Тоткада аның кул җылысы калгандыр, дип кагылып карадым.

Асия апа: «Мин бу йортка төшкәндә Әминә апа бирнәсеннән калган ике калын көмеш чәнечке исән иде әле, – дип сөйләде. – Берсенә йөгертелгән язуны Саҗидә әни укый алган иде. Анда «Трапизон» дип язылган иде», – ди. Моны ишеткәч шаккаттым. Чөнки Кара диңгез буенда Төркиянең Трабзон дигән шәһәре бар. Сүз, һичшиксез, шушы шәһәр турында булырга тиеш, дип уйлап куйдым. Алгарак китеп, шуны әйтим: Казанга кайтып, интернетны ачсам, ни күрим – электрон энциклопедиядә шәһәр атамасы «Трапезунд» дип тә бирелә. Мондый мәгълүмат та бар: «Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында, 1916 елның 14 апрелендә, урыслар Трабзонга басып керә. Шунда бер ел ун ай ун көн торалар. Россиядәге Октябрь түнтәрелешеннән соң гына урыс армиясе чигенергә мәҗбүр була». Өстәвенә,

[3] Өзһан Әрәннең «Торналарга тотын да кайт» шигыре. Ф.Кутлу тәрҗемәсе.

Рәшит Әхмәтҗанның ике томлык сайланма әсәрләре тышлыгы

Трабзон көмеш чәнечке-кашыклары белән дан тоткан.

Асия ападан шундый яңалык ишетүгә ирештек (аңа, үз чиратында, Саҗидә әнисе сөйләгән): Әминәләр гаиләдә биш бала булган, дүртесе – малай, кыз затыннан берүзе. Аны авылларында «Әмеш» дип йөрткәннәр. (Чыннан да, бездә Әминәне үзара шулай атыйлар.) Ике туганының исеме дә ачыкланды: Ярулла абый искәргәнчә, алар Хәсән һәм Хөсәен булганнар. Мин Әминәнең әнисе Әмрия атлы булмадымы икән, дим. Чөнки бездә оныкларга әби-бабай исемен кушу йоласы бар.

Йә хуш, монда эшебезне төгәлләдек. Ниятләгән өч урынга барасы калды тагын: Әминә ана сулар ташыган чишмә, поэмада телгә алынган «кер бәләкләгән су буе» һәм зират. Болар турында иң тулы мәгълүматка ия кеше Илдус Әхмәтҗанның бертуганы Кәмияр абый икән.

***

Чишмә урыны корыган....

Авыл хатыннары кер бәләкләгән яр буен агач-куак баскан...

Яр буенда, тал куенында
Кер бәләкли хатыннар,
Шул хатыннар арасында
Төрек кызы Әмен бар,

– дигән юлларны нәкъ үз урынында укыдым. Кәмияр абыйның күз алмалары дымланды. «Тынычланыр суыгыз...» дигән юллардан соң: «Әминә ана, су тып-тын ага! Тынычланган, күрәсең», – дидем дә... үземнең бәбәкләремне дә җил канаты сыйпап үткәнен сиздем.

Азактан бергәләп Сөләйман зиратына бардык. Әминә ана чорына караган бик күп кешенең кабере билгесез икән. Ярулла белән Кәмияр абыйлар Әминә ананың кабере булырга мөмкин, дип фаразланган калкулыкка күрсәттеләр. Коръән укып мәрхүмәнең рухына багышладым. Ул көнне көндәлегемә мондый сүзләр теркәлгән: «И Әминә ана! Җанашым! Мин син җирләнгән зиратта хәзер. Бер кабер ташың да юк хәтта. Туксан ел чамасы арадан соң, туган илеңнән бер милләттәшең буларак килдем каберең̧ә, догалар кылып багышладым рухыңа. Син мине ишетәсеңдер, дип уйлыйм. Ходай Тәгаләм туганнарыңны табарга насыйп итсен безгә! 22.06.2016. Кандыз авылының Сөләйман зираты».

Бу урынга кабер тактасы урнаштырырга иде... Ярулла абый белән шул хакта фикерләштек. Әминә ананың әтисенең исеме нәмәгълүм булса да, тактага: «Бу урында Хәниф Әхмәтҗановның хатыны, Бәхтияр, Әмрия һәм Мәгъниянең әнисе, Төркиядән килен булып килгән төрек кызы Әминә ана җирләнгән. Туган елы – 1902[4], вафат елы – 1928», – дип язылса яхшы булыр иде, дип уйладык.

[4] Бу мәгълүмат күптән түгел Ярулла әфәнде тарафыннан Баулы ЗАГСында табылды. 1923 елда дөньяга килгән Бәхтиярның (Әминә ананың беренче баласы) туу таныклыгында «Әтисенә – 32, әнисенә – 21 яшь» дип язылган икән.

Әминә ананың кабере дип фаразланган урын. 2016 ел

Әлбәттә, Әмрия мәрхүмәгә дә шундый ук такта ясату – безнең бурычыбыз.

Күз алдыма китерәм: Хәниф әфәнде ничә мәртәбә хатыны Әминә каберенә килеп йөргәндер, аның белән серләшкәндер. «Әминәм, ватаныңа кайтара алмадым, сөекле ата-анаң, кадерле туганнарың белән очраштыра алмадым. Саргайттым сине, былбылым! Кичер мине, Ходай хакы өчен, кичер! Рәнҗеп ятма миңа...» – дигәндер.

КАРАЧКЫНЫҢ БАЛА
ЕЛАВЫН ТЫҢЛАВЫ[5]

Алданрак кайтып үлде Әмен,
Җыеп алды аны каберлек...
Көн дә килә.
Монда яшәсә соң! –
Карачкыга барыбер кадер юк.

Уйларында һәр көн Әмен үлә,
Көн дә җирли, гүргә иңдерә.
Өйгә кайтмый.
Кайтса, әллә кайда
Бала елый, бала илерә. <...>

Кайтып күрен, балам...
Һәм Әменнең
Гүрен капшый:
– Киткән иленә.
Илләренә ничек күчкәнлеген
Кояш белән бары ай белә.

Керфекләрен җилләр саный-саный
Алганнардыр – юллар бер якка.
Алсулыгын кояш тапшыргандыр
Чәчәк итеп бирәр куакка.

Күз яшьләрең узган болытларның
Монда калдыруы мөмкинме?!
Сердәш ае, туктап,
Бер сирперлек
Күз нурларын алган һәр көнне...

Күчеп беткән шулай.
Үлемнәрнең
Мондыйлары була бик сирәк.
Сагышлардан саргаюны беләм,
Саргаеп та үлү бар, димәк.

Без сәфәрне шул урында төгәлләдек. Мәгъния әби белән саубуллаштык. Киттек...

Инде, Ходаем, мәрхүмә Әминә ананың туганнарын табарга насыйп ит!

Амин. ■

[5]Рәшит Әхмәтҗанов. Әсәрләр. Икенче том. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2014. Б.177-180.

Сөембикә ханбикә

Татарстан Республикасы Милли музее фондыннан

«Сөембикә ханбикә һәм аның гаиләсе» рәсеме. Хромолитография. 1915 ел

И.Ш.Фәйзуллин. «Сөембикә Явыз Иван янында. 1551 ел»

А.Дюран, А.Раффе, А.Бри. «Сарай хәрабәләре һәм Сөембикә манарасы» Литография

В.Г.Худяков. «Казаннан китүче әсир – Сөембикә ханбикә» Эскиз.

Гүзәлия Җәләлева әзерләде. ■

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның декабрь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Асаре гатикане [борыңгы әйберләрне] саклауга

Дахилия вәзарәте[1] янындагы техника комитетының ишарәсе буенча, асаре гатика саклау җәмгыяте шәһәр управасына мөрәҗәгать итеп, Сөембикә манарасы хакында түбәндәге тәфсыйлатне боеруын сораган: 1) манараның стеналары һәм сводларының ни хәлдә икәнлеге хакында; 2) андагы ярыкларның нинди рухта икәнлеге хакында; 3) манараның нигезе һәм салынган йиренең нинди туфрак икәнлеге хакында; 4) яңгыр суларын агызып тора торган әйберләре ничек ясалганлыгы вә ни хәлдә икәнлеге хакында; 5) бу манарага техник җәһәттән нинди кимчелекләр килгәнлеге хакында.

Кояш. – 1916. – №1052. – 8 декабрь.

Балалар кичәсе

Мәүлид шәриф мөнәсәбәте илә Шәрык клубы тарафыннан «Новый клуб»залында 22 нче декабрьдә пәнҗешәмбе көн балалар кичәсе ясала. Кичәдә Габдулла әфәнде Кариев риясәте белән «Сәйяр»труппа артистлары тарафыннан балаларга махсус спектакль бирелә. Спектакльдән соң һәртөрле балалар уены һәм бүләк өләшүләр булачак. Уен көндез 2 сәгатьтә башланып, 6 сәгатьтә тәмам булачак. Хатын-кызга, баласыз булса, югарыда балконнарда булу шарты илә керергә рөхсәт ителә. Билет бәһаләре балаларга бүләк илә 2 сум 50 тиен, хатын-кызга 2 сум, 1 сум 50 тиен куелган.

Кояш. – 1916. – № 1055. – 13 декабрь.

Гәзитә мөхәррирләренә отсрочка

9 нчы декабрьдә оборонага хезмәт итә торган мөәссәсәләрдә [оешмаларда] хезмәт итүчеләргә отсрочка бирү эшләрен карый торган мәркәз комитет мөселман гәзитәләрендә эшләүчеләргә биш кешегә отсрочка бирергә карар бирде. Рус гәзитәләренә көндәлек булу һәм 15 мең нөсхә таралу шарт ителә, мөселман гәзитәләренә ул шартлар булу лязим түгел. Бу карар хәзер генеральный штабның тасдыйкына [раславына] тапшырылган. Мөселман гәзитәләре басыла торган матбага белән аларның канторларында хезмәт итүче мөтәхассыйслар [белгечләр] да гомуми низам [тәртип] буенча отсрочка белән файдаланалар. Журналларга 1917 нче ел беренче гыйнварга кадәр отсрочка бирелгән иде. Ләкин мәркәз отсрочка комитеты журналларны югарыдагы карарга кертмәгән.

Кояш. – 1916. – №1057. – 18 декабрь.

Балалар кичәсе

22 нче декабрь, пәнҗешәмбе көн, көндез булачак бу кичә[2] шәһәремезнең ханым вә туташларының катнашы белән ясала вә балалар өчен мөмкин кадәр

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Дахилия вәзарәте – Эчке эшләр министрлыгы.

[2] Сүз мәүлид бәйрәме турында бара.

күбрәк кәеф вә сафа бирерлек рәвештә ителәдер. Гаять кыйммәтчелеккә карамыйча, кичәдә балаларга бүләкләр дә өләшеләчәктер.

Хәзерендә матур бер милли гадәткә әйләнеп киткән бу кичәнең балаларымыз өчен никадәр кирәкле бер күңел ачу булганлыгы турында сүз озайтып торырга урын юк. Бу кичәне балаларымыз ел буена зур бер шук белән көтеп алалар вә шул мөнәсәбәт белән олуг дини бәйрәмебезне шатлыклы бер кодсиять белән хәтерләрендә калдыралар. Милли вә дини тәрбия җәһәтеннән бу эшнең гаять зур файдасын ата-аналар, иншалла, үзләре дә яхшы төшенә торганнардыр.

Үз кәеф-сафаларымыз өчен уннарча тәңкәләрне бернәрсәгә санамаганымыз бу көннәрдә, балаларымыз рәхәте өчен өч сум сарыф итүне авырсынырга тиеш түгелмез. «Шәрык»клубы быелгы бу кичә өчен мең сумга якын хәраҗат [чыгым] ясады. Өмид итәмез, балаларын сөя вә аларның рәхәтен тели торган ата-аналар эшнең бу җәһәтен дә хәтерләреннән чыгармаслар вә шәрык клубының бу милли тәшәббесенә [башлангычына] ярдәм кулы сузарлар. Шатландырыгыз балаларыгызны!

Кояш. – 1916. – №1058. – 20 декабрь.

Бармый калмагыз!

Бүген, пәнҗешәмбе көн, 22 нче декабрьдә «Электро» кинематографында «Тормыш өчен терелү»дигән әсәр уйнала. Бу әсәр мәҗрух [яралы] һәм гарип солдатлар тормышыннан алынган дүрт бүлекле картинадыр. Моннан киленгән варидәтнең [акчаның] һәммәсе гарип гаскәриләр мастерскойларын яхшырту файдасына булачактыр.

Мәүлид ән-нәби укылачак

25 нче декабрьдә, якшәмбе көнне, 5 нче мәхәлләдә Ак мәчетнең түбән табәкасында [катында], мәдрәсәи Мөхәммәдиянең шөгъбәсеннән [бүлеге] булган фөкарә [ярлылар] мәктәбендә иртән тугыз ярым сәгатьтә мәүлид ән-нәби укыла башлаячак. Ирадәсе [теләге] булган әфәнделәр рәхим итсеннәр. Фөкарә мәктәбенең идарәсе.

Кояш. – 1916. – №1059. – 22 декабрь.

Георгиевский комитетка

Георгиевский комитетка иганә итәргә өндәп мөфти хәзрәт тарафыннан имамнарга таратылган циркуляр буенча, Казан өязе Субаш-Аты карьясенең имамы Габделфәттах әфәнде Вәлидов мәхәлләсе мөселманнарыннан 13 сум иганә Петроградтагы Георгиевский комитетка йибәрелгән.

Солдат хатлары

Без, мөселман солдатлары, әкса [ерак] шәрыкта, монгол сахраларында ике елдан бирле тормактамыз. Шушы вакыт эчендә һичбер татар китабы, гәзитәсе вә журналы күргәнемез юк. Милли матбугатны укырга бик мохтаҗмыз. Безнең шушы хәлемезне «Кояш»гәзитәсенә бассагыз, кеше укып хәлемезне белер вә химмәт ияләре үзләре укыган гәзитә вә журнал һәм рисаләләрен йибәрерләр иде. Адресымыз: ст. Чжалайнор, Вост.-Китайской ж.дор. 547 пеш. Симбир. дружин. 1ая рота, Муратову.

Кояш. – 1916. – №1061. – 29 декабрь. ■

Вак-вак ләтыйфәләр һәм хикәя кисәкләре*

Җомга көн татар балалары

– Уйнап-көлеп калыгыз, балалар! Бу көннәрегез санаулыдыр!

СУГЫШ ФРОНТЫНДА

– Иптәш! Сугышлар ничек бара?

– Бик шәп! Не түлке көне-төне сугышу, хәтта йокыга китсәң, төшемездә дә сугышамыз. Бервакытны төшемдә бер нимес солдаты илә кара-каршы карап торамыз – ул да атмый, мин дә атмыйм. Мин аны куркытырга ямьсезләнеп күземне акайтып җибәргән идем, карасам, нимес солдат, мылтыгын ташлап, артына карамастан чабып бара. Уянып китсәм, шул нимес солдаты, минем уянуымнан куркып, качып бара икән.

«Ялт-йолт» журналы. – 1916. – №116. – Б.10-11

.

КАЗАН ТРАМВАЕ ВАГОНЫ ЭЧЕНДӘ

Бер бик матур гына яшь ханым бер прапорщик илә кокетничать итеп йөриләр. Болар икесе вагонга кереп, беренче класс бүлмәсенә утыралар. Ханым янына бер юан корсаклы бай да кереп утыра. Ханымның буңар бик эче пошканлыктан, аңар ачуын белгертер өчен, ямьсезләнеп бер карый да, байга кисәк кенә арты илә әйләнеп утыра. Бай моны сизә дә, ханымга көлемсерәп әйтә:

– Бернәрсә дә эшләр хәл юк, биш тиенгә ике прапорщик уртасында утырырга тугры килми шул.

ТАТАР АРТИСТЫ БҮЛМӘСЕНДӘ

Иртә берлән сәгать 5ләрдә бер артистның бүлмәсенә бер карак нәрсә урларга керә. Артистның ишеге дә бикле түгел иде, чөнки бүлмәне бикләүне ыстыд иде: бүлмәдә стенада эленгән бер афиша һәм өстәлдә ярты графина су илә бер кыерчык каты ипи бар иде. Артист, үзе караватта баш астына пинжагын салган да, өстенә ярты одеал ябынып, гырылдый-гырылдый йоклый иде. Каракның бөтен бүлмәне кыштырдатып эзләп, бер файдалы нәрсә таба алмагач, биниһая моңар ачуы килә:

Ләтыйфә – мәзәк.

Якшәмбе көн татар балалары

– Берничә Казан вә Чистай хаиннәре (сатлык җаннары) атнага ун сумга мине саттылар. Сез, балаларымга, бу көн бәйрәм иттереп мине картайттылар. Ул җаныйлар белеп торсыннар: безгә дә алардан көләр көннәр килер.

– Юк, болай бармый, бу мәшәкатемнең үчен алырга кирәк, – дип, күгәреп беткән будильникның стрелкасын кире сәгать бергә китереп куя да, чыгып китә.

«Пумала».

«Ялт-йолт» журналы. – 1916. – №120. – Б.12-13

ВАК-ТӨЯК

– Петербургта безнең мөселман съезды нишләде?
– Әүвәл җыелды.
– Аннан соң?
– Аннан соң таралды.
– Соң нәтиҗәсе ни булды?
– Вәкилләр өчен бесплатный сәяхәт.
Газета-журналлар өчен бер айлык зур гына материал.

***

– Иптәш, мөгаллимнең башы беткән бит.
– Алла сакласын, кайсы мөгаллим?
– «Мөгаллим» журналын әйтәм.
– Ә, алай булса күптән вакыт, авыр туфрагы салмак булсын.

АМЕРИКАННАР КАПКА АЧУДАН ДА ФАЙДАЛАНАЛАР

Эдиссонның капкасы һәрвакыт ябык тора, ди. Капка өстендә: «Капка ачык, ләкин бик тыгыз ябыла, рәхим итегез!» – дип язылган, ди.

Килгән кеше, тырышып, капканы ачып керә, шулвакытта түбәнге өйдән югары өйгә бер чиләк су качать итеЛә, ди. Кара син, явызлар, капкадан да буш кермиләр, менә агай-эне, керәсең килсә, югары өйгә бер чиләк су меңгез әле, дип каршы алалар икән. Ходай органнар, өй ишекләрен ачканда бер чиләк шакшы су чыгарып түгәргә кушсалар, һич гаҗәп түгел.

«Ялт-йолт» журналы. – 1915. – №85. – Б.16

*Текстны һәм искәрмәләрне басмага **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Татарстан Китап палатасының бүгенге бинасы

«Безнең мирас»

елъязмасы / декабрь

• 780 ел элек (1236)

Бату хан Болгар дәүләтен яулап ала.

• 185 ел элек (1851)

26 декабрьдә бөек шагыйрь, мәгърифәтче Мифтахетдин Камалетдин улы Акмулла дөньяга килә.

• 140 ел элек (1876)

2 декабрьдә күренекле сәяси эшлекле, Төркия Президенты Кәмаль Ататөреккнең мәдәният һәм сәясәт эшләре буенча киңәшчесе Йосыф Акчура (1876-1935) дөньяга килә.

• 115 ел элек (1901)

«Победа» химия лабораториясе прибор-җиһазлары һәм савыт-саба заводы төзелә. Ул хәзерге Яшел Үзән районының Васильево бистәсендә урнашкан.

• 90 ел элек (1926)

21 декабрьдә Татарстан Китап палатасы оеша.

• 85 ел элек (1931)

8 декабрьдә Һади Такташ (1901-1931) вафат була.

• 80 ел элек (1936)

«Совет әдәбияты» журналында Фатих Кәримнең «Аникин» поэмасы дөнья күрә.

• 45 ел элек (1971)

«Казан утлары» журналында Сибгат Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» поэмасы басылып чыга.

• 25 ел элек (1991)

22-23 декабрьдә Уфадагы Татар мәдәнияте үзәгендә һәм Башкорт дәүләт университетында Әбрар Кәримуллин белән очрашу була. Казаннан килгән галим очрашуларда катнашучылар алдында Татарстан һәм татар-башкорт мөнәсәбәтләре, татар халкының мәдәнияте һәм төрки халыклар арасындагы урыны турында сөйли.

• 5 ел элек (2011)

15 декабрьдә Марсель Сәлимҗанов исемендәге Актёрлар йортында тәнкыйтьче, шагыйрь, мөхәррир Фәиз Зөлкарнәйнең тууына 60 ел тулу уңаеннан «Кайту» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә була. Кичәне шагыйрь Ркаил Зәйдулла алып бара. ■

Мирасворд

Византия тәңкәсе

Айзек ... (Америка фантасты)

Бик зур, көчле, тиз оча торган әкияти кош

Өлкән мулла

Вәлиди, Нури, Зәйнуллин

«Саф күңел» романы авторы

... Атнабаев

«... - егетләр» драмасы (Туфан Миңнуллин)

Тарихчы Сәлам ...

Юл күрсәтүче, юламан (бор.)

Актер Мохтар ...

Шагыйрь Харрас ...

XV-XVII йөзләрдә татар ханлыкларында идарәче ыруг

Япония императоры титулы

Мисыр мифологиясендә күк Алласы

Борынгы төрки дәүләтләрдә ил башлыгы, хөкемдар титулы

Борынгы Римда 30 җайдактан торган атлы отряд

Ык кушылдыгы

Матур, сөйкемле (иск.)

Тигез, чокыр-чакырсыз (диал.)

Үпкә, кинә (диал.)

1914-1921 елларда Оренбургта эшләгән нәшрият

Биектау районындагы авыл

Даниядә административ-территориаль берәмлек

Япон кылычы

Әйткән сүздә тору, тугрылык (иск.)

Дини нәсихәт бирү рәвешендәге чыгыш

Композитор ... Даутов

Шагыйрь ... Мөдәррис

Гали ... (күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист)

Юеш балчык (диал.)

Язучы ... Фәлах

Боек ... юлы

Гарәп хәрефе

Баянчы ... Гомәров

Тыгыз кижемамык тукыма

Әйләнә (диал.)

Тур Хейердал көймәсе



«..., яки гамәл вә җәза» романы (Ризаэтдин Фәхретдин)

... Гарипов (башкорт шагыйре)

Мордваларның милли уен коралы

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: сөлес, вирд, мәкам, өсәк, Или, ная, Маннур, Окс, Олт, Цветаева, Рэм, Алиш, «Ана», әсас, ихрам, Җик, җофар, Алпаров, ончы, «Ил», балбал, Рико, саам.
Өстән аска: Сәмәндәр, Эсхил, Ликия, ал, баҗа, боз, Сәмитова, Мориак, келә, фоллис, Мстислав, бра, Аша, очлым, Ихсанова, җен, улан, Декарт, аякчы.

Рәис Габдулла төзеде.

2016 ЕЛГА «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

№1. – Б.3.

Л.Лерон.Хәтере барның әйтере бар. – №10. – Б.3; Без – рәхмәтле халык. – №11. – Б.3.

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР

Газизә Сәмитова. – №3. – Б.3.

Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский) – №5. – Б.3.

М.Җәлил. – №2. – Б.3.

Марс Макаров. – №12. – Б.3.

Писатели мира о Тукае / Әдипләребез, шәхесләребез Тукай турында. – №4. – Б.6-15.

Сибгат Хәким. – №7. – Б.3.

Тәүфикъ Әйди. – №6. – Б.3.

Туры Тукай сүзләре. – №4. – Б.3-5.

Фатих Әмирхан. – №1. – Б.4-5.

Харрас Әюп. – №8. – Б.3.

ТАРИХИ МИРАС

(Түгәрәк өстәл). «Тукайны өйрәнгәндә сенсация артыннан куарга ярамый!» – №4. – Б.46-55.

(Түгәрәк өстәл) Авыл тарихы – милләт тарихы! – №9. – Б.29-37.

А.Борһанов. Якты өмет – остазыбыз! – №1. – Б.31-35; «Сәфәр – 89». – №12. – Б.12-16.

А.Арсланов. Алтын Урданың икътисади багланышлары. – №12. – Б.6-11.

Ә.Әхсәнов. Казанның беренче ханнары. – №6. – Б.14-17.

Ә.Максуди. «Йолдыз»ның тарихы. – №9. – Б.17-22.

Ә.Мөхәммәдиев Зөләйха. – №9. – Б.6-11; №10. – Б.12-20; №11. – Б.14-17; Чыңгызхан хәйләсе. – №2. – Б.6-11; №3. – Б.6-10; №5. – Б.11-19; №6. – Б.8-13; №7. – Б.6-11.

Ә.Фәйзрахманов. Мотыйгулла, Мөхәммәтгариф һәм Габдулла. – №4. – Б.16-21.

Г.Кәрам. Тукай турында исемдә калганнар. – №3. – Б.17-19.

Г.Латыйф. Татар халык шагыйре Габдулла Тукай турында истәлек. – №4. – Б.34-42.

Г.Мишкинене. Литва татарлары кулъязмасы. – №12. – Б.17-19.

Г.Мөхәммәтшин. Балтач төбәгендә Тукай эзләре. – №10. – Б.28-39.

И.Гафаров. Һади Атласи турында яңа чыганаклар. – №8. – Б.6-12.

И.Заһидуллин. Равил Әмирхан мирасы. – №9. – Б.23-28.

И.Миргалиев. Бөек татар әмире – Мамай. – №2. – Б.12-15.

Изге Синодның Праваслау Грек-Россия Чиркәвенең тугрылыклы балаларына мөрәҗәгате илә граф Лев Толстой турындагы 1901 ел 20-22 февраль карары. – №8. – Б.20-21.

Иске Кулаткы. – №8. – Б.38-39.

Исмәгыйль бәй Гаспринский илә очрашу. – №5. – Б.30-34.

К.Әхмәров. Сабантуй. – №5. – Б.45.

Л.Гобәйдуллин. Каләмнең кальбе – милләт язмышында! – №1. – Б.19-20; «Шималь ягы» газетасы. №4. – Б.25-29.

Л.Константинова. Керәшен авыллары тарихын өйрәнү тәҗрибәсе. – №7. – Б.24-26.

Л.Мортазина. «Шенас» – кызыксынучан акыл. – №6. – Б.18-27.

Л.Толстой. Синодның 20-22 февраль карарына һәм шул уңайдан миңа килгән хатларга җавап. – №8. – Б.22-29.

Л.Тябина. «Үзем дә, балалар да ялангач...» – №4. – Б.43-45.

Л.Хәмидуллин. Уңышлы башламнар. – №11. – Б.32-35; №12. – Б.24-33.

М.Кәримов. «Мән чурамын, чурамын...» – №3. – Б.11-16.

Н.Шәйдуллина. Болгар. Успение чиркәве. – №1. – Б.6-7; Болгар. Кара пулат. – №2. – 4-5; Болгар. Ак пулат. – №3. – Б.4-5; Болгар. Кече манара. – №5. – Б.4-5; Болгар. Ханнар төрбәсе. – №6. – Б.6-7; Болгар. Көнчыгыш пулат. – №7. – Б.4-5; Болгар. Хан сарае. – №8. – Б.4-5; Болгар. Археологик тикшеренүләр. – №9. – Б.4-5; Болгар. Ак мәчет. – №10. – Б.8-9; Болгар. Икмәк музее. – №11. – Б.8-9; Болгар. Табиб йорты. – №12. – Б.4-5.

Н.Гариф. Авыл тарихын языйм, дисәң... – №3. – Б.30-33.

Н.Петров-Текин. Керәшен Сәрдәсе: авыл тарихы, халык язмышы, әүвәлге документлар (1490-1900). – №7. – Б.28-35.

Н.Таиров, И.Таиров. Йосыф Акчурин йорты. – №8. – Б.17-19; Акчуриннар һәм Фатыйма Мөхтәрова. – №2. – Б.16-17; Якуб Акчурин йорты. – №11. – Б.32-35.

О.Сенюткина. Түбән Новгород татарлары. – №7. – Б.12-17.

Питрау мизгелләре. – №7. – Б.27.

Р.Әминов. Каргалы казаклары. – №11. – Б.18-23.

Р.Вәлиев. «Илдә финанс тәртибе бетте...» – №11. – Б.24-31.

Р.Галләм. Хөсрәү би язмышы. – №11. – Б.36-39.

Р.Гарипов. «Уйларыбызны әйтүдә бик сак булырга туры килде...» – №9. – Б.12-16.

Р.Исламов, Җ.Миңнуллин. Тукай – ядкярләрдә. – №1. – Б.24-30; №5. – Б.27-29.

Р.Исхаков. Керәшеннәрнең ислам дине изгеләренә гыйбадәте. – №7. – Б.18-23.

Р.Мәрданов. Гәүһәр Болгарга килдем... – №5. – Б.6-10.

Рауза Бикколова: «Бабаларым затлы кешеләр иде...» – №11. – Б.40-44.

С.Максимов. Казан губернасы керәшеннәре ышануларында мәҗүсилек күренешләре. – №7. – Б.36-44; №8. – Б.30-37.

Т.Биктимерова. Кызлар язмышы – милләт язмышы. – №12. – Б.30-33.

Т.Галиуллин. Хәлең ничек, Бараба иле? – №2. – Б.18-21.

Ф.Газизова. Гайнә иленең мәгариф каһарманнары. – №3. – Б.20-25.

Ф.Ислаев. Атка сугылган тамгалар. – №5. – Б.20-26.

Ф.Тамир. Төрек телен гадиләштерү хәрәкәте һәм Гаяз Исхакый. – №1. – Б.21-23.

Ф.Туйкин. Сугышчы Сатыш әфәнде. – №1. – Б.8-18.

Ф.Фәтхи. Уфа да Тукай эзләрен саклый. – №4. – Б.22-24.

Х.Бәдигый. Казан патшалыгы турындагы тарих. – №10. – Б.21-27.

Х.Насыйров. Кулаткы морзалары. – №5. – Б.41-44.

Һади Атласиның «Йолдыз» газетасында басылган ике мәкаләсе. – №8. – Б.13-16.

Ш.Әхмәр. Русиядә гарәби хәреф илә басмачылык. – №3. – Б.26-29.

Э.Галимҗанова. «Сүз» газетасының Тукайга багышланган бер саны. – №4. – Б.30-33.

Э.Сәлахова. Метрикада – татарның үткәне. – №12. – Б.20-23.

Эдуард Ганиев: «Дин һәм туган тел – һәрвакыт янәшә!» – №5. – Б.35-40.

ТАТАР ГАМЕ

А.Борһанов. Тирән тарихлы Азнакай. – №7. – Б.45-49.

А.Гәрәева. Гыйлем ияләре илләрне һәм дәверләрне гизә. – №1. – Б.48-51.

Ә.Әскәров белән Р.Сәгъди әңгәмәсе. «Шулвакытта мин кулыма китап алам...» – №3. – Б.45-47.

Готтхольд Вайль туплаган татар текстлары. – №5. – Б.54-59.

Илдән килгән кунакны кабул иттең, Кулаткы! – №7. – Б.58-59.

Ирек Шәрипов: «Россиядә милли сәясәтнең йөзен Татарстан һәм татарлар билгели». – №1. – Б.36-40.

Р.Мөхәммәтша. Нәсүр Юрушбаев: «Тарих «әгәр дә» дип сөйләүне өнәми...» – №5. – Б.46-53.

Р.Сәгъди. Җөри Даругасы. – №7. – Б.50-57.

С.Шәйхулла-Әнәле. Замана фаҗигасе. – №2. – Б.31-35.

Татар матбугаты һәм мирас. (Түгәрәк өстәл). – №2. – Б.22-30.

Ф.Ислаев. Җәгъфәр тарихы. – №3. – Б.48-55.

Ф.Садриев. Иске демократиядән яңасына атлаганда. – №3. – Б.34-39.

Ф.Хуҗин. Болгар һәм Спас районы энциклопедиясе. – №3. – Б.40-44.

Х.Миңнегулов. Мөхәммәдьярларга тиң шәхес. – №6. – Б.28-35.

Хәбир Ибраһим. Туган йорт. – №2. – Б.41-47.

Шәехҗан Фәния Хуҗахмәт. Габдулла Тукай: «Бу милләтне Ходаем бәхетле итсен». – №4. – Б.56-61.

Илдар Гыйльметдинов: «Булачак һәр педагогны әүвәл педколледжда укытыр идем...» – №8. – Б.40-47.

М.Кәримов. Нурланыш галиме. – №9. – Б.80-83.

Р.Сәгъди. Мансур Ярмиев: «Без татарлыгыбызга горурланып яшәргә тиеш!..» – №11. – Б.48-51.

Р.Юныс. Алардан шәп мирас калды. – №11. – Б.52-55.

Ә.Зарипов. Киләчәк кешесе үрнәге. – №12. – Б.34-41.

Без килмешәк түгел бу җирдә! – №12. – Б.42-43.

ХӘТЕР САНДЫГЫ

А.Филиппов. Сүз һәм сурәт. – №1. – Б.56-57.

А.Хәмзин. Әтиемнең фронт эзләреннән. – №6. – Б.89-96.

Ә.Фәйзрахманов. Афәт. – №6. – Б.97-101.

Ә.Шамова. Әткәй каеннарының хәтерләре. – №7. – Б.90-93.

Ә.Шәрипов. Әтине бер күрдем... төшемдә... – №6. – Б.82-86.

З.Зәйнуллин. Байгара яланында төче кумәч. – №2. – Б.44-45; Гали абый. – №7. – Б.94-95.

И.Сакаева. А.Дубин. Шәхесләребез: Иркә Сакаева. – №1. – Б.58-59.

И.Хәйруллина. Солдат (Актаныш музеена истәлекле әйберләр). – №7. – Б.96-97.

Н.Фәттах. Тарихи спектакльләр. – №2. – Б.46-49.

Р.Гаташ. Сүз һәм сурәт. – №3. – Б.60-63.

Р.Мөхәммәтша. Мин белгән Тукай. – №7. – Б.98-101.

Р.Сафин. Гали ага киңәшләре... – №6. – Б.87-88.

Ф.Галимуллин. Гариф бабай дәресләре. – №3. – Б.64-67.

Н.Дунаев. Сүз һәм сурәт. – №8. – Б.60-63.

А.Фәизов. Бер кат кис... – №9. – Б.76-79.

Д.Фәйзуллина. Бер рәсем тарихы. – №10. – Б.80-81.

Н.Нәккаш. Милләт хадиме. – №10. – Б.82-88.

Р.Мирхәйдәров. Ялтаның җылы хатирәсе. – №11. – Б.32-35.

М.Зәйнетдинов. Бер рәсем тарихы. – №12. – Б.90.

Үткәннән хат. – №12. – Б.91.

ӘДӘБИ МИРАС

(Туфан Миңнуллинның Гәрәй Рәхимгә хатлары). «Күп мәсьәләдә фикерләребез уртак». – №7. – Б.70-75.

«Ак чәчәкләр» әсәре: алтмыш ел элек. – №3. – Б.80-87.

«Элек дәресләрдә уку шигырь әйтү белән башлана иде...» №1. – Б.81-85.

А. Сөнкишев. Кайтаваз. Җәлилнекеме соң алар? – №1. – Б.78-80.

Атилла Расих: «Мин шулай өметләнеп ятам...» №9. – Б.64-69.

Ә. Зарипов. Зәгъферән. – №1. – Б.73-77.

Ә.Шәрипов. Остазымның хаты. – №12. – Б.58-59.

Г.Давыдова. Бер китап эзеннән... №9. – Б.72-75.

Г.Хәсән. Кайтаваз. Киң сибелгән безнең халык җир йөзенә. – №12. – Б.77.

Д.Гайнетдинова. Хатирәләр кайта яңарып... – №6. – Б.64-67.

Җ.Алмаз. Шагыйрә Газизә Баһаветдин кызы Сәмидова. – №3. – Б.72-75; №5. – Б.78-81; №6. – Б.48-51.

З.Ишаев. Үтерүче. – №5. – Б.92-97; №6. – Б.52-63.

И.Ямалтдинов. Тукай энциклопедиясе. – №2. – Б.78-79.

Исхак Мосули һәм кәрҗинле сарай хикәяте. – №5. – Б.72-77.

Й.Баласагуни. Кутадгу билик (Котайткыч белем). – №1-3; 5-12.

К.Бикколый. Сабирҗан агай: 1906 сәнәдә булган ачлыкны тасвир кыйлган роман. – №8. – Б.74-85.

К.Булатова. Язгы хатирәләр. – №5. – Б.90-91.

К.Тинчурин. Каракүз. – №2. – Б.64-77.

Кыйссаи Таһир илә Зөһрә. – №1. – Б.64-69.

Л.Зөлкарнәй Кара һәм ак мунча. – №12. – Б.75-76.

Л.Лерон. Гомерлек иман. – №6. – Б.68-71.

Л.Тимерова. Һәр әсәре – камиллек үрнәге!

М.Акмулла. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе календаренда (1905) Акмулла шигырьләре. – №2. – Б.54-55.

М.Әгъләм. Мин әйттем... – №10. – Б.63.

М.Әхмәтҗанов. Габдулла Тукай Олы Мәңгәрдә. – №4. – Б.71.

М.Вәлиев. Чын кеше кадере. – №4. – Б.64-70.

М.Гали. Габдулла Тукай белән күрешүем. – №4. – Б.62-63.

М.Фәйзуллин. Галиябануның сәхнәгә менгән көннәре. – №11. – Б.76-79.

Н.Нәккаш Олы җанлы шәхес иде. – №12. – Б.68-74.

Н.Фәттах. Махатма Еники һәм Батыев. – №7. – Б.76-79.

Р.Мәрданов. Бәрәкәтле мирас ядкярләре. – №2. – Б.60-63.

Р.Харис. Фатих Кәрим: әсәр, чор, язмыш. – №5. – Б.82-87.

Р.Батулла. Күн чемоданда сакланган хәзинә. – №2. – Б.59.

С.Зыялы. Мәңгедәшләр. – №3. – Б.76-79.

С.Кальметов. Кияү сайлаганда. – №11. – Б.74-75.

Үткәннән хатлар: Г.Ахуновтан – А.Шамовка.– №5. – Б.88-89.

Ф.Галимуллин. Тукай энциклопедиясе. – №1. – Б.81-85.

Ф.Кутлу. Мөнир абый Нигъмәт турында истәлек. – №3. – Б.88-93.

Х.Миңнегулов. Казакъның «баш акыны». – №10. – Б.64-79.

Хәсән Туфан. «Фатих ага исеменә дә тел тидергән чакларыбыз булгандыр...» – №1. – Б.70-72.

Ч.Айтматов. Чыңгызханның ак болыты. – №8. – Б.68-73; №9. – Б.52-57; №10. – Б.56-62; №11. – Б.64-73; №12. – Б.17-19.

Ш.Мостафин. «Штык һәм каләм белән...» – №12. – Б.60-66.

Ш.Рәкыйпов. Балалар әдәбиятына йөз белән. – №2. – Б.56-58.

ӘДИП АВЫЛЫ

Роберт Зарипов. Нугайбәкләр шәҗәрәсе. – №1. – Б.88-91.

ТАБИГЫЙ МИРАС

Илдар Кыямов. Көмеш күзле чишмәләр... – №1. – Б.92-99.

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

Р.Мөхәммәтша. Кояш кына күктә мәңге йөзәр... – №1. – Б.100-102.

Р.Мөхәммәтша. Һади Такташ. – №1. – Б.103-107. Салих Сәйдәшев. – №2. – Б.80-81. Фатих Әмирхан. – №3. – Б.94-97. Габдулла Тукай. – №4. – Б.72-79. Сибгат Хәким. – №7. – Б.86-89. Мөхәммәдьяр, Колшәриф, Габделнасыйр Курсави, Шәмсетдин Зәки, Әхмәтҗан Тубылы, Мифтахетдин Акмулла. – №8. – Б.98-101. Галимҗан Ибраһимов. – №11. – Б.80-83. Һ.Атласи.– №12. – Б.88-89.

Р.Фәттахова. Нурихан Фәттах. – №6. – Б.79-81.

Тукай бәете. – №4. – Б.80.

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

А. Тимергалин. Миллият сүзлеге. – №№1-12.

Ә.Кәримуллин. РАЯлашмагыз! – №1. – Б.110-111; №2. – Б.97-99; Сүзләр тарихыннан: «Карандаш». – №3. – Б.110-111.

Г.Бәширов. Тел – тормыш көзгесе. – №11. – Б.99-100.

Г.Хаҗиева. Исемнәр, кушаматлар... – №7. – Б.108-111.

Й.Гәрәй. Әнием теле – күңелем гөле! – №7. – Б.105-106; Этнонимнар ни сөйли? – №9. – Б.109-110.

Р.Акъегет. Фидакяребез. – №8. – Б.106-108.

Р.Низами. Сүзләр картаямы?.. – №6. – Б.111-113.

Ф.Госман. Чырткемесь. – №9. – Б.111.

Х.Исмәгыйлев. Пибик. – №11. – Б.98.

ХӘТЕР САГЫНДА

Г.Җәләлева. Көзге. – №1. – Б.112-113; «Алтын битлек» – №2. – Б.108-109; «Әби патша» каретасы. – №6. – Б.106-107; ТАССР мирасы. – №8. – Б.102-103; Әлифба. – №9. – Б.112; Сөембикә ханбикә. – №12. – Б.108-109.

Г.Тукай әдәби музеенда шагыйрьнең шәхси әйберләре. – №4. – Б.105-107.

Л.Гаделшина Алар ГУЛАГта дуслашкан. – №11. – Б.101-103.

Л.Нәгыймов. Сугыш кораллары. – №10. – Б.8-9.

Н.Фәттахова, Л.Харасова. Җәлил мирасы. – №6. – Б.102-105.

Р.Мөхетдинова. Татар авылы хатын-кызы киеме. – №3. – Б.112-113; Агач эшләнмәләр. – №11. – Б.112-113.

Р.Халитов. Затлы мирас – гаиләм ядкяре. – №5. – Б.106-108.

Ф.Дәминова. Сорбонна шәкерте. – №5. – Б.104-105; Зур Чынлының олуг улы. – №11. – Б.104-105.

Ф.Кутлу. Еллар кайтавазы, яки бер сәфәр. – №12. – Б.104-107.

ДИНИ МИРАС

А.Гәрәева. Догалы китаплар нәшрияты. – №5. – Б.65-67.

Г.Гатауллин. Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы. – №9. – Б.42-47; №10. – Б.40-51.

Галиев мәчете.– №2. – Б.39.

Киләчәк буыннарга мөрәҗәгать.– №6. – Б.43.

М.Галләм. Исламияттә музыка. – №2. – Б.36-38; Әманәт. – №5. – Б.64.

Т.Ялчыгол. Шәех Хәбибулла кыйссасы. – №6. – Б.40-42.

ПЕДАГОГИК МИРАС

Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре. – №2. – Б.43.; №3. – Б.59; №7. – Б.62-65.

Т.Биктимерова. Кыз балаларга тәрбия бирү хакында. – №6. – Б.36-39.

Ф.Сөләймания. Гаилә дәресләре. – №2. – Б.40-42; №3. – Б.56-58; – №5. – Б.60-63.

СӘНГАТИ МИРАС

А.Алмазова. «Шүрәле» балетының катлаулы тарихы. – №4. – Б.96-104.

А.Хәкимова. Якты күңелле олуг җырчы. – №8. – Б.92-97.

Ә.Зарипов. Холык. – №3. – Б.98-103; Тукайга якынаю баскычлары. – №4. – Б.81-87; Нурлы сәхнәдә иҗат нуры. – №8. – Б.86-91; №9. – Б.84-89.

Ә.Шакиров. Вафирәкәй. – №5. – Б.102-103.

Г.Сафиуллина. «Арча гимны» – йөрәк җырым». – №3. – Б.104-105.

Д.Гайнетдинова. Бакый аганы сагыну. – №9. – Б.100-105.

И.Әхмәтҗанов: «Тукай миңа мәрхәмәтле булды...» – №4. – Б.90-95.

И.Хәйруллин. Гади кеше. – №5. – Б.98-101.

Н.Әлмиев. Остазым Бакый Урманче. – №9. – Б.96-99.

Н.Игъламов. Театр белеменең йөзек кашы. – №2. – Б.82-86.

Р.Батулла. «Сират күпере». – №4. – Б.88-89.

Р.Игъламов. Безнең замандашыбыз Камал. – №2. – Б.87-93.

Р.Сәгъди. Тетрәндереп киткән алиһә! – №6. – Б.72-78; Садриевлар кавеме. – №10. – Б.89-99.

Р.Шаһиева, Р.Фәизова. Милләтнең күңел җәүһәрләре. – №12. – Б.78-87.

Ф.Арслан. Илаһи моң иясе. – №9. – Б.90-95.

Ф.Мөслимова. Татар моңын дөньяга таратучы. – №11. – Б.90-95.

ТАТАР ҖЫРЫ

А.Хәлим. Сагыштан туган сабырлык. – №8. – Б.109-113.

Г.Сафиуллина. Татар җыры – ул мәңгелек. – №12. – Б.94-98.

М.Макаров. Урау юллар гизеп табылган бәхет. – №12. – Б.99-101.

Р.Котлыев. Онытылмас очрашу. – №5. – Б.109-111.

Р.Курамшин. Мәшһүр җырчы, миһербанлы зат... – №7. – Б.80-83.

Т.Миңнуллин. Үз ягының баласы. – №7. – Б.84-85.

Ш.Әхмәтҗанов. Милләт яшәсә, Тукай онытылмас! – №4. – Б.108-109.

СӘНАИГЫ НӘФИСӘ

Р.Фәизова. Бөек остазга иң якын рәссам. – №2. – Б.100-107.

СПОРТ

Ә.Фәйзрахманов. Башкала, спорт һәм җитәкчеләр. – №2. – Б.112-114.

Без – көрәшче халык. – №2. – Б.115.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» – 25

«Без – мираслы халык». Рәхмәт хатлары, тәбрикләүләр. – №11. – Б.4-11.

Ак юл сиңа, «Мирас»ыбыз! – №7. – Б.60-61.

Ә.Фәйзрахманов. Милләтне кайгыртучы басма. – №8. – Б.52-57.

Күренекле дәүләт эшлеклеләре, шәхесләр, әдипләр, галимнәр – журналыбыз хакында. – №10. – Б.4-7.

М.Госманов. Мирасыбызның колачы киң. – №8. – Б.58-59.

М.Мәхмүтов. Ә.Кәримуллин: «Без нинди мираска мохтаҗ?» – №9. – Б.38-41.

ТАТАР МӨҺАҖИРЛӘРЕ

Ф.Гаффарова. Хәмит Зөбәер Кошай. – №8. – Б.48-51; Сания Гыйффәт. – №11. – Б.56-59.

100 ЕЛ ЭЛЕК...

Л.Гобәйдуллин. «Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 ел. – №1-12.

ШАЯН МИРАС

Көлке куа килә... – №1. – Б.116-118.

Р.Шәрәфиева. Вак-вак ләтыйфәләр һәм хикәя кисәкләре. – №8. – Б.116-117; Вак-вак ләтыйфәләр... – №9. – Б.116-117; №11. – Б.116-117; №12. – Б.112-113.

МИРАСВОРД. – №№1-12.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ. – №№1-12.



СОДЕРЖАНИЕ

Историческое наследие: Булгар. Дом лекаря; Экономические связи Золотой Орды. А.Арсланов; «Сәфәр - 89». А. Бурганов; Рукопись литовских татар. Г. Мишкинене; Прошлое татар – в метриках. Э.Салахова; Судьба девочек – судьба наций. Т.Биктимерова.

Татарский мир: Образец будущего человека. А.Зарипов.

Литературное наследие: Кутадгу билик. (Благодатное знание). Ю.Баласагуни; Белое облако Чингизхана. Ч.Айтматов; Письмо наставника. А.Шарипов; «Со штыком и пером...» Ш.Мустафин; Был человеком с великой душой. Н.Наккаш.

Художественное наследие: Драгоценности национальной души. Р.Шагиева, Р.Фаизова

Татарская песня: Татарская песня – это вечность! Г.Сафиуллина; Счастье, найденное через тернии. М.Макаров.

В глубине памяти: Эхо веков или одно путешествие. Ф.Кутлу; Царица Сююмбике. Г.Залялова.

100 лет назад..: «Казанские вести» в газете «Кояш»: декабрь 1916 года». Л.Губайдуллин

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

Historic heritage: Bulgar. Healer's house; Economic relations of the Golden Horde by A.Arslanov; «Safar - 89» by A. Burganov; The manuscript of the Lithuanian Tatars by G.Mishkene;The last of the Tatars are in by E.Salakhova; The destiny of girls is a destiny of nation by T.Biktimerova.

The Tatar world: The model of the man of future by A.Zaripov.

Literary heritage: Kutadgu bilik («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; The mentor's letter by A.Sharipov; «With bayonet and quill... » by Sh.Mustafin; He was a man with great soul by N.Nakkash.

Creative heritage: Jewels of national soul by R.Shagieva, R.Faizova.

Tatar song: Tatar song is an eternity! by G.Safiullina; The happiness found through obstacles by M.Makarov.

From the depth of memory: Echo of centuries or one trip by F.Kutlu; Tsaritsa Suyuymbike by G.Zalaleva.

100 years ago...: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: November of 1916.

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation life.

ТАТАРСТАН РӘССАМНАР БЕРЛЕГЕНӘ – 80 ЕЛ



АЛДАГЫ САННАРДА:

● «Салих абыйны соңгы күрүем 1994 елның 25 августында булды. Бу – җәлилчеләрне, шулар арасында Абдулла Батталны да җәзалап үтерүгә илле ел тулу уңаеннан кирмән янында аларның барельефларын ачу тантанасы көне иде. Тантанага килгән Салих абый белән исәнләшкәч, ул миңа: «Туганым икәнеңне чамалыйм, танымыйм гына», – диде...»
Фәрит Баттал. «БАТТАЛ БУЛУЫН ОНЫТМАДЫ...»

● «Лагерьда әдип гомеренең соңгы – фаҗигале акты уйнала: төрмә ялчылары махсус оештырган әләк-донослар нигезендә Ф.Бурнаш өстеннән яңа җинаять эше кузгатылып, НКВДның Махсус киңәшмәсе 1942 елның 15 июль утырышында әдипне «сугыш шартларында Советка каршы коткы сүзләр таратканы өчен атарга» дигән хөкем карары чыгара».
«ФӘТХИ БУРНАШ». Р.Мөхәммәтша әзерләде.

● «Җефет кала Кырым ярымутравындагы иң яхшы сакланган мәгарәле ныгытма-кала икән. Ниһаять, без шушы каланың капка төбенә менеп җиттек. Бу капка Кече капу – Кече капка дип атала. Капка чыннан да әллә ни зур түгел, ул дошман үтә алмаслык биек диварда уелган».
Солтан Шәмси. «ҖЕФЕТ КАЛАГА СӘФӘР».

● «Хатын-кызның күңеле нечкә
Тиз кырыла, өзелә.
Хатыныңны яхшы тотсаң,
Шунда дөнья төзелә».

1905 нче елда Кабан күленә ташланган хатын вакыйгасы.
«МОҢЛЫ ХАТЫН БИБИГАЙШӘ». Э.Сабирова әзерләде.

● «Сорбонна университетында укыткан С.Максудины 1923 нче елда, Йосыф Акчура ярдәме белән оештырылган «Төрек оҗагы» оешмасында доклад сөйләргә дип, Анкарага чакыралар, шул килүдә Мостафа Кемал паша белән күрешү дә планлаштырыла. Бу очрашуда Ататөрек аңа тормышын үзгәртердәй тәкъдим ясый: «Яңа дәүләт төзибез. Сезнең кебек галимнәргә ихтыяҗыбыз булачак», – дип, Төркиягә чакыра».
Әлфинә Сибгатуллина. «ҮЗСҮЗЛЕ ПРОФЕССОР САДРИ МАКСУДИ».

4 612750 670172

ИНДЕКС:
Татарстанда – 54132 (П-2343)
Россиядә – 70275
www.beznenmiras.ru